ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№8 (367)
АВГУСТ 2022

КАЗАН КҮГЕ ҺӘРЧАК АЯЗ!

Фото: Александр Ефремов

ТАТАРСТАН АВИАТӨЗҮЧЕЛӘРЕ ИҢ ҖИТДИ СЫНАУЛАРГА ДА БИРЕШМӘС

Татарстанда авиация төзелеше – гаять куәтле җитештерү комплексы. Ул иң зур һәм катлаулы бурычларны да үтәргә сәләтле. Казан авиазаводының заманча цехларында җитештерелә торган очкычлар дәүләт хәрби куәтенең ышанычлы нигезе булып тора.

Илебез авиация сәнәгатенең әйдәп баручы предприятиесенә әйләнгән бу комплекска күп еллар элек авиатөзүчеләрнең фидакарь хезмәтләре белән нигез салына. Бөек Ватан сугышы елларында Казандагы цехларда Пе-2 пикировщиклары һәм дошманның котын алып торган легендар төнге По-2 бомбардировщиклары җыела. Соңрак биредә беренче реактив стратегик Ту-16 бомбардировщиклары да, тәүге реактив Ту-104 пассажир самолетлары да җитештерелә.

Казан авиазаводы – озак еллар буе гражданнар авиациясе флагманы булган Ил-62 лайнерларын җитештерүче дә. С.П. Горбунов исемендәге авиация заводы цехларында вакытны дистә елларга узып эшләнгән стратегик Ту-160 ракета йөрткече дә җыела! «Белый лебедь» илне саклау калканының нигезен тәшкил иткән стратегик кораллы көчләрнең иң мөһим өлешенә әйләнә.

Бүген – Ту-22М3 һәм Ту-160М самолетларын модернизацияләүдән соң – Казанда өр-яңа мөмкинлекләргә ия Ту-160М2 ракета йөрткечләре җитештерелә башлады. Болар барысы да предприятиене яңа техник дәрәҗәгә күтәрә. Бу исә авиация заводының заманча җитештерү куәте, зур фәнни потенциалы, биредә югары һөнәри осталыкка ия инженерлар һәм техник хезмәткәрләр эшләве хакында сөйли.

Импортны алыштыру кысаларында Казанда авиация кластеры төзү мәсьәләсе карала. Елына 1 миллион эшләнмә җитештерү куәтенә ия «Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе» механика-эшкәртү үзәге проекты төп резидент булырга мөмкин.

Авиатөзүчеләргә аяз күк йөзе, матур очышлар һәм яңадан-яңа уңышлар телисе килә!

Иманым камил, авиация тармагы киләчәктә дә алгарышның ышанычлы локомотивы булыр, ә Татарстан авиатөзүчеләре заманның иң җитди сынауларына да бирешмәс.

Татарстан Республикасы Президенты
Р. Н. Миңнеханов

Фото: ТР Президенты матбугат хезмәте

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская,
Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Сафа Гәрәев, Илдус Заһидуллин, Илүзә Илшатова,
Ксения Сёмина, Наталья Урейская
Фотографлар: Александр Ефремов, Алсу Шакирова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Лев Волегов, 1 нче классны штурман-сынаучы.
Алексей Пилипенко фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О–2321
Басарга кул куелды: 09.08.2022
Басмадан чыкты: 12.08.2022

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2650 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 5050 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

ЗӘҢГӘР КҮКНЕ САЙЛАУЧЫЛАРГА

Хәтерлисезме, болгавыр 90 нчы елларда шундый реклама бар иде:

– Самолетлар очсын өчен,
сирәк кенә булса да,
аларның моторларын төзәтергә кирәк.
Сез минем белән килешәсезме?
– Әйе!

90 нчы еллардагы рекламада самолетларны кем төзәткәндер – анысын беркем дә хәтерләми. Ә менә матур зәңгәр формалы очучыларның хор белән «Әйе!» дип җавап бирүләре истә калган. Чөнки алар – авиатөзүчеләр, авиаконструкторлар, авиамеханиклардан башка очучы һөнәре бөтенләй булмас иде. Ә без кошлар кебек шәһәрләр һәм илләр, материклар һәм океаннар өстеннән оча алмас идек. Дөнья белән дә таныша алмас идек. Һәм Казанда җәй дә иң яхшы авиашоусыз гына үтәр иде...

Шуңа күрә без бик бәхетле. Август эссе булырга, уңыш бай булырга охшап тора, ә күкне сайлаганнар өчен Казан искиткеч авиация тамашасы әзерли. Бәйрәмне караганнан соң, кулыгызга «Татарстан» журналының август санын алырга һәм безнең шәһәр кемнәр тырышлыгы белән Россиянең канатлы һәм куәтле авиация башкаласына әйләнүен белергә тәкъдим итәбез.

Сезнең зәңгәр күкне яратучы редакциягез.

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **963 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

ТАТАРСТАННЫҢ 100 ҖӘҮҺӘРЕ
БАРЫ ТИК ТАТАРСТАНДА

ТУ-4: СОВЕТ «АМЕРИКАЛЫСЫ»

1947 елның маенда Казанда беренче мәртәбә B-29 Америка очкычының төгәл күчермәсе – Ту-4 стратегик бомбардировщигы һавага күтәрелә. Импортны алыштыру буенча уникаль эксперимент Сталин әмере буенча башкарыла: авиаконструктор Андрей Николаевич Туполевка бу эшләр өчен барлыгы ике ел вакыт бирелә. Сроклар искиткеч кырыс: мондый самолетны күпләп җитештерү өчен сызымнар гына түгел, технологияләр дә таләп ителә. Ә алар СССРда юк, күп кенә материалларның да аналоглары булмый. Бурычны үтәр өчен, яңа фәнни-тикшеренү институтлары, җитештерүләр, тулы бер тармаклар булдырырга туры килә. Башка юл калмый: салкын сугыш шартларында илгә тиз арада атом-төш коралын йөртүче стратегик бомбардировщик кирәк була, үз машинабызны төзү бик күп вакытны алачак. Нәтиҗәдә ике ел җитә, ә үзләштерелгән технологияләр СССР авиациясен яңа дөнья дәрәҗәсенә күтәрә.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр
ТӨП ТЕМА

6. Һавага юл
«Аккошлар» кайда туа

8. Социализм чорының хыялдагы каласы
Казандагы Социалистик шәһәр

20. Максимовларда кунакта
Легендар авиазавод директоры кайда яшәгән

22. Колонналы фатирлар, витражлы подъездлар
Белинский урамындагы яшел йорт

24. Безнең ишегалды бөркетләре
Очучы-сынаучыларның гаиләләре кайда яшәгән

26. Туполев дачасына сәяхәт
Авиаконструкторны Казан белән нәрсә бәйләгән

30. «Көндезге фурияләр» һәм «төн пәриләре» турында
Дошманның котын алган кызлар

34. Пе-2 пикировщигын җыю
«Татарстан канатлары» проекты кай ягы белән уникаль

38. ХһК махсус мәктәбе курсантлары
Алар нинди биеклекләргә ирешкән

42. Самолетларны очарга өйрәтү
Очучы-сынаучылар белән әңгәмә

игелекле эшләр

48. Мәхәббәт аңлату
Кечкенә өяз шәһәре кемгә бик якын

52. Туган як манзарасы
Тәтешлеләр ирешкән уңышлар

мәңгелек кыйммәтләр

66. Россия халыклары мәдәни мирасы елы
Нәрсә ул йола

68. Тарих сәхифәләре
Хөсәен Әмирхан турында

72. Нәзакәтле затлылык
Әҗем мәчете замандашларын кай ягы белән сокландырган

76. Татар авыллары
Келәнче – тарихны торгызу

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Акыллы гамәлләр

21.07

Олег Матыцин, Россия Федерациясе спорт министры, – Казанда «Дуслык уеннарын» ачу көнендә:

– Дуслыкны акча белән санамыйлар, без Россиядә иң зур ярышлар үткәрергә җитәрлек финанс потенциалына ия. Бу Россия Федерациясе Президентының да, Хөкүмәтенең дә позициясе. Финанслау мөһим, әмма бәхет акчада түгел. Бүген без Казанның потенциалын күрәбез, уеннарны бирегә үткәрергә планлаштырабыз. Аларның ел саен уздырылуына да каршылыклар күрмим.

Игелекле эшләр

07.07

Алексей Куртов, сәясәт белгече, Россия сәяси консультантлары ассоциациясе идарәсе әгъзасы (Мәскәү):

– Татарстан һәр кеше өчен дә лаеклы урын табылган модель төзи алды. Монда милләтенә, диненә, һөнәренә яисә туган урынына бәйсез рәвештә кеше үзен уңайлы һәм якланган итеп тойсын өчен бөтен нәрсә эшләнә. Бу бүген һәр төбәк үрнәк алырлык территория. Шул ук вакытта республиканың үзен Россиядән аерып карамавы да бик мөһим.

Мәңгелек кыйммәтләр

17.07

Борис Березовский, пианист, Россиянең атказанган артисты, «Алабуганың җәйге кичләре» фестиваленең сәнгать җитәкчесе:

– Мондый матур урында халык каршында чыгыш ясау – безнең өчен бәхет. Быел чит ил артистлары юк, ләкин мин ватанпәрвәр, һәм без бәхетле булсын өчен барысы да бар, дип саныйм. Бу шул исәптән музыка өлкәсенә дә кагыла. Әлбәттә, киләсе елларга фестиваль әле халыкара дәрәҗәдә булачак. Мин күңелсезләнәмме, юк, алай дип әйтә алмыйм. Бездә талантлы һәм шәп музыкантлар бик күп, шуңа күрә чит ил артистларының булмавы фестивальнең сыйфатында чагылыш тапмый.

Фото: tatar-inform, classicalmusicnews.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

ТӨП ТЕМА

Бу санда тәкъдим итәбез:

Казан **ничек** авиатөзелеш үзәгенә әйләнгән

Хыял шәһәре **кайда** урнашкан

Атом-төш янавын тыеп торучы корал **кайда** җыела

Туполевның онытгының оныгы гаилә бәхетен **нәрсәдә** күрә

«Көндезге фурияләр» һәм «төн пәриләре» **нинди** очкычта очкан

Казан эшчеләре дошманга **нинди** «сәлам» җибәргән

Казанда ХһКнең махсус мәктәбе **кайда** булган

Самолётларны очарга **кем** өйрәтә

ИЛ КАНАТЛАРЫ

Әгәр Казанны Россиянең авиация башкаласы дип атасаң, бу һич тә арттыру булмастыр. Атом-төш янавын тыеп торучы корал – стратегик ракеталар йөртүче очкычлар җыелуы белән тагын кайсы шәһәр горурлана ала? Яисә заманча пассажир лайнерлары, шуларның берсе – дәүләтнең беренче заты өчен тәгаенләнгән 1 номерлы борт булуы белән?

Фото: tupolev.ru

Ярты дөнья диярлек очкан вертолетлар тагын кайсы шәһәрдә җитештерелә? Ниһаять, тәмамлаучылары арасында атаклы Су-27 не уйлап тапкан Михаил Симонов, «Ансат»ның этисе Валерий Карташов, «Сатана» һәм «Энергия» континентара ракеталарын эшләгән Борис Губанов һәм башка меңләгән конструктор һәм инженерлар булган вуз Казанда урнашмый тагын кайда урнашсын?

Казан авиация Олимпында бер генә көн, бер генә ел һәм хәтта бер генә дистә ел да түгел. Барысы да 90 ел элек, шәһәр читендә гаять зур төзелеш җәелдерүдән башлана: ил авиация комбинаты – «Казмашстрой»-га нигез сала. 1932 нче ел Казан авиация заводы өчен дә, инженер кадрлары үзәге – КМТТУ-КАИ өчен дә, авиатөзүчеләр яшәргә тиешле торак массив – Орджоникидзе бистәсе (хәзерге Социалистик шәһәр) өчен дә башлангыч нокта санала.

Ә киләчәктә тагын нәрсәләр була? Өлгергәнлекне сынау, осталык, көндәшлеккә сәләтлелек. Ел саен түгел – көн саен. Һәм үзләре өчен үзләре сөйли торган нәтиҗәләр. Казанда һавага юл алган машиналар гадәттә илебезнең гражданнар һәм хәрби авиациясе флагманнарына әверелә. 1938 елда төзелгән, үз вакыты өчен дөньяда иң зур АНТ-20бис. Дошманның котын алып торган легендар пикировщик Пе-2. Илебезнең беренче атом-төш коралын йөртүче самолёты Ту-4. Ерак арага очучы беренче совет реактив бомбардировщигы Ту-16. Беренче совет реактив пассажир самолёты Ту-104. Безнең беренче континентара пассажир лайнеры Ил-62, күп кенә илләрнең лидерлары дөнья буйлап әлеге самолётта очуны өстен күргән. Ниһаять, үз вакытыннан дистә елларга алданрак пәйда булган безнең «Аккош» – стратегик ракета йөртүче очкыч Ту-160.

Лаеклы тарих – зур эш. Ә иртәгә нәрсә? Лаеклы дәвам булырмы? Гыйнвар аенда Казан күгенә күтәрелгән модернизацияләнгән Ту-160М. Чит илләрнең «боинг» һәм «эрбас»ларын алыштырырга сәләтле Ту-214. Перспективалы ПАК ДА – яңа буын стратегик ракета йөрткеч... Аргументлар шундый, безгә калса, башка бернәрсәне дә исбатлап тору таләп ителми.

«Татарстан» журналының бу санын укып чыгыгыз. Редакция журналистлары булдыра алмастайга: узганны – хәзергедә һәм тарихны бүгенге көндә күрүгә иреште кебек.

Фото: Александр Ефремов, Марина Демидова архивыннан

СОЦИАЛИЗМ ЧОРЫНЫҢ ХЫЯЛДАГЫ КАЛАСЫ

Ольга Туманская

Горбунов исемендәге Казан авиация заводы директоры Николай Савицких белән без Ту-214 авиалайнеры янында очраштык. Дөресрәге, аның «Крылья Советов» паркындагы балаларны сөендереп торган уенчык версиясе янәшәсендә. Шушы урыннан безнең Социалистик шәһәр буйлап сәфәребез башлана, Казан үзәгеннәнерактарак урнашкан бу кечкенә район кайчандыр хыялдагы калага әверелергә тиеш була. «Һәм ул шундый булды да!» – дип саный экскурсоводыбыз булырга бик теләп ризалашкан Савицких.

1920–1930 нчы елларда социалистик шәһәрнең архитектурасы нинди булырга тиешлеге турында бәхәсләргә бик күп алдынгы фикерле кешеләр җәлеп ителә. Казанның Социалистик шәһәрен РСФСР Эчке эшләр халык комиссариаты карамагындагы «Гипрогор» – Шәһәрләрне фотога төшерү, планлаштыру һәм гражданнар корылмаларын проектлаштыру дәүләт институты белгечләре проектлаган. Биредәге торак йортларның архитектурасы төрле планда башкарылуы белән таң калдыра: мәһабәт, зур «сталинка»лар да, күренекле архитекторларның проектлары буенча эшләнгән, күңелгә җылылык биреп торучы өч катлы йортлар да бар. Тормыш өчен кирәк бөтен нәрсә – кул сузымында гына.

Социалистик шәһәр мохитенең уйлап эшләнгән планировкасы, җыйнаклыгы һәм уңайлылыгы хәтта бүгенге көн таләпләренә дә туры килә алырлык. Алар шундый булып калачак та: 2018 елда микрорайонга берьюлы ике – истәлекле урын һәм мәдәни мирас объекты статусы бирелгән.

КАНАТЛАРЫН ҖӘЙГӘН ПАРК

Без «Крылья Советов» паркы – «хыялдагы кала» оазисында! Кайчандыр әлеге юллардан Сергей Королев һәм Валентин Глушко йөргән.

Сугышка кадәрге елларда бу паркта тормыш кайнап торган! Заводның чаңгы базасы һәм шугалагы булган, яшьләр парашют каланчасы янына ашыккан.

Әлбәттә, аларга мондый мөмкинлек ирекә чыкканнан соң гына тәти. Сугыш елларында әле бу атаклы конструкторлар халык телендә «шарашка» дип йөртелгән ОКБ-16 махсус конструкторлык бюросы тоткыннары була, анда реактив двигатель уйлап табу белән шөгыльләнә…

– Сугышка кадәрге елларда бу паркта тормыш ничек кайнап торганын күз алдыгызга китерегез әле! – дип башлый сүзен Николай Владимирович. – Заводның чаңгы базасы һәм шугалагы булган, яшьләрне парашют каланчасы үзенә тартып торган…

Агачларының күләгәсе кояш нурларыннан саклый торган, елның һәр фасылында матур булган парк бүген дә илһамландырырга сәләтле. Бигрәк тә реконструкциядән соң. Сүз уңаеннан, «Крылья Советов» сүзтезмәсендәге «канатлар» паркның формасын да белдерә. Һәрхәлдә, башта, 1939 елда, парк нәкъ менә канат рәвешендә булган.

Казандагы иң мәһабәт Ленин һәйкәлләренең берсе торган үзәк аллеягә чыгабыз. Күләгә астындагы эскәмиягә утырып, Ильичны күзәтәбез. Юлбашчының басып тору рәвеше үзенчәлекле: бер кулы кесәсендә, икенчесе бераз өскә күтәрелгән.

– Сүз уңаеннан, менә бу урында кайчандыр Михаил Симонов ял итәргә яраткан, – ди Савицких. – Дөньяда беренче булып Төньяк полюста авыр самолётны утырта алган атаклы очучы ул!

Бөек Ватан сугышы елларында Симонов өч йөзгә якын сугышчан очыш ясый. Берничә тапкыр дошман уты астында кала, тик ул һәрвакыт аэродромга исән-имин әйләнеп кайта… Ә безнең завод Михаил Васильевич өчен иң якын урынга әверелә – сугыштан соң ул унике ел биредә чыгарыла торган самолёт модельләрен сынау белән мәшгуль була.

ШАТЛЫК ТА, ГОРУРЛЫК ТА, КАЙГЫ-ХӘСРӘТ ТӘ…

Ак мәрмәр идән, колонна һәм баскычлар, ә эчтә – кызыл имән паркет… Без Ленин исемендәге мәдәният сараенда йөрибез. Совет чорындагы зиннәтлелек – башка сүз дә табып булмый. Сызым эшләре 1950 елда башлана, 1961 елда бина файдалануга тапшырыла, аны Казанның Сталин ампиры стилендә төзелгән зур җәмәгать объектларыннан иң соңгысы дип атарга мөмкин. Бүген бу мәһабәт Мәдәният сарае мәдәни мирас объекты санала.

Моннан биш ел элек биредә зур реставрация эшләре башкарыла, реставраторлар үз эшлә-

Горбунов исемендәге Казан авиация заводы директоры Николай Савицких бик рәхәтләнеп редакциябез өчен экскурсия үткәрергә ризалашты.



– Аны Бөек Пётр дип йөрткәннәр – Дементьев чын авиация империясен төзүгә ирешкән: дөньяда һәр бишенче самолёт Советлар Союзында эшләнгән булган, – дип сөйли Николай Савицких.

ренә бик сак карый. Планировкасы тарихи рәвешендә кала, залларның гомуми күренеше дә күпчелек дәрәҗәдә саклана, вакыт җилләре шактый таушалткан имән паркетны гына алыштырырга туры килә. Нәкъ шундыйга.

Театр залы, кинотеатр, ике катлы китапханә – болар барысы да завод эшчеләренең мәдәни ялын күздә тотып ачылган. Бирегә совет эстрадасы йолдызлары килә, авиация заводының дан тоткан күренекле иҗат коллективлары концертлар күрсәтә. Монда төрле зур бәйрәмнәрне билгеләп үтәләр, Яңа елны каршы алалар. Директор Виталий Копылов заманында, аның шәхси күрсәтмәсе нигезендә, Мәдәният сараендагы табынга дефицит шампан шәрабе, мандарин һәм башка тәм-томнар алып кайтыр өчен, 31 декабрь алдыннан Казаннан Мәскәүгә махсус рейс җибәрелгән, дип сөйлиләр.

Әмма бу диварлар якты истәлекләр белән бергә, кайгылы көннәр турындагы хатирәләрне дә саклый. 1961 елның 20 июнендә Ту-16 самолётының сынау очышы вакытында алты кешедән торган экипаж һәлак була, алар арасында чын легендалар – очучы-сынаучы Әнвәр Кәримов, штурман-сынаучы Василий Демидов була. Мәңгелеккә очып киткән ирегетләрне соңгы юлга шушы Мәдәният сараеннан озаталар. Бирегә сакланган фотода хезмәттәшләре һәм дуслары белән хушлашырга килгән меңләгән кешене күрә алабыз.

Мәдәният сарае каршындагы мәйданны Социалистик шәһәрнең иң күренекле урыннарыннан берсе дип атарга була. Биредә биек гранит постаментта авиация сәнәгатенең тагын бер легендасы – СССР авиация сәнәгате министры, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое, тугыз тапкыр Ленин ордены кавалеры Пётр Дементьевның бронза бюсты урнаштырылган...

– Аны Бөек Пётр дип йөрткәннәр – Дементьев чын авиация империясе төзүгә ирешкән: аның чагында дөньяда һәр бишенче самолёт Советлар Союзында эшләнгән булган, – дип сөйли Николай Владимирович. – Сүз уңаеннан, Пётр Васильевич – чыгышы белән Татарстан кешесе, Чүпрәле районының Үби авылында туган. Бу факт аның безнең заводка карата кайгыртучан мөнәсәбәтендә берәр нинди роль уйнагানмы, анысы билгесез. Тик шунысы хак: Ту-160 стратегик бомбардировщигын җитештерүне җайга салачак завод турында карар кабул итү нәкъ менә Дементьевка бәйле була. Һәм ул Казанны сайлый.

СОҢГЫ КЫЗЫЛ ДИРЕКТОР

Ә юл аркылы Дементьевка тагын бер легендар шәхес – Виталий Копылов «карап тора». Горельеф «авиация сәнәгатенең күренекле оештыручысы» хөрмәтенә аталган урамга урнаштырылган. Якынрак килеп карыйбыз. Истәлек тактасында кырыс йөзле кеше сурәтләнгән: иреннәре кысылган, кашлары җыерылган, уйчан акыллы күзләре әйтерсең һәр нәрсәнең асылына үтеп керергә тырыша...

1973 елда яңа директорны Комсомольск-на-Амуре каласыннан Дементьев үзе алып кайта. «Мин тайгада үскән егет. Эшләргә дип килдем һәм сезнең ышанычны акларга тырышачакмын», – Копыловның коллектив алдында беренче чыгышы әнә шундый була. Күп тә үтми, ул Казанда иң абруйлы кешеләрнең берсенә әверелә.

– Копыловны заводта «Уссури юлбарысы» дип йөрткәннәр, шул исәптән холкының ныклыгы өчен дә, әлбәттә, – дип сөйли Николай Савицких. – Торгынлыклы 1970–1980 нче еллар Виталий Егорович тырышлыгы белән безнең предприятие өчен интенсив үсеш һәм иҗат чорына әйләнә. Асылда, аның территориясендә яңа завод үсеп чыга. Копылов чорында тавыш тизлегеннән югарырак тизлектә очарга сәләтле Ту-160 стратегик бомбардировщикларын сериялап җитештерү башлана. Ерак арага оча торган Ил-62 гражданнар самолётларын җитештерү җайга салына, алар нигезендә 1 нче номерлы борт функциясен башкарган самолётлар җыела.

Шундый ук глобаль үзгәрешләр социаль өлкәгә дә кагыла.

...Кайда гына булса да, завод хезмәткәрләрен кабул итә торган көнне Копылов бил-



«Уссури юлбарысы» Виталий Копылов. Торгынлыклы 1970–1980 нче еллар аның тырышлыгы белән КАЖБ өчен интенсив үсеш һәм иҗат чорына әйләнә.

гелəнгəн вакытка һичшиксез кайтып җитә иде, дип сөйлиләр. Иң мөһим бурычларның берсе – торак мәсьәләсен хәл итү. Виталий Егорович вакытында завод эшчеләре өчен ел саен 30 мең квадрат метрга кадәр торак файдалануга тапшырыла башлый! Нәкъ менә аның башлангычы белән йортлар төзү комбинаты оештырыла.

Лукин урамында Казанның беренче 16 катлы йортын төзүне Копылов шәхсән үзе җитәкли. Ул чорда яшәгәннәр искә алганча, йортны тапшыргач, директор шулхәтле сөенә ки, хәтта биеп җибәрә, әнә шул чакта аны барысы да «шат күңелле һәм яшь итеп» күрә...

Маршрутыбыз уза торган Копылов урамы, 5 нче йортны совет чорының соңгы директорына истәлек тактасы куяр өчен очраклы гына сайламаганнар. Бу өй 1950 нче еллар башында ук төзелгән, ләкин аны бүген дә, һичшиксез, Социалистик шәһәрнең йөзе дип атарга була. Йорт архитектурасы гаять үзенчәлекле һәм бик саллы. Горельеф урнаштырылган почмак өлеше җиде катлы башнядан гыйбарәт, ул түбәсендә терраса һәм колонналары булган биек шпиль белән бизәлгән.

Совет елларында биредә кунакханә урнашкан була. Казанга килгәч, ике балалы Копыловлар гаиләсе, шундагы казна бүлмәләренә күченеп, шактый озак яшәгән, диләр. Виталий Егорович, еллар буе яңа фатир көткән хезмәткәрләрне узып, завод фондыннан фатир алудан баш тарткан.

МОНДА КОРОЛЁВ ЯШӘГӘН!

Тар гына юл безне кирәкле подъездга алып килә. Күтәртелебрәк ясалган ишек төбендә – каеннар. Лядов урамындагы 5 нче йортта яшәгән күренекле шәхесләрне монда инде бернәрсә дә хәтерләтми. Өйнең ян тарафындагы истәлек тактасын санамаганда, әлбәттә. «1944–1946 елларда бу йортта танылган конструктор, совет ракета-космос техникасын уйлап табучы Сергей Павлович Королев яшәгән», дип хәбәр итә ул.

– Казанда ул күптән көтелгән иреккә чыгуга ирешә – ОКБ-16 «шарашка»сының башка тоткыннары белән бергә 1944 елның июлендә вакытыннан алда азат ителә. Әлеге «шарашка»да Валентин Глушко җитәкчелегендә реактив ракета двигателе ясау белән шөгыльләнәләр, – дип аңлата Николай Савицких.

Алтынчы подъезд. Баскыч буйлап бишенче катка күтәреләбез. Биредә дүрт фатир, безгә сулдагысы кирәк. Королёв яшәгән ике бүлмәле фатир буш тора, диләр. Сүз уңаеннан, Валентин Глушко шушы катта ук яшәгән, Королёвның күршесе булган. 1944 елда бөтен подъездны элекке «шарашка» тоткыннарына биргәннәр. Кайсы гына исемне атама – барысы да даһи, күренекле шәхесләр.

Королёв фатиры тәрәзәсеннән күренгән манзара – балалар бакчасы, каршыдагы йорт аркасы, дистә еллар узса да, үзгәрмәгән диярлек. Тәрәзә каршындагы биек каенны

Лядов урамы, 5 нче йорт, 100 нче фатир – биредә Королёв яшәгән!



гына кисҡәннәр. Тик бу безгә иртәнге якты нур белән тулган иркен бүлмәне күзалларга комачаулыймы соң? Шулкадәр кояшлы фатир! Җиһазлану ягыннан шактый тыйнак булган ул: караватт, эскәтер урынына урын-җир җәймәсе җәелгән аш өстәле, язу өстәле, берике табурет, тумбочка. Кирәк-яраклардан – өч пыяла банка, ике шешә, кружка һәм чәй кашыгы. Менә бөтен байлык шул! «Минем үземә дә көлке. Тик мин кайгырмыйм... Бу бит тормышта иң мөһиме түгел, һәм, гомумән, болар барысы да вак-төяк кенә», – дип язган Королёв туганнарына үзенең, ниһаять, ирекле тормышы турында.

Әйе, ирегә шактый шартлы булса да, монда ул бәхеткә тиенә. Ник шартлы дигәндә, паспорт урынына кулына азат ителү турында белешмә генә тоттырыла. Сайлауларда һәм демонстрацияләрдә катнашу мөмкинлеге урынына – хокукларда чикләнү һәм атна саен Черек күлгә барып билгеләнеп кайту. Каторга һәм махсус төрмәдәге тормыштан, махсус конструкторлык бюросында 15–18 сәгатьлек хезмәт көненнән соң Лядов урамындагы фатирында ул ялгызлыктан сүзнең туры мәгънәсендә ләззәт ала. «Кайтам да кичке ашка берәр җиңел генә нәрсә әзерлим, ә аннары караватка сузылып ятам да, үзем дә сизмичә, уйлый-уйлый йокыга талам. Бик рәхәт!» – дип яза ул әнисенә. «Мин элек (сугышка кадәр) дөньяның гүзәллеген тоймый идем, ә хәзер мин кояш нурының да, бер йотым саф һаваның да, кипкән икмәк катысының да кадерен беләм».

Королёв гомере буе шундый булып калачак. Ул беркайчан да көнкүрештәге авырлыкларга зарланмаган, бернәрсә дә җыймаган, матди байлыкка исе китмәгән. Чөнки аның кулында күпкә мөһимрәк, кыйммәтлерәк әйберләр булган. Әйтик, баллистик ракета һәм ракетоплан ясау өчен беренче сызымнар һәм исәпләүләр, аларны ул шушы кояшлы бүлмәдә эшли башлый һәм Казаннан киткәндә үзе белән ала.

Социалистик шәһәрнең уйлап эшләнгән планировкасы, җыйнаклыгы һәм уңайлылыгы хәтта бүгенге көн таләпләренә дә туры килә алырлык.

Өченче каттагы ике балконлы фатирда очучы-сынаучы Александр Васильченко яшәгән.

ЯШЕРЕН ОЧУЧЫ

Белинский урамындагы кечкенә скверда эсселек бөтенләй сизелми. Эскәмияләр, җәяүле сукмаклары һәм эшләми торган фонтан – сугыштан соң җәйләнгән тормыш-көнкүреш истәлекләре.

– Бу скверга башка бер кызыклы фатир тәрәзәләре карый, – дип сөйли Николай Владимирович. – Анда Советлар Союзы Герое, танылган очучы-сынаучы Александр Васильченко яшәгән. Сугыш башланган көннән бирле Александр Григорьевич фронтка Пе-2 бомбардировщикларын илтә торган авиация эскадрильясы белән җитәкчелек итә. Ә 1943 елның маеннан ул безнең заводта самолётлар сыный башлый.

Васильченконың фатирын табу бик җиңел булып чыкты: сигезенче йорт, өченче кат. Андый фатирлар икәү генә, аларны балконнарыннан аерып була. Француз балконы кухнядан чыга торган, зуррагына залдан чыгасың. Ул вакыт өчен бик шәп планировкалы фатир аның хуҗаларына зур казанышлары өчен бирелгән. Бу тәрәзәләргә карауга ук, ак эскәтерле өстәл, бәйләнгән челтәр салфеткалар, буфетта тезелгән савыт-саба күз алдына килә...

Хәер, күрше йортларда яшәгән кешеләр сөйләгән истәлекләр дә бар. Менә алар, ул чакта бер көтү бала-чага, арка ягына җыелып, кумирларын көтә. Һәм шулчак ул үзе дә күренә – көндәлек тормышта бик мәзәкчән, шук ир-ат ишегалдына кәттә «Победа» машинасында килеп керә. Малайларны күргәч туктый. Аларга исә ике мәртәбә әйтеп торасы юк – шундук машинага төяләләр. Васильченко аларны аэропорт буфетына алып бара – ярымач йөргән урам балаларын тамаклары туйганчы сыйлый.

Аны яраталар, аңа сокланалар. Туганнары, дуслары һәм күршеләре генә түгел. Мөгаен, иң беренче чиратта, хезмәттәшләредер. Алар

арасында инженер Сергеев та бар, Васильченко белән аны бер истәлекле вакыйга бәйләп тора.

...Пе-2 бомбардировщигы. Самолётның койрыгына РД-1 сыек реактив двигательле тизләтү җайланмасы урнаштырылган – ул тизлекне шундук 200 километрга арттырырга сәләтле. Фашистларның котын алачак бу нәрсәне НКВДның ябык конструкторлык бюросы – шул «шарашка» тоткыннары уйлап таба. Чираттагы сынау очышларының берсе. Штурвалда – Александр Васильченко, янәшәдә – тоткын, инженер-экспериментатор – конструкторлык бюросы конструкторы Сергеев. Очыш гадәттәгечә дәвам итә, әмма 7 мең метр биеклектә койрык өлешенә ут каба. Ялкын бик тиз кабинага үрмәли. «Сикер!» – дип кычкыра пилот инженерга. Сергеев баш тарта – аңа авариянең сәбәбен ачыкларга кирәк. Васильченко янып торган машинаны могҗиза белән җиргә төшереп утыртырга өлгерә. Икесе дә шактый пешә.

Ул вакытта Васильченко кемне коткаруын аңлаган микән? Сергеев фамилиясендә киләчәктә космосны яулаячак легендар конструктор Сергей Павлович Королёв йөргән була.

СССРның 30 нчы еллардагы легендар авыр сәнәгать халык комиссары Сергей Орджоникидзенең илебездә сакланып калган сирәк һәйкәлләреннән берсе.

КОБА? СЕРГО!

Маршрутыбызның соңгы ноктасы да, мөгаен, беренчесе кебек үк кызыклы һәм үзенчәлекледер. Аңа алып баручы юл да... Түшәме кессоннар белән бизәлгән биек арка аша узабыз – адресы Белинский урамы, 5 булган ар-деко стилендәге биш катлы йорт 1938 елда төзелгән. Үз вакыты өчен артык модалы һәм затлы йортны архитекторлар бу тирәнең доминантасы итеп планлаштыра, ул авиазавод инженерлары һәм техник хезмәткәрләренә уңайлы тормыш шартлары тудыру максатын күздә тота.

Бу микрорайондагы торак йорт ансамбльләре аерым бер конфигурациягә ия – проектлаучылар аларда иркенлек һәм уңайлы җыйнаклыкны берләштерүгә ирешә. Без моны үзебез дә күрәбез – безгә кирәкле торак квартал ишегалдында зур сквер! Биредә дә үз архитектура доминантасы бар – Серго Орджоникидзе һәйкәле.

«Казанда «халыклар юлбашчысы» Иосиф Сталинга бердәнбер һәйкәл сакланып калган», – дип язган иде күптән түгел аның турында кайбер гаммәви мәгълүмат чаралары. Янәсе, соңрак, идеология үзгәргәнгә күрә һәм шәхес культына каршы көрәш максатларында, монументка тиз генә Серго исемен биреп куйганнар. Өстәвенә, авыр сәнәгать халык комиссарын тышкы кыяфәте буенча Иосифтан аеру шактый катлаулы, таш һәйкәл рәвешендә инде әйтәсе дә юк..

– Бу уйдырма гына, – дип шикләрне тарата Николай Савицких. – Сезнең каршыда Серго Орджоникидзе һәйкәле, һәм ул башта ук шулай итеп уйланылган була. Монументны сүтеп реставрациягә алып киткәч, монда яшәүчеләр шулкадәр борчылды! Әмма, күргәнегезчә, бүген ул үзенең тарихи урынында.

Сүз уңаеннан, СССРның 30 нчы еллардагы легендар авыр сәнәгать халык комиссары хөрмәтенә куелган сыннарның илдә бик азы гына сакланып калган. Социалистик шәһәрдәге һәйкәл – шуларның берсе. Монумент авторының исеме һәм аның иҗат ителү елы тарих төпкелендә яшеренгән. Ә менә аның биредә – хыял каласындагы күләгәле скверда пәйда булуы билгеле.

...90 ел элек, 1932 елда, Казаннан ерак түгел бишьеллыкның удар төзелеше старт ала. Сәнәгать комплексын кеше ышанмаслык тиз арада – ике ел эчендә сафка бастыралар. Ә тагын бер елдан соң, 1935 елда, яңа предприятиенең беренче самолёты – спорт ярышлары һәм укуөйрәтү өчен кулланыла торган КАИ-1 очкычы күккә күтәрелә. Бу әле зур тарихның башы гына була! Яңа заводка 124 нче номер һәм Орджоникидзе исеме бирелә. Әш шунда ки, халык комиссары бу эштә ярдәм генә күрсәтеп калмыйча, заводны да, Социалистик шәһәрне дә колачлаган бинидаһа зур төзелешне тулысынча үзе күзәтеп, тикшереп тора. Сүз уңаеннан, әлегә кадәр рәсми документларда ул Серго Орджоникидзе исемендәге бистә дип исәпләнә. Дөрес, бу хакта бик азлар гына белә.

Николай Савицких белән сәяхәтебез ахырына якынлаша. Кечкенә генә Социалистик шәһәрне берничә сәгать эчендә генә йөреп бетереп булмый икән. Казанның нибары берничә гектарын гына тәшкил итсә дә, монда күпме тиңсез архитектура һәйкәлләре, истәлекле тарихи урыннар, күренекле кешеләр турында хатирәләр саклана.

ҺАВАЛАРДА – «АККОШ»!

Фото: Александр Ефремов, КАЗ матбугат үзәгеннән алынды

Ксения Сёмина

Фюзеляж, канатлар, койрыкның яшел саклагыч грунтовка белән капланган өлешләре цехта өр-яңа гигант конструктор детальләре кебек пөхтәләп таратып куелган. «Татарстан» – Казан авиация заводының җыю цехында.

Панельләр җыелмаларга, җыелмалар – агрегатларга, стапельләрдәге агрегатлар самолет конструкциясе элементларына тоташтырыла. Җыю цехына меңнәрчә деталь керә дә, аннан тулысынча диярлек җыелган Ту-214 самолетына (мөгаен, бу хәзер Россиядәге иң перспективалы пассажир очкычыдыр) әйләнеп чыга.

ПАССАЖИРЛАР ӨЧЕН

Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе планнары буенча, Казан авиация заводы (КАЗ) стапельләреннән 2030 елга кадәр ерак араларга оча торган 70 Ту-214 пассажир самолеты төшәргә тиеш.
Чит илләрдән кертелә торган пассажирлар авиатехникасы паркын глобаль алыштыру кебек мөһим миссия өчен Казан авиация заводы («Туполев» ГАҖ филиалы, Ростех ДК «Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе» ГАҖ составына керә) очраклы гына сайлап алынмаган. Татарстан җитәкчелеге тырышлыгы нәтиҗәсендә әлеге завод – 2000 нче еллар башыннан бирле гражданнар самолетлары җитештерү туктатылмаган илдәге бердәнбер диярлек

предприятие. Ту-214 планеры һәрвакыт биредә җитештерелгән. 20 ел эчендә КАЗ дәүләт максатлары өчен махсус билгеләнештәге Ту-214 самолетларының тулы бер паркын чыгарган.

– Без традицион стапельләрдә җыюны саклап калдык, бүген ул үзен тулысынча аклый. Шул ук вакытта Ту-214 очкычының модификацияләре күптөрле. Без елына өч самолет чыгара идек, әмма җитештерү күләмен әкренләп арттырырга җыенабыз – эшкәртү җиһазлары, агрегатларны параллель әзерләү өчен стапельләр өстәләчәк, ә яңа технологияләр җыюны тизләтергә булышачак. Ихтимал, бурычларның бер өлеше аутсорингка тапшырылыр, – дип сөйли Конструкторлык хезмәте күрсәтүне оештыру буенча конструкторлык бюросы директоры урынбасары Максим Кондратьев.

Ул безнең өчен цех буйлап экскурсия үткәрә. Икенче залда – коеп ясалган бик зур «гармошка», самолетның үзәк балкасының яртысы. Алга таба барлык җаваплы узелларның җыелу сыйфаты җентекләп тикшерелә.

– Без төп узеллардан файдалану вакытын 50 елга җиткерергә омтылабыз, – ди Максим Кондратьев.

Сүз уңаеннан, Ту-214 тулысынча диярлек Россия машинасы, чит ил детальләре баштан ук бик аз кулланылган.

Россия транспорт министры Виталий Савельев Ту-214 самолетын база моделе, дип атады, илнең эйдәп баручы авиакомпанияләре шуңа күчүне планлаштыра. Очкычның кайбер характеристикалары аны тышкы базарда да көндәшлеккә сәләтле итәрлек. Ул җирдә шаулау тавышы һәм атмосферага зыянлы матдәләр эмиссиясе буенча халыкара таләпләргә тулысынча җавап бирә, шундый ук класстагы чит ил судноларына караганда ерагракка оча ала, өстәмә ягулык баклары куелганда, тагын да ераграк очу мөмкинлеге дә бар. Максималь очып китү авырлыгы – 110 тонна. 4000 км чамасы ераклыкка очканда Ту-214 самолеты пассажир кәнәфиеннән файдалану чыгымнары аның турыдан-туры конкурентлары белән чагыштырганда кимрәк.

Бу казанышлар, әлбәттә, сөендерерлек. Шулай да Казан авиация заводы «пассажирлар» юнәлешендә генә эшләми әле.

Мондый нәтиҗәгә ирешү мөмкинлеге җыю белән шөгыльләнүче белгечләрнең квалификациясенә бәйле. Бәхеткә, завод үз штатында тәҗрибәле мастерларны саклап кала алган, алар үз эшләрен сыйфатлы башкарып кына калмый, яшь белгечләрне дә өйрәтергә сәләтле. Җыю цехына эшкә, мәсәлән, Казан авиация техникумыннан соң урнашырга мөмкин. Заводның җитештерү планнарын күздә тотканда, биредә һәр яшь профессионалның үсеше өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар.

Хәзер КАЗ өчен материаллар һәм кирәкле детальләр Россиядәге йөздән артык предприятиедән китерелә. Кулланыштагы машиналарда детальләр әкренләп үзебезнең илдә җитештерелгәннәренә алмаштырыла.

«АККОШ»НЫҢ ТИТАН БӘПКӘЛӘРЕ

«Советлардан соңгы авиация сәнәгате тарихында моңарчы күрелмәгән гаять зур проект», – Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе (БАК) генераль директоры Юрий Слюсарь 2016 елда Казан авиация заводында Ту-160 самолетын модернизацияләү башлануны шулай шәрехләгән иде.

Нәзакәтлелеге һәм купшылыгы өчен «Аккош» дип йөртелә башлаган, канат геометриясе үзгәрүчән, тавыш тизлегеннән югарырак тизлектә очарга сәләтле континентара стратегик Ту-160 ракета йөртүче иң беренче

бомбардировщик үзенең Казандагы бишегеннән 1984 елда очып чыга. Казан заводы әлеге машиналарны чыгаруын дәвам итә. «Аккош»лар һәм «Аю»лар (Ту-95МС турбовинтлы стратегик ракета йөртүче бомбардировщик) Россия Һава-космос көчләре (ҺКК) Ерак авиациясенең авангардын тәшкил итә.

1990 нчы елларда Ту-160 чыгарылудан туктый. Гамәлдәге машиналар илнең ҺККдә хезмәттә кала һәм даими камилләштерелә, әмма аларны җитештерү зарурлыгы хакында бәхәсләр бер дә тынмый. Проектның язмышы 2015 елда хәл ителә: РФ Оборона министрлыгы Казанда «Аккош»ларны җитештерүне торгызу турында карар кабул итә. Самолетның үзен генә түгел, аның белән бәйле җитештерүләрне дә модернизацияләү таләп ителә. Беренче чиратта – бомбардировщик конструкциясенең 40 процентка якынын (шул исәптән аның «сыртын») тәшкил иткән титан элементларны эретеп ябыштыру цехын. Юкка чыга язган вакуумлы эретеп ябыштыру технологиясен яңартырга туры килә, һәм хәзер Казан авиация заводы дөньядагы иң зур һәм иң куәтле электрон-нурлы эретеп ябыштыру җайланмасына ия.

Элеккегеләргә нигезләнеп төзелгән яңа стратегик Ту-160 «Петр Дейнекин» бомбардировщигының беренче очышы 2018 елның гыйнварында Россия Президенты Владимир Путин катнашында була. Ту-160

стратегик ракета йөрткечләрен җитештерү турында килешү имзалана. Аннан соң ракета йөрткеч, фактта, яңа төрдәге машинага әйләнә.

«Без Ту-160 очкычын җитештерүнең тулы циклын торгызыдык, әмма инде «М» модификациясендә – модернизацияләнгән двигательләрне, самолет белән идарә итү, навигация һәм кораллар белән идарә итүнең модернизацияләнгән системаларын файдаланып», – дип белдерде 2022 елда РФ сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров.

Самолетның тышкы кыяфәте сакланып калган, ә «эчлеген» 80 процентка, ягъни тулысынча диярлек яңартканнар. Өстәвенә, Ту-160М яңа радиолокация станциясе, элемтә һәм навигация комплекты, радиоэлектрон көрәш комплексы, авионика һәм яңа кораллар белән җиһазландырылган. Машинаның очу ераклыгы арткан. Модернизация процессында цифрлаштырылган конструкторлык документациясенең уникаль базасы булдырылган.

Инде Ту-160М самолетының тәүге очышы Казанда быел гыйнварда булган. «Аккош» «бәпкәсе» 600 метр биеклеккә күтәрелгән. Очучы-сынаучылар, берничә маневр ясап, тавыштан тизрәк очучы, дөньяда иң куәтле «кош»ның һавада никадәр тотрыклы һәм идарә ителүчән булуын күрсәткән. Ту-160 һәм ерак-ка оча торган күп режимлы Ту-22М3 ракета йөртүче бомбардировщик (ул да Казан авиа-ция заводында модернизацияләнә) Россия Федерациясе атом-төш триадасы составына керә. Сүз уңаеннан, Ту-160 самолеты 44 дөнья рекорды куйган машина. Иң соңгысы – тавыш тизлегеннән дә югарырак тизлектәге стратегик ракета йөрткечләр арасында иң ерак һәм иң озак очуга карый.

Ту-160М очкычларын сериялэп җитештерү проектының потенциалы бәһаләп бетергесез. Яңа бомбардировщиклар җитештерү бө-тен илдәге профильле югары технологияле йөзләгән предприятиегә яңа тормыш биреп кенә калмыйча, Россиядәге оборона техно-логияләре үсешен искиткеч югары дәрәҗәгә күтәрергә мөмкин. Казан авиация заводы моңа үзенең лаеклы өлешен кертә. Предприятиенең үз җиңүе әле тагын шунда да: КАЗ, илнең өр-яңа тарихында беренче буларак, тармактагы иң кискен ике проблеманы контрольдә тотуга ирешкән: технологияләр һәм кадрлар кытлы-гын. Заводның яңа данлы тарихына тәүге адым ясалган инде.

МАКСИМОВЛАР ЙОРТЫНДА

Ольга Туманская

«Авиациядә вак-төякләр юк!» дигән сүзләрне 1960 нчы еллардагы Казан авиация заводы директоры Максимов әйткән, диләр. Аның өчен, чыннан да, вак-төякләр булмый – эштә дә, өйдә дә. Соңгысына без директор йортына баргач инандык: Николай Ивановичның шәхси әйберләре, шул вакыттагы бүлмәләр якыннары тарафыннан ул үзе исән чагындагы кебек саклана икән.

Декабристлар урамындагы безгә кирәкле йорт Андрей Туполев һәйкәле белән бәйле. Хәер, аларны, чыннан да, аерым бер «туганлык» бәйләп тора – совет авиаконструкторына һәйкәл ачуны Максимовның улы Леонид Николаевич тәкъдим итә. Ул бүген дә хатыны белән этисенең йортында яши.

ЧҮКЕЧЛЕ КЕШЕ

– Безнең бистә сугыш ахырында әсир немецлар тарафыннан төзелгән, аңа кадәр биредә ташландык урын гына түгел, чүплек оясы булган, – дип сөйли безгә йорт тарихы турында Максимовның килене Светлана Борисовна. – Иске рельслар, төрле тимер-томыр калдыклары, шлак өемнәре! Аннары, монда күчкәч, йорт яны участогын буш вакытында Николай Иванович улы белән бергә үз куллары белән чистартты – җиргә төшеп җитәр өчен генә дә метр ярым калынлыктагы чүп-чардан котылырга кирәк иде.

Йорт янын матурлау өчен кулына көрәк тә, чүкеч тә тотарга туры килә директорга.

Бу йортны Максимовка 1945 елда бирәләр. Берничә йорт арасыннан үзе сайлап ала. Нәрсә өчен? Гаять зур хезмәтләре өчен.

Сүз уңаеннан, Николай Ивановичны чүкеч белән йорт эшләре генә бәйләми. Бер очрак шау-шу уята, аны журналистлар «Максимовның батырлыгы» дип атый. Сугыш вакытында ул цеха контроль бюросы башлыгы була, бервакыт фронтка җибәрергә әзер самолетларны кырып диярлек ташлый. Әлеге гамәл өчен – күп тә түгел, аз да түгел – атарга мөмкиннәр. Тикшерә башлыйлар. «Мондый җитешсезлекләргә юл куярга ярамый», – дип катгый җавап бирә Максимов барлык гаепләүләргә каршы. Һәм ул хаклы булып чыга да. Сугыш елларында да, аннан соң да – гомере буе эшен җиренә җиткереп эшләмәүчеләргә каршы көрәшә. «Син заводта булганда, мин тыныч йоклый идем!» – дия торган була аңа авыр сугыш елларында заводны җитәкләгән Василий Окулов.

МУЗЫКАГА МӘХӘББӘТ...

Кунак бүлмәсе түрендә – иске «Красный Октябрь» фортепианосы. Диварга инде бакыйлыкка күчкән туганнарның фотосурәтләре эленгән. Иң өске фотода – Николай Максимов. Янәшәдә – аның әти-әнисе, кыз туганнары...

Фото: Александр Ефремов



– Бу бик иҗади гаилә иде. Гаилә башлыгы Иван Гаврилович Казан тимер юл станциясе башлыгы вазыйфасын башкарган. Нәкъ менә ул бөтен балаларын да рояльдә уйнарга өйрәткән, һәм балалары моның өчен аңа гомерләре буе рәхмәтле булды. Бу йортта музыка һәр көн яңгырый торган була.

1934 елда совет экраннарына «Веселые ребята» фильмы чыга. Николай Максимов фильмны карауга, ноталарын таба һәм әлеге дәртле, бүгенге тел белән әйткәндә, саундтрекны өйрәнә. Менә ул Максимов кулы белән «салмак», «тиз» дип билгеләп куелган иске нота дәфтәре битләре. Һәм инде аның арып өйгә кайтуын, кичке аштан соң кунак бүлмәсендәге кәнәфиенә килеп утыруын күз алдына китерергә дә була. Ярты сәгать хәл җыеп ала һәм инструмент янына утыра...



Ул чорның телсез шаһитлары: стенка, әле бүген дә сафтан чыкмаган иске мич – барысы да хәзергәчә бүлмәне бизәп тора. Бары тик кайчагында егерме бишләп (!) кешене сыйдырган зур өстәлне генә кечерәкне алыштырган.

– Бу йорт һәрвакыт кунакчыл булды, – дип искә ала Светлана Борисовна. – Җыр, мәзәк, дусларча аралашу: эштә кырыс, җитди күренгән Николай Иванович еш кына мондый очрашуларда, балыкка, ауга йөрүләрдә үзенә ял таба иде. Ул матур итеп сөйли белде, мәзәк яратты, яхшы җырлый, бии иде. Су өстендәге ресторанда завод тарафыннан оештырылган кичәне икебезнең бал биюе белән ачып җибәрүебез бүгенгедәй хәтеремдә әле.

Күрше бүлмәгә күз салабыз. Кайчандыр анда Максимовның шәхси китапханәсе булган. Бөтен стена буйлап китап киштәләре сузылган. Классикадан тыш биредә хуҗа яратып укыган тарихи әдәбиятны һәм, әлбәттә инде, күренекле композиторларның биографияләре турындагы китапларны табарга була...

ӨЙДӘ УҢАЙЛЫЛЫК ЯСАУ

Бервакыт танылган авиаконструктор Владимир Петляков самолетның сыйфатына карата ул чакта әле контролер булган Максимовның дәгъвасын ишетә. «Ташла бу эшеңне! Синнән менә дигән конструктор чыгачак», – ди ул аңа. Чыннан да Максимовта инженерлык сәләте дә көчле була. Сүз уңаеннан, бу йортны яшәү өчен уңайлы ясауда да чагылыш тапкан.

– Өйгә ремонтны Николай Иванович белән бергә ясадык, яңа идеяләрнең күбесен ул уйлап тапты, – дип сөйли Светлана Максимова.

Ул вакыттагы ноу-хаулар арасында – Максимов үзе уйлап тапкан шкаф-купе: аны урнаштыру өчен кухня мәйданының бер өлеше алына. Хәзерге дизайнерларның яратып кулланган ысулы бу, ә менә әле ул чакта... Яисә тагын бер идея – «сталинка»лардан алынганы: арткы стенасы белән салкын террасага чыга торган өй «суыткычы».

Светлана Борисовна сөйләвенчә, Максимовның кулы эшкә ятып торган, заводта эше буа буарлык булса да, ул йорт тирәсендәге бернинди хезмәттән дә баш тартмаган, шул ук вакытта аларны мөмкин кадәр кыскартырга, җайларга тырышкан. Кухня техникасы алырга яраткан һәм чираттагы берәр «гаджет» алу форсаты чыга икән, моңа бик куанган, чөнки директор төшке ашны завод ашханәсендә түгел, өенә кайтып ашауны хуп күргән. Йорт та аңа шундый ук мәхәббәт белән җавап биргән – яраткан алмагачы (ә Максимов атаклы бакчачы да булган әле!) бүгенге көнгә кадәр алма бирә.

Арткы стенасы белән салкын террасага чыга торган өй «суыткычы» – уңайлылык булдыру өчен Максимов уйлап тапкан новаторлык үрнәге.

АРХИТЕКТОР ХЫЯЛЫ

Ольга Туманская

Кессоннар белән бизәлгән өч катлы арка, бик зур ишегалды-парк... Без – Казандагы Белинский урамында, 1938 елда авиация заводы хезмәткәрләре өчен төзелгән яшел йорт каршында. Бу йорттагы фатирлар колонналы, бизәкле, биек түшәмле, планировкасы да уңайлы. Монда югары җитәкчеләр дә, инженерлар да, гади эшчеләр дә яшәгән.

Сүз уңаеннан, яшел йортны тоткыннар төзегән дигән сүзләр йөрсә дә, чынлыкта аны комсомол төзелешендә катнашучылар салган. Тырышканнар, уңайлылык турында заманы өчен иң алдынгы күзаллауларны кулланып, булдыра алганча сыйфатлы итеп эшләгәннәр, чөнки бу кешеләр якты киләчәк төзегән бит!

– Бу – ул вакытта Казанда төзелгән иң зур йортларның берсе, архитектурасында шул чорга хас сыйфат – сугышка кадәрге оптимизм сизелеп тора, – дип каршы алды безне үзенең фатиры бусагасында Марсель Искәндәров. Дизайнер, архитектор, ул үзенең фәнни диссертациясен 1930 нчы еллар – «сталин» архитектурасына багышланган. Аның фикере буенча, архитектура һәм шәһәр төзелешен оештыру күзлегеннән караганда, бу урынны шәһәребездә тормыш өчен иң яхшы җир дип санарга мөмкин.

Менә алар карашны шундук үзенә җәлеп итә торган Тоскана ордеры колонналары! Затлы бизәк элементы булудан тыш, алар бүлмәне зоналарга бүлү өчен уңайлы алым – залда куыш урын ясала. Һәм бу һәр фатирда диярлек шулай эшләнгән! Ремонт вакытында калын буяу катламы астында кыйммәтле терраццо технологиясе буенча эшләнгән тәрәзә

Фото: Александр Ефремов



төпләре, юыну бүлмәсе идәнендә «метлах» плитәләре табыла. Ә инде идәннәрне ачкач, фатирның тарихы үзе яңа хуҗага «юллама» җибәргәндәй тоела. Ленд-лиз буенча алынган Америка мае капкачы, тун биркасы, чыршы уенчыгы, «Белая ночь» хушбуе савыты, СССР белән Кытай арасындагы дуслыкны искә төшерүче кысык күзле курчак, иске ачкыч һәм икра этикеткасы... Өстән генә караганда да әлеге өч бүлмәле фатирның элеккеге хуҗаларының начар яшәмәгәннәре күренә, бигрәк тә фатирның коммуналка булуын исәпкә алганда!

– Әйе, сиксән квадрат метрда үз вакытында унберләп кеше яшәгән, – дип сөйли Марсель. – Ләкин аерым фатирлар бирү дә булган. Завод директоры үзе башка җирдә яшәгән, ә монда, гади эшчеләр, инженерлар белән күрше булып, мәсәлән, аның урынбасарлары, баш бухгалтер торган. Ягъни бернинди дә сегрегация, аеру булмаган. Хәзер мондыйны күз алдына китерү дә авыр.

Яшел йортка алтмышынчы елларда газ кертелә, ә аңа кадәр ризыкны иркен кухняларда примуста әзерләгәннәр. Йомычканы подъездда ук ярганнар – кайбер урыннарда әле хәзергә кадәр әзләре сакланган. Көек, корымны тышка чыгаруны вентиляциянең тармакланган системасы тәэмин иткән, шуңа күрә әле бүген дә монда суларга җиңелрәк кебек.

Күз алдына китерегез, 1938 елда бу фатирларда бәдрәф белән юыну бүлмәсе инде аерым булган. Соңгысында трап – тотылган су агып китә торган тишек булган, димәк, суны идәнгә агызырга да мөмкин – бу исә сыйфатлы эшнең тагын бер дәлиле. Керләрне чардакта киптергәннәр, фатирдагы кладовкадан тыш, подвалда һәр гаилә өчен әйберләрне саклау бүлмәләре дә бүленгән.

Әйе, йортның һәр метры кулланылган! Сүз уңаеннан, подъездларны бизәүгә дә тиешле игътибар күрсәтелгән – идәне әлеге дә баягы террацца технологиясендә эшләнгән, баскыч култыксасының киңлеге хәйран калдыра, ә тәрәзәләрне Рим әвернәсе формасындагы бизәк бизи...

Утыз сигезенче елларда әле массакүләм төзелешләр булмый, димәк, типлаштырылган планировкалар да юк. Конкрет бу йортта уникеләп төрдәге фатир бар – бер бүлмәледән алып алтыга кадәр. Һәм аларның һәркайсы үзенчә яхшы. Мәсәлән, монда хәтта бер бүлмәлеләрнең дә тәрәзәләре ике якка карый. Тагын бер сирәк очрый торган нәрсә – тәрәзәләрдән ачылган манзара: кая күз салсаң да – яшеллек.

Әлеге фатирны хуҗа сак, игътибар белән ремонтлый, әмма «музей» итеп тә калдырмый. Утызынчы еллар архитектурасына, аңа тиешле игътибар күрсәтелгәндә, хәзерге шартларга җайлашырга җитәрлек потенциал салынган, дип саный архитектор. Безнең тормыш рәвеше үзгәрүгә бәйле уңайлылыкларны (әйтик, кер юу машинасын урнаштыру, гардероб бүлмәсе ясау) бу фатирларда хәл итеп була.

– Архитектор буларак мин әле күптән түгел генә бик уңайлы саналган йортларның ун-егерме ел эчендә физик яктан да, мораль яктан да бик тиз искерүен, картаюын күзәтәм. «Сталин» архитектурасын исә озак яшәргә, озак кына түгел, бик матур картаерга да сәләтле, дип саныйм.

Яшел йортта яшәүнең тагын бер бәхәссез өстенлеге – аны биләп алган тирәлек. Бүгенгә кадәр монда машина кую урынына кытлык юк, аның каравы алга киткән инфраструктура бар, ял итү һәм йөреп керү урыннары күп. Шул рәвешле, кечкенә микрорайон кысаларында гына булса да, аны төзүчеләр үзләренең якты киләчәк турындагы хыялларын тормышка ашыра алган.

БЕЗНЕҢ ИШЕГАЛДЫ БӨРКЕТЛӘРЕ

Ольга Туманская

Бу ишегалдына керүгә, аның үзенчәлекле булуын аңлыйсың. Йорт фасадын мурал – канатларын җәйгән Ту-160 стратегик бомбардировщигы бизи. Керә-керешкә атаклы авиаторларның исемнәре язылган стенд каршы ала. Биредә язмышларын күк белән бәйләгән кешеләр яшәгән, гаилә корган, балалар үстергән.

– Бөтен ишегалды белән җыелып фильмнар караган чакларны хәтерлим әле мин! Әнә тегендә, уртадарак, экран урнаштырыла, киномеханик будкасы белән эскәмияләр куела иде. Бераз арырак – зур чәчәк клумбасы. Әлбәттә, спорт мәйданчыгы да бар иде…

КФУ доценты Борис Эйдельман әлеге ишегалдындагы йортта үскән. Казан авиациясе белән бәйле атаклы кешеләр, шул исәптән үзенең әтисе – авиатөзелеш заводы директоры Виталий Копыловның урынбасары Михаил Эйдельман турында ул бик күп сөйли ала. Чөнки ишегалды – иң әүвәл кешеләр дигән сүз ул. Танылган очучы-сынаучылар Борис Машковцев, Василий Демидов, Николай Губин, Әнвәр Кәримов (ул космонавтлар отрядында Юрий Гагарин белән бергә әзерлек узган) – бу әле йолдызлы исемлекнең бик аз өлеше генә.

– Биредә дусларча күршелек атмосферасы хөкем сөрә иде – бер-берсе белән әдәплелек өчен генә исәнләшмиләр, алар чыннан да бик күп аралашалар, бергә эшлиләр, гаиләләре белән дуслашалар, бер-берсенә кунакка йөрешәләр.

Ишегалды тарихының иң истәлекле вакыйгаларыннан берсе – Мария Абрамовна Машковцева фатирында оештырыла торган музыкаль салоннар. Ире кебек үк кызыклы шәхес, үз фатирында җылы мохит тудыра ала торган хуҗабикә була ул. Бу фатирда кино йолдызлары, танылган композиторлар, җырчылар кунак була.

– Әти бу кичәләрдә еш кына тамада булды. Ул кечкенә, җыйнак кына гәүдәле Александра Пахмутованың рояль янына килгәч ничек үзгәрүе, Людмила Гурченконың ул вакытта әле ире булган Иосиф Кобзоннан мәзәкләп көлүе турында сөйләргә ярата иде…

Борис Эйдельман безгә подъездның нәкъ мурал астына туры килгән тимер ишеген ача. Гагарин урамындагы 105 нче йорт, дүртенче кат... Кайчандыр мондагы бер бүлмәле фатирда, мөгаен, ишегалдының иң атаклы кешесе – хатыны һәм ике кызы белән Василий Сталин яшәгән.

Фото: Александр Ефремов



Хәрби-һава көчләре генерал-лейтенанты, Иосиф Сталинның кече улы. Бер катка югарырак танылган очучы Әнвәр Кәримов яшәгән.

– Василий Иосифович турында мин туганым Маша Кәримовадан ишеттем – алар үзара аралашканнар. «Башкала журналистлары аның турында дөреслекне белергә телиләр икән, килсеннәр һәм белсеннәр!» – дип ачулана иде ул, Василий Сталин турында сәрхүш булган дип язган һәр мәкаләне укыган саен.

Чыннан да, ишегалдында яшәүчеләрнең истәлекләренә караганда, генералиссимус улының портреты бераз башкачарак күзаллана: тыныч, акыллы, гади, тыйнак, ачык йөзле... Тагын бер кызыклы көнкүреш детале – ашарга әзерләргә ярата.

«Маша, мин бүген сезне шундый тәмле сациви белән сыйлыйм әле!» – дип исәнләшә Василий, күршеләрен баскычта күргәч. Чыннан да, кич белән хатыны Мария белән, кайнар ризык күтәреп, кунакка керәләр. Кичке аштан соң беркайчан да савыт-саба юмыйча китми ул. «Ярар инде, кирәкмәс иде!» – ди Мария Кәримова. «Маша, су нерв системасын тынычландыра», – дип җавап бирә Василий.

Күршеләр бары бер генә тапкыр Василий Сталинны барлык сугышчан бүләкләре беркетелгән формада күрәләр – аңа хәрби киемдә халык каршында күренергә тыелган була. Бу сынау очышы вакытында егылып төшкән Ту-16 самолеты экипажын соңгы юлга озатканда була. Командиры Әнвәр Кәримов булган экипаж. «Иртәгә мине Себергә җибәрсәләр җибәрерләр, әмма мин дустымны парад киеменнән озатырга тиеш», – дип нык тора ул чакта Василий. Бу фаҗигале очышта Василийның дусты – экипаж штурманы, өч Кызыл Йолдыз ордены кавалеры Демидовның гомере өзелә. Аның оныгы Марина Демидова, атаклы бабасының истәлеге итеп, фатирындагы кунак бүлмәсен тулысынча ничек булган шулай саклап калган. Бүлмәнең уртасында түгәрәк өстәл тора.

– Бу кунакчыллык символы – бабайның экипажы бик дус була һәм еш кына әлеге өстәл янында җыела, – дип сөйли Марина. – Ләкин мин шәхсән үзем, кечкенә булу сәбәпле, башка составны истә калдырдым – ирләре үлгәннән соң да дуслыкларын дәвам иткән сынаучы-очучыларның тол хатыннарын. Сүз уңаеннан, ирләреннән калган автомобильләрне йөртергә өйрәнү өчен, алар курсларга да барысы бергә язылды. Әбием «Волга» машинасын йөртә иде.

Бүлмә вакыт машинасы кебек безне 1950 нче елларга алып китә: агач идән, бизәкләп ясалган түбә, иске фотосурәтләр куелган буфет, Кытай келәме һәм ул вакытлар өчен зур байлык – люстра. Василий Степанович кибеттә сатып алган люстраны иптәше белән ломга асып алып кайткан.

– Кайчандыр йорт каршында шугалак бар иде, аннан да иртәрәк – сазлык, анда көймәдә йөри идек! – дип искә ала Марина Ринатовна. – Бүген монда сквер ясарга ниятлиләр. Бу җирләрне берничә мәртәбә төзелеш өчен алырга тырышып карадылар, безнең ишегалды халкы яклап кала алды. Күрәсең, мондый бердәмлек тә безгә әбибабаларыбыздан мирас булып күчкәндер.

Үз ишегалларын алар нәкъ шулай – «Авиатор» дип атаган. 2019 елда энтузиастлар тырышлыгы белән һәм ишегалларын төзекләндерү буенча президент программасында катнашу нәтиҗәсендә әлеге йорт яны территориясе үзгәреш кичерә башлый. Хәзер монда яңадан тормыш кайный: самолет формасындагы балалар мәйданчыгында сабыйлар мәш килә, үсмерләр спорт почмагын үз иткән, ә өлкәнрәк яшьтәгеләр өчен агач күләгәсе астында эскәмияләр тезелгән.

1
Штурман-сынаучы Василий Демидов фатирындагы бүлмә торышы вакыт машинасы кебек безне 1950 нче елларга алып китте.

2
Марина Демидова һәм Борис Эйдельман – атаклы авиаторлар ишегалдында яшәгән шәхесләрнең варислары.

3
Гагарин урамы, 105 нче йорт, дүртенче кат... Мондагы бер бүлмәле фатирда кайчандыр хатыны һәм ике кызы белән Василий Сталин яшәгән.

1

Фотолар Туполев-Крижевскийларның гаилә архивы һәм КАЗ архивыннан алынды.

ТУПОЛЕВЛАР ГАИЛӘСЕ ТАРИХЫ

Наталья Урейская

Казан авиациясе танылган авиаконструктор Андрей Туполев исеме белән дә шактый тыгыз бәйләнгән. Һәм гаиләсе белән дә. Өч тапкыр Социалистик Хезмәт Герое, Ленин һәм алты Дәүләт премиясе лауреаты, инженер гаскәрләре генерал-полковнигы, СССР Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Казан авиация заводына бик еш килеп йөргән, «Казан командировкалары» икешәр-өчәр айга сузылган, кайчагында күңелсезләнмәс өчен, кызы Юляны да үзе белән ала торган булган. Шуңа күрә Туполевлар шәһәребезне аеруча ярата, бу гаиләнең Казанга мәхәббәте әле дә сүрелми.

Заводка Андрей Николаевичның кияве – самолетлардагы көч бирү җайланмаларын проектлаштыру өлкәсендә танылган белгеч, СССР Дәүләт премияләре лауреаты Владимир Вуль да еш килә.

2014 елның июнендә Декабристлар урамында Андрей Туполевка һәйкәл ачу тантанасына аның оныгы – авиаконструктор Андрей Алексеевич Туполев килгән иде. Аның этисе Алексей Андреевич Туполев – дөньяда тавыш тизлегеннән югарырак тизлектә очарга сәләтле беренче пассажир самолеты булган Ту-144 очкычының баш конструкторы. 77107 номерлы әлеге самолет казанлыларга яхшы таныш – әлеге матур һәм куәтле машинага хәзер Четаев урамында карап сокланырга мөмкин.

2018 елда, Андрей Николаевич Туполевның тууына 130 ел тулуга багышлап, Казанның авиатөзүчеләр микрорайоны булган Социалистик шәһәр буйлап экскурсия оештырыла. Әлеге сәяхәтнең шигаре итеп: «Без тарихны һәм аны зур ярату белән булдырган кешеләрне онытмаска тиеш», – дигән сүзләр алына. Яңа маршрут белән беренче булып Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов таныша.

Туполев исемендәге конструкторлык бюросы үзенең 100 еллыгын билгеләп үткән быелгы юбилей елында Казан авиация заводы директоры Николай Савицких заводның районындагы мәктәп укучыларына шефлык итү традициясен торгызырга карар кыла. Социалистик шәһәр буйлап экскурсия аша ул яшь буынны район тарихы һәм илебез авиациясен булдыруга зур өлеш керткән шәхесләрнең язмышлары белән таныштыра.

СҮЗ АЛАМ МИН ДӘ

Шулай килеп чыга ки, Андрей Николаевич Туполев оныгының оныгы, Владимир Михайлович Вуль оныгының улы, Мәскәү кунагы Станислав Крижевский беренче яшь экскурсант була.

Станислав Казанга үзенең атаклы туганы белән бәйле урыннарны якыннан күрү өчен килә. Аның бабасы Социалистик шәһәрдә еш кунак булган, үзе ясаган очкычларны сынаучы пилотлар белән күрешеп торган.

Андрей Николаевич йөргән урамнар буйлап узгач, Станислав көтмәгәндә: «Ә мин сезгә Николина Гора бистәсе буйлап экскурсия үткәрә алам. Килегез! Әбием Юлия Владимировна хәзер шундагы дачада яши», – дип тәкъдим итте.

ЯРАТКАН ИСЕМ

Бөек авиаконструктор турында дистәләгән китап, йөзләгән мәкалә һәм хатирәләр язылган, нәфис һәм документаль фильмнар төшерелгән, төрле шәһәрләрдә аның исемендәге музейлар булдырылган... Ә менә «Татарстан» укучылары өчен без, Станиславның җиңел аягы белән, шактый эксклюзив күчтәнәч әзерләдек: Андрей Николаевич 1955 елда гаиләсе өчен атап алган дачада Туполевлар турында бүгенгәчә саклана торган кызыклы, җылы гаилә хатирәләрен барладык. Аларны атаклы конструкторның оныгы Юлия Владимировна сөйләде.

– Андрей Николаевичны барысы да ярата иде: хезмәттәшләре, күршеләре, өлкәннәр, балалар, этләр, песиләр... Ә гаиләсе исә аңа чын-чынлап мөкиббән була. Андрей Николаевич хатыны Юлия Николаевнаны шулкадәр ярата ки, аның хөрмәтенә кызына шул ук исемне куштыра. Ә аның кияве – Владимир Вульның Юлия Андреевнага карата мәхәббәте чиксез була, шуңа да аның хөрмәтенә кызына, ягъни миңа Юлия исемен бирә.

Юлия Крижевскаяның ире Владимир, мөгаен, традицияне дәвам иткән булыр иде, тик хатыны аңа ике ир бала – Павел һәм Алексейны бүләк итә.

Булачак ире белән танышу тарихын искә төшергәндә, Юлия Владимировна, шаяртып, Булгаков әсәрендәге сүзләрне китерә: «Мәхәббәт безнең каршыбызда, җир астыннан чыккандай, кинәт калкып чыкты...», – ди. Ул синагогага бәйрәмгә килә. Анда түгәрәккә басып биегән «бик матур яшь егетләр»не күреп ала, шуларның берсе белән карашлары очраша, һәм егет аңа кулын суза. Гомерлеккә.

Аның әти-әнисе Юлия Туполева белән Владимир Вуль арасында да бер күрүдә мәхәббәт кабынган булган икән. Алар Арбаттагы бер кибеттә танышкан һәм шуннан соң бер дә аерылышмаган.

ЯЛКЫНЛЫ ЙӨРӘКЛӘРГӘ УТ САЛУЧЫЛАР

Туполевлар нәселендәге ир-атлар нинди хатын-кызларны яраткан соң? Бер билгеле җырда «ялкынлы моторлар» дип аталган дәртле йөрәкләрне Юлия исемле кызлар гына ауларга сәләтле микән әллә?

Юлия Владимировна башка серләрне дә ача.

Мәшһүр авиаконструктор булып танылачак Туполев сөеклесе белән Беренче бөтендөнья сугышы яралылары өчен ачылган госпитальдә өлкән шәфкать туташы («медбрат» дигән сүз ул вакытта бөтенләй кулланылмый) булып эшләгәндә таныша. Юлия Николаевна анда, хәзерге заман теле белән әйткәндә, волонтер була. Мәскәү консерваториясен һәм югары хатын-кызлар курсларын тәмамлаган кыз, берничә чит тел белә.

– Сүз уңаеннан, улым Алексейның хатыны һәм Станиславның әнисе – Марина Крижевская да чит телләрне камил белә, аның эше дә хәйриячелек һәм өметсез авы-



1
Бар гаилә җыелгач (сулдан уңга): Юлия Андреевна һәм Андрей Николаевич Туполевлар, Владимир Георгиевич Крижевский, нәни Павел Владимирович Крижевский, Владимир Михайлович Вуль, Юлия Владимировна Крижевская. 1971 ел.

2
– Андрей Николаевичны барысы да ярата иде: хезмәттәшләре, күршеләре, өлкәннәр, балалар, этләр, песиләр... Ә гаиләсе исә аңа чынчынлап мөкиббән була, – ди Юлия Владимировна.



3
Юлия Владимировна белән Алексей 1978 һәм 2022 елларда дача фонында.

ру кешеләргә ярдәм күрсәтү белән бәйле. Ул хоспислар төзү һәм аларга булышу белән шөгыльләнә торган «Вера» фондында эшли.

ПОЛИГЛОТЛАР ҺӘМ КИТАП КОРТЛАРЫ

Туполевлар гаиләсендә барысы да полиглотлар. Андрей Николаевич авиация тематикасы буенча барлык чит ил журналларын укып барган. Кайчагында аңа аларны хатыны яки оныгы Юля тәрҗемә иткән.

– Мин француз мәктәбендә укыдым, – дип сөйли Юлия Владимировна. – Булачак режиссер Павел Лунгин белән бер партада утырдым. Аның әнисен – Астрид Линдгрен әсәрләрен тәрҗемә иткән Лилиана Зиновьевнаны бик ярата идем...

Туполевлар гаиләсендә укырга яраталар. Юлия Владимировна искә алуынча, Кырымга ялга баргач, бабасы: «Син миңа нәрсә кирәген беләсең», – дип, аны шунда ук китапханәгә җибәрә торган була. Һәм Юлия аңа Лев Толстой китапларын алып кайткан. Некрасов һәм Пушкин әсәрләрен Андрей Николаевич бите-бите белән яттан сөйли алган.

ТУПОЛЕВ – ТӨРМӘДӘН ЧЫГУ АЧКЫЧЫ

Күңелдәге җылы истәлекләр кайвакыт авыр хатирәләр белән үрелеп бара – репрессияләр дулкыны Туполевлар гаиләсен дә урап узмый.

Владимир Вуль Лондонда урнашкан Мәскәү халык банкы директоры Михаил Вульның улы була. 1937 елда Михаил Давыдовичны Мәскәүгә чакыртып кайтаралар да атып үтерәләр. Ә хатынын лагерьга озаталар. Андрей Николаевич үзе һәм аның хатыны исә, корткычлыкта, контрреволюция оешмасы белән бәйләнештә гаепләнеп, иректән мәхрүм ителә. Төрмә богауларыннан котылгач,

авиаконструктор кияве өчен икенче этигә һәм остазга әверелә.

Андрей Николаевичны СССР Югары Советы депутаты һәм ярлыкау комиссиясе рәисе итеп сайлагач, ул капчык-капчык хат ала. Аның белән бергәләп бер төркем юристлар командасы эшли. Әгәр алар гаепсез хөкем ителгән кешене ничек тә коткару, иреккә чыгару мөмкинлеген таба икән, эшне ахырына кадәр җиткерәләр. Депутатка мөрәҗәгать иткән һәр тоткынга ничек тә булса булышырга тырышалар. Хәтта «Туполев – төрмәдән чыгу ачкычы» дигән гыйбарә дә пәйда була.

Юлия Владимировна әбисенең, ә соңрак әнисенең дә конвертларга акча салып утырганын хәтерли. Андрей Николаевич күп кешеләргә матди ярдәм күрсәтә. Хастаханәләргә барып, катлаулы операцияләргә мохтаҗ балалар өчен шәхсән ярдәм сорап йөри.

– Күпме кешене, дәвалану өчен, хастаханәгә салуга иреште ул! – дип искә ала бөек авиаконструкторның оныгы.

Бервакыт Юлия Владимировнаның хезмәттәше, медицина ярдәме күрсәтүен сорап, атаклы хирург Андрей Королевка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Үтенечне ишеткәч, ул: «Туполевка гомеребез белән бурычлы бит без!» – дип җавап бирә.

БАБАЙДАН КАЛГАН МИРАС

– Миңа дәү әнинең этисен күрергә насыйп булмады, – ди Юлия Владимировнаның улы Алексей. – Әти-әнием, әби-бабам истәлекләре, төрле мемуарлар һәм биографик китаплар нигезендә гомерем буе туплап ясалган җыелма портрет кына бар. Аны кайвакыт даһи дип атаганнар. Даһилек – бик көчле психофизик үзенчәлек, ул еш кына ниндидер экстремальлек белән чиктәш. Ә Андрей Николаевичның гаҗәеп акылы ихлас кешелеклелек белән берләшкән. Шуңа күрә ул гаиләсенә социаль генетиканың бик зур, сәламәт, рациональ уйланылган тәҗрибәсен мирас итеп калдырган.

БИШЕНЧЕ БУЫН

Легендар Туполевның оныклары һәм аларның балалары белән саубуллашып, Николина Гора бистәсеннән Казанга бу гаиләнең буыннан-буынга күчеп килгән бәхет серен алып кайтып китәбез. Чынлыкта анда гайре табигый һични юк: бер-береңне яратырга, хөрмәт итәргә, ярдәмләшеп яшәргә һәм һәрвакыт кеше булып калырга кирәк. Тагын бер шарт: үз тамырларыңны һәм гаилә тарихын онытмау зарур. Даһи авиаконструктор Туполев оныгының оныгы Станислав үз гаиләсенең тарихын бишенче буынга кадәр чатнатып белә. Ә безнең оныкларыбызның оныклары да шулай мактанып-горурланып сөйли алырмы?

4

– Миңа дәү әниемнең этисен күрергә насыйп булмады, – ди Юлия Владимировнаның улы Алексей. – Әти-әнием, әби-бабам истәлекләре, төрле мемуар һәм биографик китаплар нигезендә гомерем буе туплап ясалган җыелма портрет кына бар.

5

Андрей Николаевич һәм Алексей Андреевич Туполевлар.

PRESSA

«КӨНДЕЗГЕ ФУРИЯЛӘР» ҺӘМ «ТӨН ПӘРИЛӘРЕ» ӨЧЕН КАЗАН КАНАТЛАРЫ

Фотолар Туполев сынау-конструкторлык бюросы музее архивыннан алынды.

Наталья Урейская

Бу елның 22 июнендә Мәскәүдә яшәүче Полина Бельцова Казан авиация заводы коллективына Советлар Союзы Герое, Бөек Ватан сугышы елларында өч хатын-кыз авиаполкы: истребительләр, көндезге һәм төнге бомбардировщиклар полклары оештырган очучы-штурман Марина Раскова турында китап алып килде.

ФЕРЗЬГӘ ӘЙЛӘНГӘН ПЕШКА ӨЧЕН РӘХМӘТ

Китап героиняларыннан берсе – Полинаның әбисе – штурман Галина Брок-Бельцова, завод хезмәтчәннәре өчен махсус атап, басмага үз имзасын куйган, китапта аларга «ферзьгә әйләнгән «Пешка» өчен» рәхмәт белдергән. Бөек Ватан сугышы елларында ул үзе Казан авиация заводында җыелган Пе-2 бомбардировщигында очкан.



Полина сөйләгәнчә, әбисенә инде 97 яшь булса да, көч-куәте әүвәлгедәй ташып тора, картлыкка һич бирешми икән. Галина Павловна – очучы белгечлекләренә ия хатын-кызларның «Авиатриса» берлегенең вице-президенты. Очучы хатын-кызлар турында китаплар чыгарырга булыша.

Ул «Татарстан» журналы белән дә хатирәләрен уртаклашырга әзер. Һәм менә без Мәскәүдә, курку белмәс штурман Галина Брок-Бельцовада кунакта.

САМОЛЕТ ИСЕ КИЛӘ!

– Безнең турында озак белмәделәр, бу сер иде, – ди Галина Павловна.

Бәлки, менә шуңа да әлеге ханым турында Казан авиация заводында да бөтенләй хәбәрдар булмаганнардыр. Ә бит аның тормышы әлеге заводта җыелган төрле хәрби очкычлар (пикировщиктан алып стратегик бомбардировщикка кадәр!) тыгыз бәйләнгән.

Туполев сынау-конструкторлык бюросы музеенда Галина Павловнаның инде безнең көннәрдә җыела торган стратегик бомбардировщик – Ту-160ның идарә системасы стендындагы штурвалын тотып төшкән фотосурәтен күрергә мөмкин. Конструкторлык бюросы хезмәткәре Ренат Җәләлиев әлеге фотоның быел гына төшерелгәнен телгә алды.

«Самолет исе килә!» – дип сөенгән Галина Павловна, штурвалга тотынгач.

1 «Самолёт исе килә!» – дип сөенгән Галина Павловна, штурвалга тотынгач.

2 Сылу гәүдәле, көчле, нык булганга, мине «Чыршыкай» дип йөртәләр иде

3, 4 Штурман Галина Брок-Бельцова, завод хезмәтчәннәре өчен атап, басмага үз имзасын куйган, китапта аларга «ферзьгә әйләнгән «Пешка» өчен» рәхмәт белдергән.

5

Георгий Бельцов белән алар 60 елга якын матур гомер кичерә.

6

А.Н. Туполев сынау-конструкторлык бюросында.

АНЫ «ЧЫРШЫКАЙ» ДИП ЙӨРТКӘННӘР

Ә Пе-2 кабинасына Галина Брок беренче тапкыр 1943 елның кышында Йошкар-Оладa утыра. Анда көндезге бомбардировщиклар полкы өчен очучылар һәм штурманнар әзерлиләр. Очучыас Георгий Бельцов яңа укучылар сафын карап йөргәндә полк балалары өчен тегелгән шинель кигән кызны күреп ала.

«Син 10 сыйныфны тәмамладыңмы соң?» – дип кырыс кына сорау бирә Галинага чибәр офицер.

– Ун сыйныфны тәмамламадым мин, – дип сөйли Галина Павловна, – тугызынчы сыйныфтан соң Беренче хәрби авиация элемтә училищесына укырга кердем. Анда фронт өчен синоптик-метеорологлар әзерлиләр иде. Бары отличникларны гына алалар. Метеорологик исәпләүләр һәм карталар ясау, очышка рөхсәт бирү серләренә тиз арада өйрәнергә кирәк иде. Бер ел укыгач, Марина Раскова полкына яңа сугышчылар эзләүчеләр килеп төште. Без 300 кыз идек, барыбызны актлар залында җыйдылар да, кем үз теләге белән штурманлыкка укырга китәргә һәм яңа техникада очарга әзер, дип сорадылар. Тугыз кеше кул күтәрде.

Мәскәүдә мин 3 нче үрнәк мәктәптә укыдым. Без барыбыз да спорт белән ныклап шөгыльләндек. Сылу гәүдәле, көчле, нык булганга, мине «Чыршыкай» дип йөртәләр иде. Безне рус классик әдәбиятында тәрбияләделәр. Үз дәрәҗәбезне белергә өйрәттеләр. Шуңа күрә мин офицер алдында югалып калмадым, аның барлык сорауларына тыныч кына җавап бирдем. Аңа әллә ни игътибар да бирмәдем. Мин штурманлыкка укырга килгән идем бит.

...МИН СИНЕ ЯУДА САКЛАРМЫН

Һавада очу күнекмәләренә кызлар ел буе өйрәнә. Галина экипажын фронтка озатканда, кызны үзенә карату өчен Георгий Бельцов очарга әмер бирелгән очкыч кабинасының тәрәзәсенә шакый. Борылып карамый кыз. Тик, башка кызлар кебек үк, егетнең фотосурәтен үзе белән ала. Георгий Бельцов фотографиянең арткы ягына һәркемгә: «Сугыш беткәч, без очрашырбыз. Җиңүгә кадәр яшәячәкбез!» – дип яза.

Ә Галинага биргән фотосурәттә башка сүзләр була: «Истәлеккә бүләк итмим, үзең аңлагач, кайтарып бирерсең йә үзем әйтермен. Үзең белән йөрт, мин сине яуда саклармын!»

Һәм саклый да.

Авиация генерал-майоры Георгий Бельцов белән алар 60 елга якын матур гомер кичерә. 1945 елда өйләнешә алар. Өч балалары, җиде оныклары бар, аларның һәрберсе бер-бер артлы нәни сабыйлар белән сөендерә тора...



ДӨНЬЯНЫҢ БАР ЧӘЧӘКЛӘРЕН...

Булачак ире белән беренче очрашуы турында Галина Павловна тыйнак кына сөйләсә, Пе-2 очкычына соклану, аны мактау сүзләрен кызганмый. Машинаның хәрби сыйфатларын да, көчен дә, ышанычлы булуын да югары бәяли. Совет кызларының очучылык осталыгына француз пилотларының соклануын исенә төшерә. Франция һәм Америка пилотлары Пе-2не иярләргә омтылып карый, тик бу машина белән идарә итү шактый катлаулы була, очып төшкәндә артык югары тизлектә утыра. Нәзакәтле французлар кызларга: «Хәлебездән килсә, сезгә дөньяның бар чәчәкләрен җыеп бирер идек», – диләр.

Аларның нәзакәтлелеге сүздә генә түгел, чын тормышта да чагылыш таба. Бервакыт Галина Павловнаның экипажы эскадрильядән артта кала – моторның берсе көйсезләнә. Пе-2 һавага истребительләр сагы астында гына күтәрелә. Бу юлы истребительләр бомбаларны ташлап кайтып барган коллегаларын аэродромга озата киткән була. Тося Спицина һәм Галина Брок хәрби бурычны ялгызлары гына үтәп, эшләрен фотога төшерәләр дә база ягына очалар. Шул вакытта ике немец «Фокке-Вольф» истребителе якынюын күрәләр. Очучы башта бер, ә аннары ике бармагын күрсәтә, янәсе: «Бер атуда бәреп төшерергәме, әллә ике тапкыр атыйммы?» Тик шулчак Як-3 истребительләрендә французларның «Нормандия–Неман» авиаполкы очучылары килеп чыга һәм кызларны аэропортка кадәр озатып куя.

СҮЗ УҢАЕННАН

Франциядә совет очучы кызларының батырлыгы һәм профессионализмы турында бүген дә хәтерлиләр. Былтыр француз язучысы Мартин Гэй «Төн пәриләре, көндезге фурияләр. 1941–1945 елларда совет очучы кызлары» дигән китап чыгарган. Тик башта ул Галина Павловнадан аның полкындагы очучы кызларны «көндезге фурияләр» дип атарга рөхсәт сораган, чөнки алар көндез генә оча торган булган.

– Мин энциклопедиядә «фурия» сүзенең мәгънәсен карый башладым. Төрле халыклар аны төрлечә аңлата икән, әмма, гомумән алганда, «мифологик сугышчы хатын-кыз, үч алучы хатын-кыз» дигән мәгънә белдерә, бу исә безнең полк эшчәнлеген дөрес чагылдыра. Әүвәл китапны «Төн пәриләренең берсе» дип атарга ниятләгәннәр иде, – дип сөйләде Галина Павловна үзенең язучы ханым белән хезмәттәшлеге турында.

«Төн пәриләре»нең берсен Казанда яхшы беләләр. Шәһәрнең бер урамы аның исемен йөртә. Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланова 46 нчы гвардия Тамань хатын-кызлар авиация полкында эскадрилья командиры урынбасары була. Полк белән Евдокия Бершанская командалык итә. Совет очучылары кызларны – «Дунькин полк», ә немецлар «төн пәриләре» дип атый. Алар авиаконструктор Николай Поликарповның По-2 бипланында оча. По-2 төнге бомбардировщигын да, көндез оча торган Пе-2не дә Казанда җыялар. Хәзерге Казан вертолет заводында. Самолет, моторын сүндереп, тиешле урынына тавышсыз гына шактый якын очып килә дә, төнге тынлыкны ярып, дошман объектларына бомба яудыра алган. Аның бу сәләте немецларның котын ала торган була.

***

– Безне Берлинга кертмәделәр, – диде саубуллашыр алдыннан Галина Павловна. – Аның көнендә Пе-2 самолетлары болай да күп иде. Безнең ферзьгә әйләнгән «Пешка» Җиңүгә үз өлешен кертте. По-2 дә шулай ук. Һәм моның өчен данлыклы авиатөзүчеләр шәһәре булган Казанга рәхмәт!

7 Мәскәүле Полина Бельцова (уңда) Казан авиация заводы музее директоры Янина Чурбановага Советлар Союзы Герое, Бөек Ватан сугышы елларында өч хатын-кыз авиаполкы оештырган очучы-штурман Марина Раскова турында китап тапшыра.

8 «Хатын-кыз авиаторлар турында 76 бәян һәм хат» дигән тагын бер китап Мәскәүдән Казан авиация заводы хезмәткәрләренә бүләк итеп җибәрелә.

Фотолар: Александр Ефремов, «Ватан» республика берләшмәсе архивыннан

ЛЕГЕНДА ПИКЕДАН ЧЫГАРМЫ?

Олеся Бондаревская

«Александр Коноплев дуслары белән гаражда самолет җыя» – Казанда легендар Пе-2 очкычын җыю турында тәүге репортажларның берсе шундый башисем белән чыга. «Татарстан канатлары» дип аталган уникаль проект шулай башлана һәм дәвам итә.

Башта урман ешлыгында озын бүрәнкәсыман чокыр күренә. Алай гына да түгел, су белән тулган аланлык дияргә дә була. Эзтабарларның сизгерлеге сынатмый: металл эзләгеч чыелдый башлый. Ул да түгел, туфрак катламында очкычның шассие күренә. Димәк, самолетның башка өлешләре дә монда булырга тиеш! Рация дә җанланып китә: ярты чакрым тирәсе ераклыкта, бөтенләй икенче якта эшләгән командадан хәбәр алына – экипаж әгъзасының шлемофонын тапканнар. Ике отряд та бер үк вакытта самолет һәлакәте урынына чыга. Татарстанның «Ватан» берләшмәсе эзтабарларының һәм аларның Северодвинскидан килгән коллегаларының сазлыклы Тосно урманнарында бу табылдыкны табарга өметләре җуела башлаган була инде.

– Шлемофон – шәхси әйбер. Гадәттә аны алыштырмыйлар, кешенекен дә алмыйлар. Без аны пычрактан чистарттык һәм наушнигында «Костя» дип язылган язуны таптык, – дип сөйли Татарстанның «Ватан» берләшмәсе эшләре идарәчесе, тарихчы Илья Прокофьев. – Аннары самолет двигателе номерына карап, безнең база буенча экипаж әгъзаларының исемнәрен ачыкладык. Костя дигәнебез Константин Павлович Прохоров булып чыкты, ул Кострома өлкәсенең Нерехт районы Сарай авылында туып-үскән егет.

Кул астындагы берничә база мәгълүматын чагыштырып, эзтабарлар шлемофон хуҗасының язмышын ачыклый. Аның самолетын 1943 елның июлендә бәреп төшерәләр. Очучы һәм штурман һәлак була, ә укчы-радист парашют белән Тосно урманына төшә, аннары, күрәсең, үзебезнекеләр ягына таба 30 чакрымнар тирәсе юл үтә, тик барып җитә алмый, әсирлеккә эләгә. 1944 елда немецларның Херне лагереннан качарга омтыла, әмма аны тоталар. Костя шул ук елны әсирлектә үлә. Аңа 24 яшь кенә була.

«НЕМЕЦ ХӘШӘРӘТЛӘРЕНӘ ҮЛЕМ»

Өлкән очучы Александр Поляков, штурман Василий Пыхтунов һәм укчы-радист Константин Прохоров командасы тулысынча «Хроника пикирующего бомбардировщика» экипажы прототибы була алыр иде. Егетләр мәктәп эскәмиясеннән үк диярлек аэродромга юл ала. Анда заманы өчен иң алдынгы, инновацион Пе-2 очкычларын өйрәнәләр, һавага күтәреләләр һәм, нәфрәтләнеп, дошман самолетларын юкка чыгаралар. Сугыш елларында һавага күтәрелгән якынча 11,5 мең бомбардировщикның 10,5 меңе Казанда җыелган. Монда экипажлар аларга сынаулар үткәрә, аннан соң фронтка, үзләренең частьларына китәләр.

– Пе-2 конструкциясендә агач детальләр кулланылмаган беренче очкыч була. Шул ук вакытта электрлашу дәрәҗәсе буенча ул заманының башка самолетларын узып китә. Шуңа күрә самолетны сынау еш кына хәвеф-хәтәр белән бәйле була, – дип сөйли Илья Прокофьев.

Двигательләр эшләмәскә, таркалырга, янарга мөмкин, руль һәм идарә системаларында җитешсезлекләр табыла. Татарстан территориясендә сынау һәм бер җирдән икенчесенә күчерү очышларында гына да берничә экипаж һәлакәткә очрый. 1942 елда Казаннан Мәскәүгә очкан Пе-2 самолетында аны уйлап тапкан Владимир Петляков үзе дә һәлак була. Ул вакытта С.П. Горбунов исемендәге 22 нче номерлы Казан авиация заводы дистәгә якын машина чыгара. Эш бик кызу темпларда бара, эшчеләр станок янында 12–14 сәгать эшли.

1944 елның гыйнварында Казан авиация заводы конвейерында эшләүче бер эшче подшипник бокрасына электрокарандаш белән «Немец хәшәрәтләренә үлем» дип яза. Тылдан фронтка бу «сәлам»нең нинди хисләр белән җибәрелгәнен күз алдына китереп була. Татарстан эзтабарлары мондый язуларны Пе-2 детальләренең эчке өлешләрендә таба.

– Без 1980 нче еллардан бирле хәрби самолетлар егылып төшкән урыннарда эшлибез. Безнең бурыч – очучының гәүдәсен табу, исемен ачыклау, туганнарын эзләү, күмү эшләрен оештыру, сугышчы турында мәгълүматны яңарту. Шул рәвешле без 155 экипаж әгъзасының язмышын ачыкладык. Шулай да безгә очкычның үзе дә гел кызганыч тоела иде. Самолет калдыклары беркемгә дә кирәк түгел. Аларны еш кына тимер-томырга тапшыралар, йә булмаса хуҗалык максатларында,

әйтик, бакчада кулланалар. Ә безнең аларны онытылудан саклап каласы, Бөек Ватан сугышында батырлыкларның нинди машиналарда кылынганын һәм якташларыбызның дүрт ел дәвамында нәрсә хакына ач-ялангач, көнне төнгә ялгап эшләгәннәрен күрсәтәсебез килде, – дип сөйли «Ватан» республика берләшмәсе җитәкчесе Александр Коноплев. Аның ике бабасының да язмышы турыдан-туры авиация белән бәйле: берсе, очучы Константин Александрович Голубев, 1941 елның 3 июлендә хәрби заданиедән кире кайтмый, икенчесе, Геннадий Александрович Коноплев, сугыш буенча Казан авиация заводында Пе-2 очкычларын җыя.

Шул рәвешле 2017 елда «Татарстан канатлары» проекты пәйда була. Максат – республикага аның Бөек Җиңүгә керткән өлешенең төп символларының берсе – торгызылган Пе-2не кайтару.

ЙӨЗЛӘГӘН ТАРИХТАН ҖЫЕЛ ПАЗЛ

Гаять зур максат. Сугыштан соң калган бомбардировщикларны 1950 нче елларда реактив авиация алыштыра, Пе-2ләр үтилгә тапшырыла. Россиядә бары ике Пе-2 генә кала – Мәскәү өлкәсе Монино шәһәрендә Хәрби-һава көчләре үзәк музеенда чын самолет үзе һәм Югары Пышмадагы (Свердловск өлкәсе) Хәрби техника музеенда торгызылган үрнәк. Башка илләрдә тагын өч машина сакланган. Калганнары – төрле дәрәҗәдә сакланып калган, безнең иксез-чиксез илебез кырларында, урман һәм сазлыкларында таралып яткан калдыклардан торган гаять зур пазл.

– Утыз ел элек тә, хәзер дә без экспедициягә походка барган кебек җыенабыз. Аквалангчы җайланмалары, чыгыр, палатка, ашамлыкларны күтәрелү ноктасына үзебез алып киләбез. Берникадәр вакыт элек грантка кечкенә генә вездеход-амфибия сатып алган идек, аңарда 400 кг га кадәр йөк ташырга мөмкин. Әмма, мәсәлән, двигатель табабыз икән, аны сүтеп, өлешләп чыгарырга туры килә, – дип сөйли Александр Коноплев.

Татарстанлылар Карелиядә табылган Пе-2 очкычының берничә детален алып кайта, шул исәптән пике вакытында тизлекне киметергә мөмкинлек бирә торган тормоз рәшәткәләрен дә.

Табылган һәр самолет – табышмак. Кайчагында аны шактый тиз чишәргә, ягъни машинаның хәрби юлын һәм экипаж әгъзаларының исемнәрен ачыкларга була, әйтик, самолет һәм двигательләрнең сакланып калган серияле номерлары буенча. Илья Прокофьевның дистә еллар дәвамында җентекләп тупланган базасы бар, номерлар буенча мәгълүматны ул шунда таба. Аның базасында Пе-2 очкычларына караган 4 меңләп язма теркәлгән, бу якынча 700 самолет дигән сүз. База архив материалларының ачылуы хисабына, эзтабархезмәттәшләре, энтузиаст-тарихчылар ярдәме белән тулылана бара.

– 2018 елда Мәскәү өлкәсендәге коллегаларыбызга Карелия Республикасының Сегеж шәһәрендәге аучылардан хәбәр килә. Берничә ел элек урманда самолет ватыклары табылуын әйтәләр, фотолар да җибәрәләр. Эзтабарлар, Пе-2 калдыкларын танып, безгә хәбәр иттеләр. Без аучылар янына бардык, бергә «уазик» белән урман чытырманына – самолет егылган урынга килдек. Беренче, икенче тапкырдан булмаса да, двигательнең номеры сугылган фрагментны таптык. Тик әлеге сериядәге самолетларны сугыш алдыннан гына чыгарудан туктатканнар, һәм бу җирдә барган сугыш югалтулары исемлегендә дә очкыч теркәлмәгән иде, – дип сөйли Илья Прокофьев.

Аучыларның берсе самолетта финнар очарга мөмкин, дигән фараз әйтә. Татарстанлылар фин тарихчысы Карл Геуст белән элемтәгә керә. Ул сугышның беренче көннәрендә немецлар кулга төшергән, фин армиясе сатып алган һәм 1943 елда радарлардан югалган самолет моторлары номерларын таба ала. Бу нәкъ менә Карелия урманында аучылар тапкан очкыч була. Соңрак Геуст экипажның исән калган ике әгъзасы совет госпиталенә эләгүен хәбәр итә. Берсе өч көннән соң үлә, икенчесе исән кала, 1944 елда үз иленә кайта, белем ала һәм, Италиягә китеп, опера җырчысы була. Эзтабарлар Геуст үтенече буенча госпитальдә һәлак булган очучының Беломорск шәһәрендә туганнар каберлегендә күмелүен ачыклый. Совет сугышчылары белән бер кабердә булуы да ихтимал.

БЕЗ ИНДЕ ЮГАЛТА ЯЗГАН ХӘТЕР

Татарстанлылар Карелиядә табылган Пе-2 очкычының берничә детален алып кайта, шул исәптән пике вакытында тизлекне киметергә мөмкинлек бирә торган тормоз рәшәткәләрен дә. Канатларының колачы 16 метрга җиткән самолетны эзтабарлар иске янгын частеннан калган гаражда җыялар. Гараж киштәләре Калуга, Мәскәү, Түбән Новгород, Псков, Брянск, Ленинград, Мурманск, Смоленск өлкәләреннән һәм Карелиядән алып кайтылган самолет фрагментлары белән тулган. Проектка күптән яңа урын кирәк, әмма «Ватан» ел саен берничә федераль һәм республика программалары буенча ота барган грант акчалары экспедицияләр оештыруга, детальләр-

не кайтартуга, комплектлаштыру әйберләрен сатып алырга гына җитә.

Хәзер гаражда 69 Пе-2 самолетының детальләре саклана. Эзтабарлар самолетның канатлары, койрыгы, кабина, борыны беркетелә торган «рам»ны җыялар. Кайнар һава өрдерү ярдәмендә бердәнбер төзек двигательне эшләтеп җибәрергә планлаштыралар. Дөрес, аңа башта вкладышлар сатып алырга кирәк... Экспедицияләрдә табылган детальләрнең өчтән бере генә очкыч җыярга яраклы. Калганнары яңадан торгызылырлык хәлдә түгел. Алар буенча детальләрнең күчермәләрен ясарга кирәк, әмма шул ук вакытта проектта катнашучылар самолетны максималь дәрәҗәдә чын, аутентик итеп җыярга тели. Конструкциянең кайбер элементлары, мәсәлән, кабина, прибор панеле бөтенләй юк диярлек – җиргә бәрелүдән һәм янудан бу өлешләр барыннан да көчлерәк зыян күрә.

Хәлне самолет конструкциясенең сызымнары булмау да катлауландыра, алар төрле сәбәпләр аркасында сугыштан соң юкка чыккан. Өлешчә Пе-2не ремонтлау буенча КМТТУ-КАИ китапханәсе һәм КАПО музеенда сакланган китаплар коткара. Тик проблема шунда ки, самолет даими камилләштерелеп торган һәм сугыш вакытында аның 500 гә якын модификациясе чыккан. Шулай булгач, хәтта бөтен детальләр табылып, аларны урнаштыру инструкцияләре булган очракта да, алар бер-берсенә туры килмәскә мөмкин. Проектка ярдәм йөзеннән КАПО үз эшчеләре – слесарьларны тәкъдим иткән…

– Быел һәм киләсе ел башында инде табылган самолетларның фрагментларын кайтару белән шөгыльләнәчәкбез, шул исәптән Константин Прохоров очканын да, – ди Александр Коноплев. – Әлбәттә, кайдадыр зыян күрмәгән Пе-2 кабинасы ята дип хәбәр итәләр икән, без шунда ук килеп җитәчәкбез. Ватылмаган детальләрне никадәр күбрәк тупласак, самолетны җыю эше шулкадәр тизрәк барачак.

Һәм тагын бер нәрсә: хәтта тулысынча җыелган самолет та оча алмаячак – детальләр артык тузган. Һавага күтәрелергә сәләтле яңа очкыч күчермәсен ясау өчен 500 млн сумга якын акча сорала. Һәм моны хәзер үк, прототипны җыйганчы эшләргә кирәк, чөнки детальләрнең 3D-күчермәләрен ясап калу таләп ителә. Тик туры килә торган сканер да, аның белән эшли белүче белгечләр дә юк.

2020 елда Казан «Хезмәт батырлыгы шәһәре» статусын алды. РФнең бу мактаулы исеме «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы вакытында тыл хезмәтчәннәренең батырлыгын мәңгеләштерү максатларында» гамәлгә куела һәм «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш керткән, шәһәр территориясендә урнашкан сәнәгать предприятиеләрендә хәрби һәм гражданлык продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин иткән, һәм шул ук вакытта массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге күрсәткән шәһәрләргә бирелә». Шунысы кызык: әлеге батырлык чагылышы булган матди һәйкәлне торгызу өчен инде күптән массакүләм булудан туктаган шул ук каһарманлык һәм фидакарьлек кирәк икән.

Эзтабарлар самолетның канатлары, койрыгы, кабина, борыны беркетелә торган «рам»ны җыялар.

Бердәнбер төзек двигательне эшләтеп җибәрергә планлаштыралар.

Фото: Александр Ефремов, kpfu.ru. Язмада ХһКнең Казандагы махсус 9 нчы мәктәбенең 80 еллыгына багышланган «Честь имею!» китабыннан өземләр кулланылды.

ТУГЫЗЫНЧЫ МАХСУС МӘКТӘП

Алсу Троицкая

Хәрби-һава көчләренең Казандагы 9 нчы махсус мәктәбен тәмамлаучыларның язмышы төрле. Әлбәттә, күбесенең тормыш юлы авиациягә бәйле. Араларында галимнәр, инженерлар, төзүчеләр, сәнгать әһелләре дә бар. Әмма бу мәктәпне тәмамлаучылар тормышта ни белән генә шөгыльләнсәләр дә, ирләр дуслыгының бәһасен белгән чын ватанпәрвәрләр булып калалар.

БУЛАЧАК ГЕРОЙЛАР

1941 елның гыйнварында Казан урамнарында курсантлар формасы кигән чибәр егетләр пәйда була, барысында да кара шинель, куе зәңгәр төстәге китель һәм чалбар, киң каеш һәм хром ботинка. Зәңгәр петлицаларында – ВВС (ХһК) эмблемасы, аеру билгеләре өчпочмаклары һәм «СШ» хәрефләре. Беренче курсантлар. Аларның тәүге чыгарылышы 1941 елның 20 июненә туры килә.

Хәрби-һава көчләре махсус урта мәктәбенең беренче җитәкчесе Йосыф Туишевның педсоветтагы ялкынлы чыгышын укытучылар игътибар белән тыңлый:

– Безнең бурычыбыз – булачак геройлар тәрбияләү! Бернәрсә белән дә исәпләшмичә, партия һәм халыкка тугры калып, Ватан өчен гомерләрен бирергә әзер булган Кызыл Армия сугышчыларының тиңдәшсез каһарманлыклары турында без шәкертләребезнең күңеленә үтеп керерлек итеп сөйләргә тиеш...

Мәктәптә дәресләр тугыз ай элек кенә башланган. Һәм беренче чыгарылыш нәкъ сугыш алдыннан – 1941 елның 20 июнендә була. Әле генә мәктәптән чыгарылган беренче рота егетләренең күбесе шундук фронтка китә.

Җиңү көненә кадәр Казанның тугызынчы махсус мәктәбен 651 курсант тәмамлый һәм аларның шактыена хәрби очышлардан әйләнеп кайту насыйп булмый...

1941 елгы тәүге чыгарылыш курсантларының бер өлеше башлангыч Югары авиация мәктәбенә укуларын дәвам итәргә җибәрелә. Алар арасында Александр Муравьёв (сугыштан соң ул туган мәктәбенә командир һәм әдәбият укытучысы сыйфатында әйләнеп кайтачак) та була. Аның «Девятая Казанская» дигән китабында беренче чыгарылыштагы курсташы Дамир Әюпов белән очрашуы сурәтләнә. Ул кайбер иптәшләренең язмышы белән таныштыра: «Дистәгә якын кеше һәлак булган. Синең белән бер партада утырган Борис Гужавин укчы-радист булган, самолетын 1943 елда бәреп төшергәннәр. Шулай ук Саша Шелымагин, Гриша Назаров, Женя Егоров – барысы да укчы-радист булып очкан. Сорокин белән Евлампиев Сталинград янында пехотада сугышканда һәлак булган. Андреев та шунда ук. Кайдадыр Сюнька Кулик та башын салган... Февральдә исә Рәим Учаров кайтты. Аның да сугышчан биографиясе сокланырлык. 1942 елның көзеннән ЛИ-2 самолетында укчы-радист булган. Берлинны бомбага тотуда катнашкан. Бервакыт, фронт линиясеннән читтә самолетына зыян килгәч, парашют белән сикергән, адашып йөргәч, партизаннар янына килеп чыккан, диверсияләрдә катнашкан, шуңа Кызыл Йолдыз ордены аңа бик кыйммәткә төшкән...»

«ХӘРБИ-ҺАВА УЧИЛИЩЕЛАРЫ ӨЧЕН КАДРЛАР ТУПЛАУ, КЫЗЫЛ АРМИЯ ХһК ОЧУЧЫЛАРЫ ҺӘМ ОЧУЧЫ-КҮЗӘТЧЕЛӘРЕН ӘЗЕРЛӘҮ МАКСАТЛАРЫНДА РСФСР, УССР, БССР, ГРУЗИЯ ССР ҺӘМ ӘРМӘНСТАН ССР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЛАРЫНА МӘГАРИФ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ СИСТЕМАСЫНДА ХӘРБИ-ҺАВА КӨЧЛӘРЕНЕҢ 20 МАХСУС УРТА МӘКТӘБЕН (СИГЕЗЕНЧЕ, ТУГЫЗЫНЧЫ ҺӘМ УНЫНЧЫ СЫЙНЫФЛАР СОСТАВЫНДА) ОЕШТЫРЫРГА ТӘКЪДИМ ИТӘРГӘ».

Совет хөкүмәтенең 1940 елның 6 ноябрендәге 2276 нчы «Хәрби-һава көчләре махсус урта мәктәпләрен оештыру турында»гы карары.

Исемлектә тугызынчы булып торган Казан махсус мәктәбенә Ленин һәм Лобачевский урамнары чатындагы бина бирелә. Бүген ул бинаны РФ Фәннәр академиясенең Казан филиалы били. Сугыш башлангач, анда госпиталь ачыла, махсус мәктәпне исә 6 нчы урта мәктәп бинасына күчерәләр (элекке Мариинск гимназиясе бинасы). Бүген бирердә КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге лицей урнашкан.

Бүген бу тарихи бинада КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге лицей урнашкан, кайчандыр бирердә булачак очучылар әзерләнүен исә бина фасадындагы истәлек тактасы һәм музей искәртеп тора.

ХЫЯЛГА ТАБА!

Гомумән, бөтен махсус мәктәпләр дә бер типта оештырыла. Укыту 8 сыйныфтан башлана, укыту программаларында хәрби эшне өйрәнүгә басым ясала. Махсус мәктәпләр турында нигезләмәгә ярашлы рәвештә аны тәмамлаучыларга унынчы сыйныфтан соң теләсә кайсы хәрби училищега керү мөмкинлеге бирелә.

Махсус мәктәпкә укырга керү җиңел булмый: кандидатларны махсус комиссияләр сайлап ала. Барлык гомуми белем фәннәре, бигрәк тә математика, физика, химия һәм чит телләр буенча белемнәр, сәламәтлек һәм физик әзерлек тикшерелә. «Готов к труду и обороне», Осоавиахим, «Ворошиловский стрелок», парашют спорты һәм башка оешмаларның спорт значокларына ия булу хуплана. Аңлашыла ки, бирегә иң талантлы, белемле һәм спорт яраткан үсмерләр генә эләгә ала.

Әлеге яшүсмерләрнең балачагы да бер үк төрле диярлек: күпләренең әтиләре юк, ачлык-ялангачлык, мохтаҗлык. Шуңа күрә ХҺК махсус мәктәбенә укырга керү аларга исән калырга гына түгел, хыяллары – зәңгәр күккә якынаерга да булыша. Үсмерләрне тулысынча карап-тәрбияләп кенә калмыйлар, аларны иң яхшы педагоглар укыта, хәрби очучы карьерасына әзерләнеп, алар армия чыныгуы үтә.

...Генаның әтисе фронтта һәлак була, әнисе исә, колхозда хезмәт көненә бирелә торган «таяк»ка эшләп, өч баласы белән көч-хәл җан асрый. Шуңа күрә җидееллык мәктәптән соң Генаның укуын дәвам итү мөмкинлеге бөтенләй булмый. Бервакыт авыл советы секретаре Александр Юновидов юлында очраган малайга «Красная Татария» газетасын күрсәтә. Анда ХҺКнең 9 нчы махсус мәктәбенә укучылар җыю турында хәбәр ителгән була.

– Гена, мәктәпне мактау грамотасы белән тәмамладың, сине Казан мәктәбенә имтиханнарсыз кабул итәргә мөмкиннәр, – ди ул үсмергә.

Тиздән Геннадий Ванюрихин махсус мәктәп укучысына әйләнә. 1952 елда аны көмеш медальгә тәмамлый. Бүген ул – техник фәннәр докторы, профессор:

– Мәктәп минем тормышымда хәлиткеч роль уйнады дию һич арттыру булмастыр...

Сугыштан соңгы авыр елларда Казанның иң яхшы урта мәктәпләреннән берсендә уку (мин хәзер дә шулай уйлыйм) минем өчен дә, сугышта әтиләрен югалтып, яшәү өчен нормаль шартлар булмаган авыллардан һәм кечкенә шәһәрләрдән килгән күпчелек үсмерләр өчен дә бәйрәм булды. Безнең белән укучы курсантларның берсе өенә: «Без төнлә ап-ак җәймәләргә ятып йоклыйбыз, иртә белән исә атланмай ягылган ипи ашыйбыз», – дип хат язган иде. Без бу хатны аның тумбочкасыннан «табып алдык» һәм бергәләп укып көлештек. Әлбәттә, бу «әчке эшләргә» тыкшыну иде, әмма мәктәптә кагыйдәләр шундыйрак булды – бездәге хәлләр дә Николай Помяловскийның «Очерки бурсы»* әсәрендә сурәтләнгәннәргә охшаш иде. Ә ачы хакыйкать шунда ки: безнең күпчелегебез моңа кадәр ап-ак җәймәнең дә, иртәнге яки кичке ашка атланмай ягылган ипинең дә нәрсә икәнен белми иде...

* «Очерки бурсы» – Николай Помяловский повесте.

1952 елда мәктәпне көмеш медальгә тәмамлаган Геннадий Ванюрихин. Техник фәннәр докторы, профессор.

Очучы-сынаучы, Советлар Союзы Герое, авиациядә алты дөнья рекорды иясе Георгий Мосолов.

«САМОЛЁТЛАР ҮЗЛӘРЕ ГЕНӘ ОЧА АЛМЫЙ...»

«Тугызынчы Казан» мәктәбен ачканда Туишевка шәһәрнең иң яхшы укытучыларын сайлап алу мөмкинлеге бирелә. Шунлыктан биредә шәкертләр, стройда йөрү, атарга өйрәнү, армия Уставын ятлау һәм хәрби очучы һөнәре үзенчәлекләрен өйрәнү белән берргәттән, башка барлык предмет һәм фәннәр буенча төпле белем алу мөмкинлегенә дә ия була. Бу исә аларның барысының да киләчәк тормышында нык булыша. Мәктәпне тәмамлаучылардан менә дигән авиация инженерлары, конструктор, галим һәм, әлбәттә инде, пилот, очучы-сынаучылар чыга.

...1962 елның сентябрендә тавыш тизлегеннән югарырак тизлек белән оча торган Е-8/1 истребителен сынау тәҗрибә-конструкторлык бюросының шеф-пилоты Георгий Мосолов өчен чак кына фаҗигагә әйләнми кала. Тавыш тизлегеннән югарырак тизлектә самолет кабинасыннан катапультацияләнгәндә ул авыр җәрәхәтләнә. Табиблар аның гомере өчен озак көрәшә, коткарып кала, әмма СССРның атказанган очучы-сынаучысы, Советлар Союзы Герое, полковник, авиациядә тизлек һәм биеклек буенча алты дөнья рекорды (шулардан өчесе – абсолют) авторының очу биографиясе шуның белән төгәлләнә.

Георгий Мосоловның авиациядә эшләү дәвере пешкәкле самолетлардан – реактив, тавыш тизлегеннән акрынраклардан тавыш тизлегеннән югарырак оча торганнарына күчү чорына туры килә. Ул үзе бу турыда менә нәрсә сөйли торган була: «Безгә, әлеге бурычларны беренчеләрдән булып хәл итә башлаучыларга, шунысы яхшы мәгълүм: алга таба ясалган һәр адым конструкторларның

Ике якын дус – Юрий Гагарин һәм Георгий Мосолов.

искиткеч акыл киеренкелеген, эшчеләрнең осталыгын һәм зирәклеген, инженерларның һөнәрмәндлеген, очучы-сынаучыларның эшкә фидаиләрчә тугрылыгын таләп итә иде. Чөнки самолетлар үзләре генә оча алмый. Аларны әле моңа өйрәтергә кирәк».

Аны «Микоян фирмасы тормышындагы тулы бер эпоха» дип йөртәләр – гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул «МиГ» корпорациясе генераль директоры – генераль конструкторының консультанты була. Георгий Мосолов – Казандагы ХһК 9 нчы махсус урта мәктәбен тәмамлаучы 2 мең курсантның берсе. Атаклы мәктәпне ул 1944 елда бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган.

ТӨП УРАМНАН ОРКЕСТР БЕЛӘН

Актлар залыннан ишетелгән тавышлар какофониясе кинәт туктап кала – махсус мәктәптә тәртип шулай да иң мөһиме бит. Егетләр уен коралларын үз урыннарына куя.

– Иртәгә шәхси ял вакытыгызда репетициягә көтәм, – үсмерләр яратып «Дядя Степа» дип йөрткән укытучыларының тавышын барысы да ишетә, музыкантлар уку бүлмәләренә тарала.

Тынлы оркестр! Анда уйнау турында үсмерләрнең барысы да диярлек хыяллана. Һәм тынлы оркестр җитәкчесе, талантлы музыкант, педагог Степан Воронцов беркемне дә кире какмый. Бирегә өлкән сыйныфлар да, яңа гына мәктәпкә кергәннәр дә йөри. Шәһәрдә популяр булган оркестр кайларда гына уйнамый! Бигрәк тә бию кичәләрендә уйнарга ярата. Һәм инде ул чакта тыелган танго һәм фокстрот, падеграс һәм падеспань биюләре аеруча кызыксыну уята…

«СПЕЦ» МОРАТОВ НИЧЕК АКТЁРГА ӘЙЛӘНГӘН

Йөреп аргач, ул ВДНХ янындагы фонтан янына барып утыра, тәмәке кабыза.

Янәшәдәге күзлекле кеше дә тәмәкесен кабыздыртырга сорый, аннары йөзе көнчыгыш якка тарткан, җитмәсә матур очучы формасы кигән егетне кызыксынып күзәтә башлый. Егетнең ВГИК бинасына карап-карап куюын сизгәч, елмаеп сорау бирә:

– Шунда укырга керәсегез киләме?

– Әйе.

– Йәгез, берәр нәрсә сөйләп күрсәтегез алайса.

Егетнең Маяковский шигырен яттан сөйләве ир-атка ошый:

– Иртәгә институтка килегез, 122 нче аудиториягә. Минем янымa, дип әйтерсез…

Чыннан да, бәхетле очрашулар көтмәгәндә була. Шул рәвешле Казандагы 9 нчы махсус мәктәпне тәмамлаган Раднэр Моратов Михаил Роммның үзендә укый башлый. Соңрак ул «Джентльмены удачи» комедиясендә төшеп дан казана, андагы Василий Алибабаевич роле «спец» Моратовны бөтен илгә таныта. Әмма, кызганычка, ул инде зәңгәр күкне буйсындыра алмый…

Футбол, волейбол, тынлы оркестр, бию коллективы, театр түгәрәге, җиңел атлетика, чаңгы, По-2 самолетыннан 800 метр биеклектән парашют белән сикерүләр… Дөрес, соңгысы махсус мәктәпнең укыту программасына керми, әмма егетләрнең бөтенесе дә диярлек ДОСААФ составында була. Бирелә аларның парашют белән сикерүен шәһәр аэроклубы аша оештыралар. Табигый ки, мондый универсаль белем һәм күнекмәләргә ия курсантлар әллә кемнәр була ала – очучыдан алып… актерга кадәр.

Һәм гомумән, аларның нинди һөнәрдә уңышка ирешүе мөһим дә түгел бит. Аларның һәркайсы бу тормышта үз урынын таба…



Александр Серыйның «Джентльмены удачи» комедиясендәге Василий Алибабаевич роле «спец» Раднэр Моратовны бөтен илгә таныта. Әмма, кызганычка, ул инде зәңгәр күкне буйсындыра алмаячак...
Фильмнан кадр.

PRESSA



САМОЛЁТНЫ

Олеся Бондаревская

Казан авиация заводы очу-сынау станциясе очучылары «Татарстан»га сынаучының ни өчен иң шәп һөнәр булуы, күккә нинди сыйфатларсыз күтәрелергә ярамавы һәм иң-иң яхшы самолётлар хакында сөйләде.

РАФАЭЛЬ ЗАРИПОВ, 1 нче класслы очучы-сынаучы

– Очучы һәм очучы-сынаучы – охшаш һөнәрләр. Ә аермасы нидә?

– Пилот серияләп чыгарыла торган самолётларда оча. Очучы-сынаучы исә очкычны беренче булып һавага күтәрә. Без самолётның техник һәм очыш таләпләренә ярашлылыгын тикшерәбез, хәтта нәрсәнедер үзгәртү һәм характеристикаларын яхшырту буенча киңәш тә бирә алабыз.

– Очу – нәкъ менә сезнең язмыш икәнен ничек аңладыгыз?

– Мөгаен, бу һөнәр мине үзе тапкандыр. Симонов исемендәге Сынау-конструкторлык бюросында эшләүче этием киңәше белән өлкән сыйныфларда укыганда ДОСААФка бардым һәм L13 планерында тәүге тапкыр күк белән таныштым. Шуннан бирле гомерем авиация белән бәйләнгән.

– Теоретик һәм практик белемнән тыш, очучы-сынаучы булыр өчен тагын нәрсәдер кирәкме?

– Сынаучылар әзерләү үзгенә үз һөнәренә гашыйк кешеләрне сайлап алалар. Керү имтиханында без «Минем ни өчен очучы-сынаучы буласым килә?» дигән темага инша яздык. Шулай ук стандарт булмаган ситуацияләрдә югалып калмау сәләте дә кирәк. Болар барысы да хезмәт юлының башында ук яхшылап тикшерелә. Мәсәлән, очучылар мәктәбендә теоретик имтиханнарны зур тәҗрибәле һәм дан казанган инженерлар, пилотлар һәм штурман-сынаучылар ала. Алар бик игътибар белән тыңлап тора, аннары исә кисәк кенә провокацион сорау биреп куя, мәсәлән, җәйге кояш торгынлыгы ноктасы бүген кайсы җирдә яки нәрсә ул Фибоначчи саны. Очыш буенча имтиханда яңа техникага һәм яңа ситуациягә тиз арада җайлаша алу сәләтен тикшерәләр. Истребитель урынына сине транспорт самолётына утырталар. Бу җиңел машина йөртүченә зур йөк машинасына утыртуга тиң. Инструктор исә яңа шартларга ни арада җайлашуыңны бәяли.

– Барлык бу сыйфатлар чыннан да кирәк булган хәлләргә юлыкканыгыз булдымы соң?

– Әйе, һәм бер генә тапкыр да түгел. Бервакыт без пассажирлар белән хәрби аэродромнан Ту-134А самолётында очтык. Сигез мең метр чамасы биеклектә кабинаның алгы пыяласы очып чыкты. Самолётта бик каты тавыш – очу тизлеге сәгатенә 600 километр бит! Штурман тавышы ишетелми, һәм аңа курсны кәгазьгә язарга туры килә. Без ашыгыч рәвештә түбәнәябез. Ул чактагы халәтемне хәзергәчә хәтерлим – суламакчы булам, ә сулап булмый. Бәхеткә, төшеп утырдык, куллар гына суыктан күшегеп катты, чөнки биектә, бортның тышында, минус 50 градус салкын иде.

– Сезнең аеруча үз иткән самолетларыгыз бармы?

– Мин 20 ләп типтагы очкыч һәм аларның модификацияләрен тикшердем, үзләштердем, әмма аерып яраткан самолетым юк. Миңа аларның төрле булуы ошый. Менә йөк ташый торган Ан-72 нәрсәсе белән гаҗәпләндерә ала инде? Авыр, бик үк җитез дә түгел. Әмма аның кабинасы бик шәп. Түбәндә генә очасың һәм ачылган манзарага хозурланып барасың. Ә менә Ту-214 тә эргономика һәм автоматлаштыру шулкадәр югары дәрәҗәдә ки, син очып киткәндә һәм төшеп утырганда гына штурвалга тотынасың.

– Сезне эшегездә нәрсә илһамландыра?

– Яңа авиация техникасын үзләштерү. Миңа Казан авиация заводында эшләү, «Туполев» фирмасының легендар самолетларында очу ошый. Биредә җитештерү планлаштырыла торган яңа самолетны тикшерә башлауны түземсезләнеп көтәм.

Фото: Александр Ефремов, Алексей Пилипенко

ОЧАРГА ӨЙРӘТҮЧЕЛӘР

ЛЕВ ВОЛЕГОВ,
1 нче классы штурман-сынаучы

– Сез сынау вакытында адреналин артуын тоясызмы?

– Юк. Адреналин бүленеп чыгу куркуны аңлата, ә очканда куркырга ярамый. Ул ялгыштыра, ә безнең һөнәрдә хәтта бик кечкенә генә хата да һәлакәткә китерергә мөмкин. Очучылар әзерли торган училищеда безгә әйтәләр иде: әгәр очарга куркасың икән, димәк, син әле очышларга әзер түгел. Шунлыктан очу бурычын яхшылап өйрәнү, очышның барлык нечкәлекләрен һәм аны башкару үзенчәлекләрен җирдә чакта ук экипаж белән тикшерү бик мөһим. Куркыныч туганда килеп чыгарга мөмкин хәлләрне кабинада яки тренажерда өйрәнергә кирәк. Безнең әле тагын бер кагыйдәбез бар: белмисең икән – сора. Очыш бурычында нәрсәдер аңлашылмый икән, инженердан, конструктордан аңлатуларын үтен. Үз-үзеңә чиктән тыш ышанганлык та куркыныч.

– Сезнең эштә тагын нишләргә ярамый?

– Үз хаталарыңны машинаның төзексезлегенә яки конструкторларның исәпләүләренә сылтарга ярамый, чөнки бу чынлыкта булмаган кимчелекләрне төзәтүгә китерергә мөмкин. Ә инде техникадан ниндидер канәгатьсезлек бар икән, бу очракта үз позицияңне яклый белергә кирәк. Самолётны файдалануга тапшыру мәсьәләләрендә соңгы сүзне очучылар экипажы әйтә.

– Төрле самолетларда очу бер-берсеннән аерыламы?

– Минем бик күп машинада очканым бар – Ка-27 вертолётыннан алып Ту-160М самолётына кадәр. Алар белән идарә итүдә аерымлыклар бик күп, һәркайсының үз өстенлеге бар. Мәсәлән, вертолётта Кырым яры өстеннән очасың, матур кызлар кул болгый – бик рәхәт. Ә инде бөтен хәрби гамәлләрне үтәргә сәләтле Су-24не иярләгәндә горурлык хисе кичерәсең. Очышта штурман навигация һәм корал куллану өчен җаваплы. Заманча самолетлар – составында катлаулы системалар һәм авиация коралларының төрле чаралары булган авиацион комплекслар алар. Боларның барысын да белергә һәм дөрес файдаланырга кирәк. Ту-22М3 – әлеге җәһәттән иң катлаулы машиналардан берсе. Ул разведка һәм бомба ташлаудан алып канатлы ракеталар куллануга кадәр булган төрле хәрби бурычларны башкарырга сәләтле. Әлеге самолётта бурычымны сыйфатлы башкарганнан соң, мин рәхәтлек хисе кичерәм.



– Сезнең хобби да очышларга бәйлеме?

– Тизлеккә, дисәк, төгәлрәк булыр. Мин тау чаңгысында шуарга, хоккей уйнарга һәм кайвакыт парапланда очарга яратам. Биткә җил бәрә, тизлек, ирек хисе. Минә көндәлек тормышта җитеп бетмәгән нәрсәләр бу.

– Әшегез сезнең гадәти тормышыгызга йогынты ясыймы?

– Авиациядә вак-төяк була алмый, диләр. Бу кагыйдә тормышымда да саклана. Миңа вакыйгаларны контрольдә тоту ошый. Бервакыт мин дусларым – ориентлашу буенча спорт мастерлары белән тауга мендем. Әйберләребезне ташлар астына яшердек, әйләнә-тирәне хәтердә калдырырга килештек. Кире кайтканда, төрлебезнең төрлечә истә калдыруы мәгълүм булды. Мин исә GPS-координаталарны язып куйган идем. Шуңа күрә әйберләребезне бик тиз таптык.

– Шундый катлаулы булса да, ни өчен үз һөнәрегезгә тугры сез?

– Миңа даими уку, яңа авиация техникасын үзләштерү ошый. Мин очышларны һәрвакыт түземсезләнеп көтеп алам. Шуңа күрә яраткан самолетым – мин әле беркайчан да очып карамаганы.

АВИАТҮГӘРӘКТӘН ДӘҮЛӘТ ЗАКАЗЫНА КАДӘР

«ЭНИКС» АҖнең Валерий Побежимов җитәкчелегендәге югары класслы белгечләре үзгәртеп кору елларында предприятиегә килгәндә әле яңа гына авиамодельчеләр түгәрәгеннән чыккан яшьләр була. Бүген алар илнең оборона сәнәгате биргән иң катлаулы заказларны үти – дөньякүләм дәрәҗәдәге пилотсыз очу аппаратлары (БПЛА) җитештерә.

Акционерное общество ЭНИКС

КАИ тәмамлаган өметле яшьләр үзләренең кызыклы тормыш юлын ерак 1980 нче елларда башлый. Энтузиаст, романтик, патриот яшьләр үзгәрә башлаган дөньяда ачылачак мөмкинлекләрне яхшы чамалый һәм үзләренең авиамодельчелек өлкәсендәге белемнәрен җитештерүдә кулланып карау турында хыяллана. Казандагы авиамодельчелек буенча спорт мастерлары һәм СССР җыелмасы әгъзалары югары бәяләнә һәм укуларын тәмамлаганнан соң эшкә билгеләнгәндә үзләре сайлап алу мөмкинлегенә ия була. Ул чакта авиамодельчеләр түгәрәген җитәкләгән Валерий Побежимов амбицияле уйлап табучы-новаторларны яңа фирмасына чакыра.

Генераль директор – баш конструктор **Валерий Побежимов** һәм икътисад һәм финанс мәсьәләләре буенча баш белгеч **Энҗе Побежимова.**

1988 елда Побежимов җитәкчелегендә тикшеренү үзәге оеша. 1997–1998 елларда компания бик катлаулы чор кичерә, кризис вакытында хезмәткәрләр коры энтузиазмда гына эшли. Җитәкчелек тырышлыгы белән команда сакланып кала, һәм 2000 нче еллардан оешма үсешендә яңа дәвер башлана. 2003 елда фәнни-тикшеренү үзәге «ЭНИКС» ЯАҖ әйләнә. Бүген бу компания – төрле билгеләнештәге пилотсыз авиация комплекслары уйлап табу һәм җитештерү буенча илдә әйдәп баручылардан берсе.

Биредә барлыгы 300ләп кеше эшли. Хәзер «ЭНИКС» идеядән алып яңа техниканы чынбарлыкка әйләндерү, анда эшләргә өйрәтүне һәм соңыннан хезмәт күрсәтүне дә башкара торган тулы циклны җитештерүгә ия заманча предприятие булып тора. Предприятиенең җыю цехларында тәүлек буе эш кайный, компьютер белән идарә ителешле станоклар шаулый, конструкторлар яңа БПЛА сызымын сыза, аларга дигән электроника һәм кирәкле детальләр ясала. Компаниянең аеруча горурлана торган ачышы – үзен үзе программалар белән тәэмин итүе, илдәге әлеге ноу-хауны бөтен чит ил инвесторлары кулга төшерергә тырыша.

– Мине дә оешмага нигез салучыларның берсе дип атый аласыз, мин биредә беренче көннәрдән үк. Шулай ук авиамодельче, тема миңа бик якын, һәрвакыт шуның белән шөгыльләнәсем килде. Хәзер бөтен тормышым пилотсыз авиациягә бәйле, моңа 35 елдан артык гомеремне багышлаганмын, – дип сөйләде юнәлеш буенча баш конструктор Илдар Рәис улы Якупов. – Безне ул чакта чыннан да банда, Кулибиннар дип йөртә иделәр. Барысы да безнең менә

Фотолар «ЭНИКС» АҖнән алынды. РЕКЛАМА

шул фикердәшләр командасыннан башланды. Шунлыктан без компанияне шәхси вакытыбызны да кызганмыйча, катлаулы финанс хәлләре белән дә исәпләшмичә күтәрергә тырыштык. Без алдыбызга һәрвакыт максат куя һәм шуңа омтыла идек – һәм бу нәтиҗә бирде дә.

– Бирегә мин 1984 елда килдем. Монтажчы булып эшләдем, аннары югары белем алып, конструктор булдым һәм Илдар Рәис улы командасында җитәкче вазыйфасына кадәр күтәрелдем, – дип сөйләде юнәлеш буенча баш конструктор урынбасары Сөләйман Әнвәр улы Саттаров. – Хәзер биредә инде балаларыбыз да эшли – улым Айрат, кызым Илсөя. Икесе дә инженер-конструктор.

«ЭНИКС» – тулы цикллы җитештерү: планерның үзен төзүдән алып аның бортындагы радиоэлектрон җиһазларга кадәр, беренче сызымнан алып инде файдаланганда сервис хезмәте күрсәтүгә кадәр. Казан компаниясендә җитештерелә торган продукциянең төп кулланучылары – Россия Федерациясе Оборона министрлыгы һәм көч структуралары. «ЭНИКС» АҖнең фәнни-тикшеренү эшкәртмәләре – пилотсыз аппаратлар тармагындагы иң актуаль чишелешләр ул, еш кына Көнбатыштагы үрнәкләрдән өстенрәк булалар һәм илебез хәрбиләренә сугыш кырында иң мөһим бурычларны хәл итәргә, безнең солдатларның гомерен саклап калырга, уңышлы разведка үткәрергә булышалар. Татарстанда җитештерелгән югары сыйфатлы җайланмаларны хәзер илнең төрле почмакларында – Калининградтан алып Курилга кадәр очратып була.

– Без барыбыз да авиамодельчеләрдән чыккан, мин үзем халыкара класслы спорт мастеры. Коллективка 1983 елда Валерий Николаевич чакыруы буенча килдем. «ЭНИКС»ның уңыш сәбәпләреннән берсе – бердәм коллектив булуыбыз, без бер-беребезнең ничек яшәвен белеп торабыз, кунакка йөрешәбез, бергәләп походка һәм балыкка йөрибез. Бик авыр вакытларда да без моның вакытлы күренеш икәнен аңлап яшәдек. Шулай булып чыкты да, – дип искә алды югары квалификацияле сынау белгече, тәҗрибә җитештерүенең ябыштыру участогы бригадиры, предприятиедәге яшь кадрларның остазы Зөфәр Котдус улы Ваккасов. – Бүген очу аппаратлары ясыйм – биредә җитештерелә торган барлык модельләргә дә минем дә өлешем кергән. «ЭНИКС» компаниясендә эшләү дәверемдә композицион материаллардан 1000нән артык фюзеляж, канат һәм төрле детальләр ясадым. Бөтен самолетлар да минем кул аша үтте.

Һичшиксез, һәрвакыт оешманың таянычы булган лаеклы хезмәткәрләр арасына исәп-хисап һәм салымнар өлкәсендә югары класслы белгеч, баш бухгалтер Зифа Сәлим кызы Конованы һәм икътисад һәм финанс мәсьәләләре буенча баш белгеч, фирма ветераны Энҗе Миһран кызы Побежимова кебек финанс белгечләрен дә кертергә кирәк. Компания әле кооператив кына булган чакта Энҗе Миһрановнага баш бухгалтер да, планчы да, кадрлар бүлеге хезмәткәре дә, юрист та булырга туры килгән.

Шунысын да аерып әйтергә кирәк: «ЭНИКС» коллективы принциплары арасында актив тормыш позициясе һәм сәламәт яшәү рәвеше дә мөһим урын алып тора. Шунлыктан компаниянең үз хоккей командасы булуы бер дә гаҗәп түгел. Аның капитаны һәм тренеры – механика-җыю эшләре слесаре (тәҗрибә җитештерүе) Зөфәр Рәхим улы Идиятуллин. Боз дружинасы составында 19 кеше исәпләнә, араларында хезмәткәрләрнең балалары да бар. 2020 елның гыйнварында Казанда үткән Бөтенроссия кышкы корпоратив фестивальдә ул үз төркемендә беренче урын яулаган.

– БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА НИНДИДЕР ӨР-ЯҢА НӘРСӘ ЯСАРГА ТЕЛӘҮЧЕ ЭНТУЗИАСТЛАР ИДЕК ҺӘМ ХӘЗЕР ДӘ ШУНДЫЙ. ЕЛЛАР УЗГАН САЕН, БАРЛЫК ВАКЫЙГАЛАРНЫ ХӘТЕРЕМНӘН ҮТКӘРӘМ ДӘ, ДӨРЕС ЮЛ САЙЛАВЫБЫЗГА ТАГЫН БЕР КАТ ИНАНАМ. «ЭНИКС» ИНДЕ МЕНӘ 30 ЕЛДАН АРТЫК ОЧЫШ ТРАЕКТОРИЯСЕНДӘ! – ДИ КОМПАНИЯ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЛЕРИЙ НИКОЛАЕВИЧ ПОБЕЖИМОВ.

– Иң зур ихтыяҗлы эшләнмә – Е95М мишене, күпләргә яхшы мәгълүм «Игла» һәм «Панцирь» һава һөҗүменнән саклану системалары шуңа атып өйрәнә. Без 800 дән артык шундый мишень ясадык. Шулай ук берничә йөз данә пилотсыз разведка аппаратларын җитештердек. БПЛА белән җиһазландырылган Россия подразделениеләре, куелган бурычны үтәгәндә, күбрәк күрә һәм үзләрен күпкә куркынычсызрак тоя, – дип хисап тотты генераль директорның беренче урынбасары Игорь Владимирович Нагибин. – Пилотсыз разведка кайнар нокталарда безнең хәрбиләрнең гомерен саклый. Шәхси составлары югалтуга дучар булмаган хәрбиләр еш кына җитештергән продукциябез өчен рәхмәт сүзләрен җиткерә. Сүз уңаеннан, 2020 елгы армия өйрәтүләрендә безнең техника белән эшләгән Россия командасы беренче урын яулады.

«ЭНИКС» АҖнең хоккей командасы.

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Татарстан авыллары
Яңалыклар

Реклама 16+

акыллы гамәлләр
игелекле эшләр
мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Пастернак Чистайны **ник** яраткан

Чистай башлыгы дөньяны **ничек** җиңгән

Тәтештә туристларны **ничек** каршы алалар

«Бакырчы» Россия Куркынычсызлык Советы Секретарен **нәрсә** белән шаккатырган

ҖАНҖЫЛЫМЛЫ ЧИСТАЙ КАЛАСЫ

Татьяна Вафина

Чистай районы башлыгы Дмитрий Ивановның яраткан шәһәренә мөнәсәбәте бөек рус шагыйре һәм язучысы Борис Пастернакныкыннан һич аерылмый: «И мил моему сердцу Чистополь, и зимы в нём, и жители, и дома...» – дип язып калдырган бит классик. Борынгы өяз шәһәренең бөтен матурлыгын саклаган әлеге җыйнак каланы яратмаска мөмкин түгел, дип саный башлык та.

– Мин мондагы Чистай Выселкасы авылында туып-үстем, шунда укыдым, эшләдем, – ди Дмитрий Алексеевич. – Аннан озак кына Казанда яшәдем. Ә инде миңа Чистай районын җитәкләргә тәкъдим иткәч, туган ягыма әйләнеп кайттым, һәм моңа һич үкенмим. Хатыным да бу якның гаҗәеп матурлыгын белеп алды, беркая да китәргә җыенмый. Зур шәһәргә караганда, биредә уңайлырак, чөнки гомер, яшәеш агымы бөтен нәрсәдә сизелә: күктә агылган болытларда да, яңгыр шыбырдавында да, дулкыннар шавында да, чәчәкләр исендә дә. Монда тормыш ашыкмый гына тәгәри, мегаполислардагы кебек яныңнан выжылдап узып китми, һәм бу тормыш Чистайның үзе кебек, аның борынгы урамнары, сырлы тәрәзә йөзлекләре, сәүдәгәр йортлары, елмаюлы йөзле кешеләре кебек матур... Һәм иң мөһиме – юлда бернинди «бөке»ләр дә юк!

Соңгысы бигрәк тә сөендерә, шуңа күрә җитез генә машинага утырабыз – Татарстандагы иң уңайлы һәм җанга җылы бирә торган өяз шәһәре башлыгы белән көн буе бергә булачакбыз.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТЕХНИКУМЫ – КАДРЛАР ЧИШМӘСЕ

Дмитрий Ивановның тормыш һәм хезмәт юлы белән танышканда, белем алу белән бәйле пунктлар санына шаккатасың. Биредә авыл хуҗалыгы белгечлекләре дә, педагогик белгечлекләр дә, хәтта аучылык та бар... Ул – «авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү, су бүлү һәм юынтык суларны агызу системасы инженеры» да, дәүләт-иҗтимагый идарә магистры да. Сингапурда да, «Сколково»да да, Европа эшмәкәрлек берлегендә дә стажировка үткән. «Дәүләт һәм муниципаль идарә структурасы – Австрия тәҗрибәсе», «Менеджментның заманча технологияләре һәм аларны дәүләт идарәсе реформасында куллану», «Моношәһәрләрне үстерү проектлары белән идарә итә торган командаларны укыту юнәлешендә һөнәри әзерлек», «Цифрлы икътисад шартларында нәтиҗәлелек белән идарә итү» программалары буенча да белем эстәгән...

– Район башлыгы эшендә кайсы белемнең аеруча кирәге чыкты соң?

– Иң әүвәл – үзебезнең Чистай авыл хуҗалыгы техникумында алганы. Монда иң төп нигез салына. Бу техникумны төрле район башлыклары тәмамлаган: араларында бүген бу вазыйфаны башкаручылары да, ул эштән

Фото: Александр Ефремов

инде киткәннәре дә бар. Минемчә, Кама аръягы зонасында әлеге уку йорты – төп кадрлар чыганагы, чөнки база бик көчле иде. Мин укыган вакытта анда ике белгечлек бар иде: авыл хуҗалыгын электрлаштыру һәм авыл хуҗалыгын механикалаштыру. Механика юнәлешен тәмамладым, ягъни мин – авыл хуҗалыгы машиналары буенча дипломлы механик.

СПОРТ ТУРЫНДА ХЫЯЛ

– Бу хыял идеме?

– Юк. Хыялым – Әлмәт спорт техникумына укырга керү иде, спорт белән җитди шөгыльләнәсем килде. Тик эти-эни һәм мәктәп директоры: «Башта безнең техникумны тәмамла, ә аннары җаның ни тели...», – дип күндерделәр. Кыскасы, монда укыдым һәм параллель рәвештә спорт белән дә шөгыльләндем. Миңа бәхет елмайды: укытучым Әдип Салихҗан улы Нуруллин иде, хәзер инде мәрхүм ул. Ул мине грек-рим көрәшенә өйрәтте. Ул һәм минем сыйныф җитәкчесе Рәхмәтулла Әкмал улы Гомәров спорт карьерама бик зур өлеш керттеләр.

Армиядән дә уңдым – Казандагы Суворов училищесында хезмәт иттем, генералны йөрттем, ә ул миңа тренировкаларны дәвам итәргә һәм Россия ярышларына барырга мөмкинлек тудырды. Армиядән соң да спорт белән шөгыльләнүне туктатмадым. Классик көрәштән соң армрестлингка күчтем. Ул чакта кул көрәше шактый яңа спорт төре иде, без бер-беребез белән көч сынашып шөгыльләндек. Шулай итеп мин Россия җыелма командасына эләктем. Аннары исә ил чемпионаты, соңрак Европа, дөнья чемпионаты...

– Шундый тыйнак кына сөйлисез... Дөнья чемпионаты турында аеруча кызык безгә.

– Мин халыкара класслы спорт мастеры. Һиндстанның Гувахати шәһәрендә (Ассам штаты) узган дөнья чемпионатында җиңү яуладым. Мәскәүдә Европа чемпионы булдым. Ә Россия чемпионатында Екатеринбургта җиңдем.

– Һиндстанда кемне җиңдегез?

– Финалда словак Янгер Манус белән очраштык. Ул вакытта дөнья чемпионы иде инде ул. Без аның белән күптәнге көндәшләр. Израильдә үткән Европа беренчелегендә мин аңа оттырдым – икенче урын алдым, ул – өстен калды. Ә дөнья чемпионатында мин җиңдем.

ЧИСТАЙЧА СПОРТ

Спорт турында сөйләшә-сөйләшә, Чистайдагы спорт объектларын карап чыгабыз. Бу корылмалар бөтен җирдәге кебек стандарт түгел, аларда Чистайга хас нindидер үзгәлек тоемлана. Борынгы урамнар һәм сәүдәгәрләр йортлары белән бик килешеп, яраштырып төзелгәннәр. «Татнефть-Олимп» стадионына кызыл кирпечтән салынган арка капка аша узасы. Шулай ук стадионның администрация бинасы фасады да «борынгыча» итеп эшләнгән. Скейт-парк һәм велодром да гомум манзараны һич бозмый, киресенчә тулыландыра гына. Шушында ук эскәмияләрдә бишекле арба белән һава суларга чыккан әниләр ял итә – Чистайның көндәлек хозурлыгы бу.

Ә «Лидер» спорт мәктәбендә вакыт минутлап язып куелган – чистайлыларда спортка хөрмәт зур. Башкача була да алмый: район башлыгы – дөнья чемпионы ич! Үзе үрнәк күрсәтә. Мәктәп директоры Венера Уразгилдиева район башлыгы һәм аңа чемпионлык мәсьәләсендә тиң көндәш өчен иң яхшы армрестлинг өстәлен әзерли.

1

– Монда тормыш ашыкмый гына тәгәри, мегаполислардагы кебек яныңнан выжылдап узып китми, һәм бу тормыш Чистайның үзе кебек, аның борынгы урамнары, сырлы тәрәзә йөзлекләре, сәүдәгәр йортлары, елмаюлы йөзле кешеләре кебек матур... һәм иң мөһиме — юлда бернинди «бөке»ләр дә юк.

2

Ә «Лидер» спорт мәктәбендә вакыт минутлап язып куелган — чистайлыларда спортка хөрмәт зур.

3

Венера Уразгилдиева — армрестлинг буенча Россия, Европа, дөнья чемпионы, халыкара класслы спорт мастеры, Россиянең атказанган спорт мастеры! Менә сиңа мә, тыйнак өяз шәһәрчеге генә диярлекме соң!

Үзе дә аның белән кул көрәштереп алырга каршы түгел. Венера Фоат кызы да – армрестлинг буенча Россия, Европа, дөнья чемпионы, Россиянең атказанган спорт мастеры! Менә сиңа мә, тыйнак өяз шәһәрчеге генә диярлекме соң!

– Аңлавымча, Чистайда кул көрәше бөтен дөньядан алда бара?

– Безнең мәктәп укучылары хәзер Татарстан җыелма командасының нигезен тәшкил итә. Румыниядә узган дөнья чемпионатында ике кызыбыз – Ирина Прусакова һәм Әдилә Фаздалова чемпион исемен яуладылар. Ә егетләрдән җиде кеше 2–3 нче урыннарны алды.

Россия җыелмасының өчтән бер өлеше чистайлылардан тора дип әйтергә була. Венера Уразгилдиева бу мәсьәлә белән бик җитди шөгыльләнә. Безнең спорт мәктәбе яңа спортчылар үстерә.

– Ә Сез үзегез хәзер шөгыльләнәсезме?

– Үзем өчен генә. Йөзәм, өйдә күнегүләр ясыйм, вакыт булганда, спортзалга йөрим. Иртән эшкә барганчы велосипедта йөрергә яратам. Иртә торам, сәгать дүрттә инде уянган булам. Шулай гадәтләнгән.

– Ә хәзер дөнья чемпионатында җиңә алыр идегезме?

– Ветераннар арасында, бераз әзерлек узгач, мөмкиндер. Ә яшьләр белән... Анысы дөрес булмый инде.

– Дөрес булмасын, ди, теоретик яктан карaганда гына, аларны егып сала аласызмы?

– Юри бирешеп ятмаячакмын инде, анысы хак.

МАТУР НӘТИҖӘ

– Кызганыч, сез бу урынны яз көне күрмәдегез, – ди Дмитрий Алексеевич, бүген шәһәр китапханәсе урнашкан борынгы сәүдәгәр йортына ымлап. – Без монда сакуралар утырттык. Тирә-ягында гел сакура бакчасы, ул гаҗәеп матур чәчәк ата. «Нигә утыртасыз инде шуларны», - сүгүчеләр дә булды, янәсе, безнең климатта сакура үсмәячәк. Җайлашып үсеп киттеләр. Җиде ел инде безне искиткеч чәчәкләре белән сөендерәләр.

Район башлыгы вазыйфасында һәрвакыт әнә шулай. Каршылыкны җиңә белергә, куелган максатка таба барырга һәм көтә белергә кирәк. Үз хезмәтеңнең нәтиҗәсен күрер өчен, кайчак әллә ничә ел таләп ителә. Предприятиеләр озак төзелә, программалар да бер ай эчендә тормышка ашырылмый, тик соңыннан, нәтиҗәне күргәндә, хезмәтеңнең юкка түгеллеген һәм, иң мөһиме, бу нәтиҗәнең матур килеп чыкканын аңлыйсың. Һәм бу – эшебездә иң яхшы бүләк.

РЕСПУБЛИКАНЫҢ ТАРИХИ ҮЗӘГЕ

– Авыл хуҗалыгы да, җитештерү тармагы да, туризм да үсеш алган районда сезгә кайсы якынрак? Нәрсә белән шөгыльләнү, нәрсәне алга таба үстерү, күтәрү кызыграк?

– Санкт-Петербургтагы «Стратеглар» форумында «Чистай-2020» программасын яклап беренче урынны алдык. Ә аннары, ике елдан соң, без инде бу программаны гамәлгә ашыру буенча беренче урынны яуладык. Анда барысы да анык язып куелган: авыл хуҗалыгы да, сәнәгать үсеше дә, туризм да.

Туризмга килгәндә, без хәзер БРИКС банкының зур проектын тормышка ашырабыз, ул шәһәрнең иске өлешен төзекләндерүне күздә тота. Музейлар, тарихи биналар белән бәйле уналты туристлык объекты тулысынча ремонтланачак. Чистайда кешеләре башка йортларга күчерелгән, туристлык мирасы объектлары булып торган биналар бар, аларда «Бер сумга бизнес» программасы тормышка ашырыла. Эшмәкәрләр бинаны бер сумга сатып ала, өч ел эчендә алар аны төзекләндерергә, кабат торгызырга тиеш: кемдер анда кафе, кемдер кунакханә ача, кемдер офис итеп файдалана.

4

5

– Чистай дөнья мәйданына ни белән чыга ала? Чит ил кунаклары каршында нәрсә белән мактанырга, аларны нәрсә белән шаккатырырга була?

– Чистай сәүдәгәрләр чорыннан башланган бик бай тарихка ия. Беренче гильдия сәүдәгәрләре Челышевлар, Шашиннар, Мамонтовлар, Мельниковлар, Поляковлар – бөтен дөньяга билгеле, алар икмәк сату белән шөгыльләнгән. Чистай, гомумән, үзенең икмәк сәүдәсе белән танылган, биредә тегермәннәр дә күп булган. Әле сугыш вакытында монда язучылар яшәгән, шул исәптән Нобель премиясе лауреаты Пастернак та. Ул биредә «Ромео һәм Джульетта»ны тәрҗемә иткән, «Доктор Живаго» әсәрен яза башлаган, димәк, монда туристларны җәлеп итә торган тарихи сәхифәләр җитәрлек.

Шәһәрнең географик урыны да бик шәп. Ул Чулман елгасы буенда, Татарстан Республикасының нәкъ уртасында урнашкан. Каланың тарихи үзәгенә карасагыз, анда һәр объект һәйкәл булып тора. Безнең Чистай үзәгендә 200 дән артык һәйкәл бар.

– Ә Сезнең яраткан урыныгыз нинди?

– Миңа бөтен шәһәр җандай якын. Скарятин бакчасында йөрергә яратам. Язын исә – сакура бакчасында. Яр буенда... Бу арада яр буе белән бәйле зур проектны тормышка ашырабыз, «Тарихи җирлекләр» конкурсында 80 миллион сумлык грант оттык, хәзер исә әнә шуны яр буен төзекләндерүгә тотабыз. Былтыргы грант акчасына тротуарны алыштырабыз, шәһәр үзәген төзекләндерәбез.

БЕР УРЫН БАР

– Рәхәтләнеп ял итеп, көч ала торган урынны атый аласызмы?

– Бер урын бар. Ак тау каршында ул. Бик зур сөзәк тау бите анда, ә аста елга ага. Әнә шул тау битенә менеп баскач, дистәләрчә чакрымга сузылган манзара ачыла, ә аста тау елгасы агып ята, дигән хис туа. Йөрәк лепердәп тибә башлый. Бу бик үзенчәлекле урын. Гражданнарны кабул иткәннән соң, шунда юл тотам. Кешеләрнең моң-зарларын тыңлагач, барысын да йөрәгем аша үткәрәм. Бик авыр халәт ул. Кеше килеп күңелен бушата, җиңеләеп кала да чыгып китә. Ә син шул йөк белән каласың. Йөк бик авыр булса, монда юнәләм. Шушында килеп басып, кулларыңны җәеп җибәрәсең дә бөтен матурлыкны күреп хозурланасың – шуннан соң яңадан тугандай кебек буласың. Ун минут тулысы белән җитә – хәлем яхшыра, мин янә сафта.

ИГЕЛЕКЛЕ ҺӘМ БӘЙСЕЗ ХОЛЫКЛЫ

– Ә чистайлылар, гомумән, нинди рәк халык?

– Алар бик игелекле һәм бәйсез холыклы. Бу шәһәрне беркем дә, беркайчан да көч белән яулап ала алмаган. Һәм беркем дә аңа үз ихтыярын көчләп тага алмый. Чистай белән килешергә-сөйләшергә кирәк. Хезмәт сөючән, бик куәтле кала, шуңа күрә шәһәр белән үзара аңлашу юк икән, берни дә барып чыкмаячак. Чистайның җаны бар, һәм сез, мөгаен, бүген моңа үзегез дә инангансыздыр.

АҺ ИТЕП КИТӘРЛЕК

– Ә әлегә тормышка ашмаган хыялыгыз бармы?

– Мин дөнья чемпионы булырга хыялландым һәм булдым да. Хәзерге шәхси хыялларыма килгәндә, алар инде бөтенләй үк шәхси дә түгел. Әйтик, бүген шәһәрне туристлар өчен уңайлы итү өчен зур акчалар кирәк. Чистайга ел саен 60 мең турист килә, безгә теплоходлар йөри, димәк, елга вокзалын тулысынча яңарту сорала. Шәһәребездә нибары ике кунакханә эшли. Өч көнгә генә булса да килсен өчен, турист кешегә яхшы шартлар тудыру зарур. Шуңа күрә хәзерге хыялым шундый: кешеләр, Чистайны килеп күреп, аһ итеп китәрлек булсын!

4

Чистайдагы спорт корылмаларында Чистайга хасниндидер үзгәлек тоемлана. Борынгы урамнар һәм сәүдәгәрләр йортлары белән яраштырып ясалганнар. «Татнефть-Олимп» стадионына кызыл кирпечтән салынган арка капка аша узасы.

5

Дмитрий Иванов яшь чистайлылар белән скейт-паркта.

6

– Шушында килеп басып, кулларыңны җәеп җибәрәсең дә бөтен матурлыкны күреп хозурланасың – шуннан соң яңадан тугандай кебек буласың.

БАРЫСЫ ДА ЧЕМПИОННАРЧА БУЛСЫН!

Шәһәр буйлап соклана-соклана сәяхәт иткәндә, игелекле һәм хөр чистайлылардан үз башлыклары тарафына әйтелгән бик күп җылы сүзләр һәм рәхмәтләр ишеттек.

– Без Дмитрий Алексеевичка уртак нәтиҗәле эш өчен рәхмәтле, – ди Кама торба изоляциясе заводы директоры Дмитрий Бобков. – Дус кеше буларак, Дмитрий Ивановка көч, сәламәтлек һәм алга таба да югары үрләр яулавын телим. Ул безнең дөнья чемпионы бит – аның тормышында барысы да чемпионнарча булсын!

***

– «Хезмәт җитештерүчәнлеге» милли проекты кысаларында район башлыгы һәм Татарстан компетенцияләре төбәк үзәге ярдәме белән бездәге «Новые технологии» ширкәтендә җитештерү процессларын оптимальләштерү эше алып барыла, – дип сөйли предприятие җитәкчесе Евгений Игнатов. – Дмитрий Алексеевичка барлык хыялларының чынга ашуын, теләкләренең үтәлүен телисе килә. Һәм, әлбәттә инде, нык сәламәтлек һәм гаилә иминлеге! Эшләрегез һәрвакыттагыча шулай уңышлы барсын!

***

– Районда алып барылган сәясәт һәм Чистай районы башлыгы ярдәме белән «Квест» компаниясе (яктылык диодлы яктырту җиһазлары һәм автоматлаштырылган идарә системаларын җитештерә) трансформаторлар һәм электр компонентлары җитештерүне күздә тоткан импортны алыштыру проектын башлап җибәрергә ниятли, – дип сөйли «Квест» ҖЧҖ директоры Радик Ильясов. – Дмитрий Алексеевичны юбилее белән котлап, аның һәрвакыт шулай бар өлкәдә компетентлы, теләсә кайсы проблеманы үзенеке сыман кабул итүче, һәр эшне бик яхшы итеп башкарырга омтылучы шәхес булып калуын телим. Сезгә бәхет, уңышлар насыйп булсын һәм эшегез һәрвакыт бүгенгедәй мавыктырсын!

ТӘТЕШ: ҖАНГА ЯКЫН ЭШ

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН

Фото: Әскәр Сабиров, «Татарстан» журналы архивы, Тәтеш муниципаль районы сайты. РЕКЛАМА

Ничек, сезнең әле Тәтештә булганыгыз юкмыни? Сәяхәткә һәвәс туристлар мохитендә бүген бу сорау сүзсез шелтә кебек яңгырый. Гигант кырпы балыгы һәйкәле янында фотога төшмәү яки Молоствовларның алпавыт утарында булмау – башкаланы барып күрмәүгә тиң: болай ярамый! Гаҗәпме? «Юк, бу – нигезле гаепләү», – дип саный Тәтеш районы башлыгы Рәмис Сафиуллов та. Һәм бер сан атый: 130 мең. Идел буендагы тыйнак кына кечкенә кала быел шулкадәр сәяхәтчене кабул итәргә әзер.

Сафа Гәрәев

Провинциаль Тәтештәге борынгы сәүдәгәрләр каласы аурасын саклап калган купшы йортлар арасында – идеаль юллар. Һәм көндез кояштан энергия туплап, төнлә яктырып күренә торган юл билгеләре. Төсле музыкалы фонтан һәм көмеш сулы буа яр буйлары – барысы да авангард, заманча. Пөхтәлек буенча исә Тәтеш күп көндәшләреннән бер башка өстенрәк.

РАРИТЕТЛАР БИХИСАП

– Безнең өчен 130 мең турист та чик түгел. Бурыч – 200 мең кунак кабул итү, – дип гаять зур планнары белән бүлешә Рәмис Хатыйп улы. – Бу чынга ашарлыкмы? Менә үзегез уйлап карагыз: 2017 елда безгә 45 мең турист килгән. Аннан алты ел элек 13 тапкыр (!) азрак булган. Былтыр исә без инде 109 мең сәяхәтчене кабул иттек! Без, алма пеш, авызыма төш, дип ятмыйбыз – гел яңа туристлык марш-

рутлары тәкъдим итәбез, Аллаһка шөкер, районыбызда һәйкәлләр, истәлекле, уникаль урыннар җитәрлек.

Вшиха тавыннан искиткеч манзара ачыла. Иделдәге иң озын баскыч. Укчылар арбалеттан атарга рөхсәт итә торган каравыл каланчасы. Бер гасырлык карагачлар үсеп утырган Мәхәббәт аллеясы булган чын алпавыт утары. Ниһаять, тиңдәшсез интерактив балыкчылык музее, анда үзеңне узган гасыр балыкчылар артелендә итеп тоя, ятьмә үрергә өйрәнә аласың, яңа гына пешеп чыккан уха белән сыйланасың. Һәм хәтта паранормаль алан да бар, риваятьләр буенча, анда болгар сугышчыларының җәрәхәтләре ике тапкыр тизрәк төзәлә торган булган...

Тәтештәге истәлекле урыннарны санап чыгу гына да бөтен эшне ташлап бирегә киләргә мәҗбүр итәрлек. Ә акча кайдан табалар соң биредә, дип сорар өчен иң кулай вакыт. Кайдадыр музейлар көчкә очын-очка ялгап яши, биредә исә яңаларын ача торалар – мәсәлән, шул ук Балыкчылык тарихы музее моннан берничә ел элек кенә эшли башлаган иде.

– Иң мөһиме – яхшы идея һәм аны гамәлгә ашыру теләге, – ди Сафиуллов. – Бурыч куелган икән, аны һичшиксез хәл итеп булачак. Төбәкне өйрәнү музее директоры Наталья

1
Укчылар арбалеттан атарга рөхсәт итә торган каравыл каланчасы.



2, 3, 4
Уникаль Балыкчылык тарихы музеенда үзеңне узган гасыр балыкчылар артелендә итеп тоя, ятьмә үрергә өйрәнә аласың һәм яңа гына пешкән уха белән сыйланасың.

Понедельникова һәм аның командасы – креатив идеяләр капчыгы. Тәтешкә су юлы белән килүче туристларны бездә югары дәрәҗәдә каршы алалар: шәһәр башлыгы шәхси рөхсәт бирә, милли киемнәрдәге кызлар рус, татар, мордва телләрендә җырлап сәламли. Туристларга бик ошаган тагын бер нәрсә – музейда төнәтмә белән сыйлану, аны борынгы рецептлар буенча ясыйлар.

Тәтешлеләрнең креатив идеяләре грант артыннан грант яулый – федераль һәм республика күләмендә җиңеп алган грантларга барлыгы дистәдән артык проект тормышка ашырылган инде, шул исәптән Балыкчылык тарихы музее да. Быел тагын бер проект гамәлгә ашарыла. Нинди икәне әлегә сер.

Табигый ки, җирле хакимият тә идеяләрне хәлкадәри хуплап тора. Молоствовларның уникаль утары экренләп реставрацияләнә – әйләнә-тирәдә сакланып калган башка бер дворян утары да юк.

– Безнең өчен туристлык – үзебезне күрсәтү мөмкинлеге генә түгел ул. Бу – әлегә аз гына булса да бюджет кереме. Тагын да мөһимрәге – яңа эш урыннары һәм лаеклы хезмәт хакы, – дип аңлата Рәмис Сафиуллов. – Төп бурыч – тәтешлеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту бит. Биредә җитди үзгәрешләрсез берничек тә булмый.

Бигрәк тә район халкының күпчелеге хезмәт куйган авыл хуҗалыгында. Биредә исә үзгәрешләр шулкадәр саллы ки, тагын бер, бу юлы инде аграр, туристлык маршруты ачарлык.

ЭКСПОРТКА АШЛЫК – ФАНТАЗИЯ ТҮГЕЛ

Бер ун ел элек кемдер, районда тәүлегенә 100 тонна сөт алачаклар, дисә, аны көлкегә калдырырлар иде. Ул чакта Тәтеш терлекчеләре тәүлегенә кырык тонна сөт җитештергән һәм, нәтиҗәләр таблицасының арттан беренче-икенче юлларын биләп, республика буенча иң соңгы урыннарда барган. Монннан сигез ел элек районны җитәкли башлаган Сафиулловның әлеге саннарны исенә төшергәндә хәзер дә кәефе китә әле. Ул аңарчы авыл хуҗалыгында уңышлы бизнес белән шөгыльләнгән, шунлыктан элек булган терлек, иске технология һәм савымнарның тупикка гына китерәсен яхшы аңлаган.

– Элек бөтен сыерлар диярлек лейкоз белән чирләгән, без исә нибары ике ел эчендә бөтен малны диярлек алыштырдык. Соңгы елларда мең башка якын нәселле тана сатып алдык. Башка чара юк иде, – дип сөйли Рәмис Хатыйп улы. – Бүгенге 100 тонна – терлекчелектәге кардиналь үзгәрешләр нәтиҗәсе ул.

Иркен сулап куярга да мөмкин кебек. Тәтешлеләр бүген сөт саву буенча яхшы бара, шартлар охшаш булган күрше районнарны узып та киткән. Әмма хәзер инде Сафиулловка абсолют лидерларның нәтиҗәләре тынгы бирми: ә без нәрсә, алардан начарракмыни? Заманча югары технологияле фермалар, иң яхшы җиһазлы саву заллары, азык әзерләү үзәкләре... – болар барысы да хуҗалык итүнең элекке методларын экренләп кысрыклап чыгара бара.

Ул табигате буенча максималист, сүздә түгел, тормышта. Кул астындагылардан да шуны ук таләп итә. Грамоталы менеджмент, максатларны дөрес куя белү – иң мөһиме. Нәтиҗәләр дә шуңа бәйле. 2020 елда тәтешлеләр, гектарыннан уртача 46,5 центнер уңыш алып, 206 мең тонна ашлык җыйган – рекордлы сан, республикада икенче күрсәткеч. Шикәр чөгендеренең уңдырышлылыгы буенча исә районга бөтенләй тиңнәр табылмаган.

Әлеге нәтиҗәнең очраклы булмавын узган ел да раслаган. Аграрийларны искиткеч корылык сынаса да, бөртеклеләрнең уңышы буенча тәтешлеләр республикада кабат икенче урынга, шикәр чөгендере буенча исә тагын беренче урынга чыккан... Башкача була да алмый. Биш ел эчендә районның үсемлекчелек тармагында да гаять зур үзгәрешләр барган.

– Дәүләт ярдәме программалары кысаларында безнең авыл хуҗалыгы оешмалары ике миллиард сумлык югары җитештерүчәнлеккә ия техника сатып алды, – ди Сафиуллов. – Заманча агротехнологияләр, югары уңыш бирә торган сортларның орлыгын сатып алу да уңдырышлылыкны арттыра. Монннан 10–15 ел элек Германия игенчеләренә гаҗәпләнсәк, хәзер үзебез аларны таң калдыра алабыз.

Хәлбуки, бу бернинди дә арттыру түгел. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы нәтиҗәләре буенча, 2020 елда Татарстаннан экспортка чыгарылган арпаның яртысы Тәтештән булган. Гомумән алганда исә, Тәтеш ашлыгын чит илгә, Иранга, 2019 елда ук сата башлаганнар. Аны анда Идел һәм Кас-

5

– Заманча агротехнологияләр, югары уңыш бирә торган сортларның орлыгын сатып алу да уңдырышлылыкны арттыра, – ди Рәмис Сафиуллов.

пий буйлап илтеп җиткерәләр, баржаларны исә озак вакыт эшләми торганнан соң кабат сафка бастырылган җирле элеваторда яхшылап төйиләр.

Ниһаять, район игенчеләренә кайбер позицияләр буенча тиңнәр юклыгын дәлилли торган соңгы яңалыкны да әйтер вакыт җитте. Күптән түгел узган «АгроВолга» Халыкара агросәнәгать күргәзмәсендә конкурсның «Россиядәге иң алдынгы чөгендер чәчү хуҗалыклары» номинациясендә җиңүчеләрен атаганнар. Тәтешнең «Колос», «Бакырчы» һәм «Содружество» хуҗалыклары илдә иң шәп дип табылган.

Быелгы уңыш нинди булачак? Фаразлар уңай, әмма Сафиуллов бу җәһәттән бик сак:

– Уңыш – җыеп алып инде амбарга салынган ашлык ул... – ди.

Алдан кычкырып куюдан куркамы? Әмма район башлыгын җавапсызлыкта һәм кыюсызлыкта һич гаепләп булмый. Менә, үзегез бәя бирегез.

6

Мохтаҗларга гуманитар ярдәмне район башлыгының үзе үк тапшыруы мәҗбүри түгел кебек. Әмма Сафиуллов үзе болай уйламый.



РАЗВЕДКА ҮЗЕБЕЗНЕКЕЛӘРНЕ ТАШЛАМЫЙ

Бронясына V символы төшерелгән хәрби машинада – «Тәтеш муниципаль районы» дип ябыштырылган. Гәрчә Тәтеш махсус операция барган җирләрдән бик еракта булса да, әлеге фото – фейк түгел. Сурәтне Украинадагы бәрелешләрдә катнашучы һава десанты гаскәрләре бригадасы солдатлары җибәргән. Сугышчылар шул рәвешле тәтешлеләргә рәхмәтен җиткерә: июнь башында алар алгы сызыкка ашамлыклар һәм егерме дизель-генератор илтеп биргән. Болар барысы да Рәмис Сафиуллловның һәм хуҗалык җитәкчеләренең шәхси акчасына сатып алынган.

Бу Тәтештән җибәрелгән гуманитар ярдәмнең беренчесе дә, соңгы партиясе дә түгел. Июльдә Донбасстагы солдатлар Сафиулловтан 24 тонна гуманитар ярдәм алган. Ә беренче партия – кырык тонна азык-төлек – Украина халкына мартта ук барып җиткән. Иң кирәкле ризыклар тулы ике мең тартма: тәтешлеләр исәпләвенчә, ике мең гаилә өчен бер айга җитәрлек ризык...

Атыш барган җиргә гуманитар ярдәмне илтеп җиткерү үзе дә шактый куркыныч булу һәркемгә мәгълүм. Шәхси акчасына сатып алган азык-төлекне район башлыгының үзе үк илтеп тапшыруы мәҗбүри түгел кебек. Әмма Сафиуллов үзе болай уйламый. Дүрт тапкырында да ул йөкне үзе алып барып тапшырган.

Йөкне ДХР, ЛХР вәкилләренә, безнең сугышчыларга тапшыргач, Сафиуллов һичшиксез махсус операциядә катнашучылар белән аралашу өчен дә вакыт таба. Бер баруында татарстанлылар хезмәт иткән кече ракета корабында да кунак булган.

– Алар безнең өчен гомерләрен куркыныч астына куя, аларга ярдәм итү – безнең бурычыбыз, – дип саный Рәмис Сафиуллов. Сугышчылар белән ул эшне белеп, тиң булып аралаша – чөнки үзе дә армиядә Һава десанты гаскәрләренең разведка ротасында хезмәт иткән.

Әлеге сәфәрләрдә тагын бер асыл мәгънә бар. Бурычның үтәлүен шәхси контрольдә тоту – аның холкының үзенчәлеге. Йөкне алып барып җиткереп, адресатка тапшыргач, бар нәрсәнең дә яхшы сакланган хәлдә килеп җитүенә инангач кына, аның җилкәсеннән тау төшкән кебек була.

Сафиуллов барган саен сугышчылардан тәфсилләп сораштыра да: аларга нәкъ менә хәзер нәрсә җитми. Бу чираттагы ярдәм траншыйның чыннан да кирәкле булуы өчен мөһим, чөнки кемдер таләп иткәнгә генә гуманитар ярдәм күрсәткән булып кылану дөрес түгел. Бирелә дә үз районындагы кебек: бөтен эшләнгән эш матур хисап тоту өчен түгел, бәлки халык өчен башкарыла.

ТӘТЕШЧӘ ЛАЙФХАК

Тәтеш стендка ату мәктәбенә кергәндә безне каршылаган «түтәл» кояшта бакырның куе кызылдан алып җете алтынсуга кадәр бөтен төсмерләрендә ялтырап ята. Бик матур һәм илдә башка беркайда да юк мондый «түтәл». Бәлки әле дөньяда да юктыр. Биредә чәчәк урынына патрон гильзалары тезелгән. Менә шундый Тәтешчә лайфхак.



– Кызык кына килеп чыкты ул: ату буенча чираттагы чемпионат якынлаша. Әзерлек – 100 процент, әмма тулы бәхет өчен матур чәчәк түтәле җитми кебек. Аның өчен акча исә хәтта проектта да каралмаган. Шуңа уйлап табарга туры килде, – дип сөйли үзенчәлекле арт-объектның тарихын мәктәп җитәкчесе Андрей Кушагин. – Ни чарадан бичара инде...

Эш акча кытлыгында түгел инде әлбәттә. Әлеге мәктәп – җиһазланышы буенча илдә иң яхшылардан берсе, бәлки иң яхшысыдыр да. Пөхтә, төзек территория, яңартылган административ бина һәм төп байлык – «скит» һәм «трап» дисциплиналарында ату өчен идеаль җиһазландырылган алты мәйданчык. Барысына да Франциядә эшләнгән тәлинкә ыргыту машиналары куелган – чикләүләргә кадәр алып калырга өлгергәннәр.

– Мондый алты мәйданчык – иң югары дәрәҗәдәге ярышлар үткәрү мөмкинлеге ул. Илдәге башка бер генә ату урынында да бездәге кадәр мәйданчык юк, – дип горурланып сөйли Кушагин. – Шунлыктан Россиянең командалы чемпионаты быел Тәтештә уздырылды, аннары – ил Кубогы да. Европа чемпионаты да планлаштырылган иде, әмма чикләүләр комачаулады.

7

Ату өчен алты мәйданчык – иң югары дәрәҗәдәге ярышлар үткәрү мөмкинлеге ул.

Олимпия уеннары, дөнья, Европа һәм Россия чемпионатларының дистәләрчә җиңүчесен һәм призерын тәрбияләгән атаклы Тәтеш стендка ату мәктәбе өчен заманча ату урыны, табигый ки, зиннәт түгел, ә зарурлык. Шуңа гаҗәп тә: ә бит әле күптән түгел генә ул икенче планга күчәргә һәм әкренләп юкка чыгарга мөмкин була, чөнки Югары Ослан районында ату комплексы төзелгәч, Тәтештәге секциягә тыйнак филиал роле белән генә канәгатьләнергә яисә бөтенләй ябылырга туры киләчәк иде.

Кушагин һәм аның командасы Рәмис Сафиулловтан ярдәм сорамаган булса, нинди хәлдә калган булырлар иде. Район җитәкчесе чаң суга башлый: илнең горурлыгы булган, Тәтештәге һәр үсмер диярлек аның аша үткән данлыклы мәктәп болай юкка чыгарга тиеш түгел! Иганәчеләрне җәлеп итә. Сафиуллов Татарстан Президенты ярдәменә өметләнә һәм ялгышмый. Кирәкле акча республика бюджетыннан бүленә.

Бүген Тәтештәге ату урынында ике йөзгә якын малай һәм кыз шөгыльләнә, ил җыелмаларының өчтән бер өлешен исә, элеккеге кебек үк, Тәтеш шәкертләре тәшкил итә.

Сүз уңаеннан, биредә оча торган тәлинкәләргә спорт мәктәбе шәкертләре генә түгел (алар өчен барысы да бушлай), ә теләгән һәркем атып карый ала. Инструктор карап-күзәтеп торганда, мишеньнәргә рәхәтләнеп атасың. Бер мәртәбә ату – алтмыш сум.

Атып карау бигрәк тә пристаньга килеп туктаган теплоходлардагы туристлар арасында популяр диләр – алдан ук язылалар, тулы бер төркемнәр белән. Үзенең төз ату сәләтен Олимпия дәрәҗәсендәге чын ату урынында тагын кайсы шәһәрдә тикшереп булыр иде әле?

СӘЛАМӘТЛЕК ҺӘМ ДЕМОГРАФИЯ ТУРЫНДА

Тәтеш район хастаханәсенең беренче катында эш кайный – капиталь ремонт бара.

– Бу катта ковид госпитале урнашкан иде, – ди хастаханәнең баш табибы Илья Савельев. – Ремонттан соң палаталар һәм процедура кабинетлары булачак. Палаталар – иң күбе биш кешелек. Ике-өч кешелекләр дә бар. Барысы да уңайлыклар белән. Капремонтка кадәр исә коридорда нибары бер бәдрәф иде...

Беренче кат яңартылганнан соң Тәтеш Үзәк район хастаханәсендә моннан берничә ел элек башланган капиталь ремонт тәгәлләнәчәк. Биредә бер-бер артлы поликлиника, бәби тудыру, хирургия бүлекләре яңартылган. Капремонт кысаларында корпус һәм биналар гына реконструкцияләнеп калмый, хастаханә яңача җиһазландырыла да, элек персонал мондый яңа заманча җиһазлар турында хыяллана да алмаган.

Мисалга бәби тудыру бүлеген алыйк, ул беренче чиратта, моннан дүрт ел элек яңартылган. Җайланмалар, җиһазлар сатып алуга, территорияне төзекләндерүгә 22 миллион сумнан артык акча бүленгән. Инкубатор, үпкәне ясалма вентиляцияләү аппараты, реанимация мониторы... – биредә хәтта гадәттән тыш очракларда да кирәк булачак бөтен нәрсә бар.

– Конкрет кешеләр тормышындагы социаль мәсьәләләрне хәл итмичә торып, территорияне уңышлы үстереп булмый, – дигән бәби тудыру бүлеген ачкан чакта Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. – Мин Тәтеш районында мондый күп мәсьәләнең хәл ителүенә сөенәм. Президентыбыз инициативасы буенча гамәлгә ашырыла торган социаль программалар нигезендә үзәкләр үзгәртелә, районда яшәүче һәркем төрле хезмәт күрсәтүләрдән файдалана ала.

Хәзер Тәтештәге хастаханә һәм поликлиника башкаладагылардан калышмый. Үзәк район хастаханәсен капиталь ремонтлау ахырына якынлаша, шунлыктан инде 2014 елда яңа гына эшкә билгеләнгән район башлыгының моннан ике дистә ел элек төзелгән хастаханә комплексын күргәннән соң нинди авыр хисләр кичерүен хәзер искә төшерсәң дә була. Тармак программаларына кертелмәгән объектны җитди реконструкция таләп ителгәннәр арасына кертү өчен аңа бик нык тырышырга, үҗәтләнергә туры килә.

Хастаханә һәм бигрәк тә заманча бәби тудыру бүлегеннән башка демографияне яхшырту хакында уйлыйсы да юк, дип фикер йөртә Рәмис Сафиуллов. Демография – аның авырткан җире. Районда халык саны кимү белән килешәсе килми аның. Иманы камил: яшьләрнең зур шәһәрләрдә яшәү теләге генә гаепле түгел монда, кайдадыр үзебез дә «булышабыз».

– Менә бездә өч торак пункт бар: Келәш, Вожжи, Бессоново. Һәркайсында мәктәп, мәктәп саен 70–80 укучы бар иде... Ә аннары оптимальләштерү башланды да, өч авылга бер мәктәп калды, – дип хафалана башлык. – Дөресме инде бу? Әгәр авылда мәктәп ябыла икән, аның киләчәге юк дигән сүз. Гадәттә гел шулай була...

Яшьләрнең ихтыяҗына килгәндә исә, монда максат аңлаешлы. Лаеклы яшәү һәм ял итү өчен Тәтештә дә мөмкинлекләр зур шәһәрдәгедән азрак булмаска тиеш. Болай эшләп буламы соң? Әйдәгез карап карыйк.

«РЭДИССОН»ДАГЫ КЕБЕК СЕРВИС

«Барс» спорт-сәламәтләндерү комплексы директоры Илнур Рәхимовка күптән түгел бассейнга абонемент бәясен күтәрергә туры килгән. Хәзер бирегә бер ай йөрү 1500 сум тора.

– Без үз популярлыгыбызның корбанына әйләндек, – дип аклана Илнур. – Йөзәргә теләүчеләр бик күп.

Бу гаҗәп тә түгел, 25 метрлы гүзәл бассейн тәтешлеләрне магниттай тартып тора. Сигез йөзү юлы, душ, уңайлы кием алыштыру бүлмәләре – барысы да иң югары дәрәҗәдә. Объектны файдалануга тапшырганда, шкафларга гади йозак куймакчы булганнар. Барып чыкмаган – чөнки район башлыгы Сафиуллов Мамай заманындагы технологияләргә катгый каршы. Шуңа хәзер биредә ниндидер биш йолдызлы «Рэдиссон» отелендәге кебек – шкафлар пластик карта ярдәмендә бикләнә...

Бассейнга түләп йөрү – олылар өчен генә. Җирле балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең яшь йөзүчеләре исә, әлбәттә, биредә бушлай шөгыльләнә. Зур казанышлар спортына иң сәләтлеләр генә килсен өчен, сайлап алу системасы эшләнгән. Тәтеш сабыйлары бассейн белән дүрт яшьтән үк таныша башлый, чөнки икенче, кечерәге бәләкәйләргә

тәгаенләнгән. Берничә дәрестән соң ук үзләрен судагы балыктай хис итә башлаганнарны исә аннары бушлай секциягә чакыралар.

Бүген җирле яшь йөзүчеләр инде Бөтенроссия ярышларында медальләр яулый, шунлыктан тәтешлеләр Рөстәм Миңнеханов куйган бурычны уңышлы үти, дип әйтеп була. Нинди бурычмы? Эш шунда ки, ФИНА Халыкара йөзү федерациясе президенты Хулио Маглеоне белән бергә бу бассейнны ачканда, Татарстан Президенты:

– Мин аның Тәтеш районы халкын сөендерәчәген беләм. Әмма без сездән спортта югары казанышлар да көтәбез, – дигән булган.

Бассейн – спорт-сәламәтләндерү комплексының бер өлеше генә әле ул. Спортның уен төрләре залы, тренажерлар һәм фитнес заллары, көрәш ареналары... – «Барс»та һәркем күңеленә яткан шөгыльне таба ала.

Әмма Рәмис Сафиуллловның максималист икәнен хәтердән чыгармыйк. Аның иманы камил: сәламәт яшәү, спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар район үзәгендә генә түгел, авылларда да булырга тиеш. Һәм шул юнәлештә эшли дә. Бүген районда уникаль проект гамәлгә ашырыла – авылларда универсаль спорт комплекслары төзелә.

Беренчесе Бакырчыда ике ел эшли инде, анда хәтта ирекле көрәш буенча Бөтенроссия ярышлары да үткәрелгән. Тагын җидесе төзелә: Садовод, Келәш, Олы Шәмәк, Зур Әтрәч, Олы Тархан, Вожжи һәм Килдештә.

Сүз уңаеннан, Бакырчыда иганәчеләр акчасына төзелгән комплекс турында Сафиуллов хәтта РФ Иминлек советы секретаре Николай Патрушевка да язган. Ни өчен: мондый комплекслар һәр авылда булырга тиеш, алар, төзекләндерү, мәдәният йортлары белән беррәттән, бик кирәк һәм яшьләрне авылда калдырырга булышачак. Нәтиҗәдә Тәтеш тәҗрибәсе иң югары дәрәҗәдә тикшерелгән. Аны бөтен илгә таратырга карар кылынган.

Ә Николай Патрушев, күптән түгел Татарстанга килгәч, табигый ки, Бакырчыга да сугылган һәм комплексны үз күзләре белән күргән.

БУАЛАР ПАТШАСЫ

Стильле шезлонглар, су буена алып төшә торган баскычлы яр буе, бер ярдан икенчесенә сузылган нәфис күперләр... Шәһәр буасы янындагы җәмәгать мәйданының әлеге почмагы тәтешлеләрне үзенә магниттай тартып тора: җәйге көн уртасында, күпчелек кырда яки яшелчә бакчасында чакта гына биредә кеше азрак була... Әмма инде кичкә таба ук төрле яштәге публика белән тула.

– Безнең Казандагы яр буйларында да йөргәнебез бар, тик үзебезнеке дә аннан бер дә ким түгел, – дип горурланып әйтә яшь рэпер, кәттә велосипедында су янына килеп туктагач.

– Юк ла, безнеке яхшырак, – дип каршы төшә ахирәте.

Үсмерләр бераз арттырып җибәрсә дә, бик азга гына. Тәтештәге «Городской прудЪ» проекты ике ел элек кече шәһәрләрдә һәм тарихи бистәләрдә уңайлы кала мохитен булдыру буенча иң яхшы проектларның Бөтенроссия конкурсында җиңүче дип табылган, Россиянең 82 төбәгеннән 198 көндәшен артта калдырган. Мәскәүдә район башлыгы Рәмис Сафиулловка тапшырылган җиңүче дипломына 55 миллион сумлык грант та өстәлгән – барлык бу гүзәллек шул акчага төзелгән.

Юк инде, барысы да түгел. Берничә ел элек сазлыкка әйләнә язган сулыкны чүп-чардан арындырганнар һәм хәлдән килгәнчә төзекләндергәннәр. Аннары исә белгечләр җәлеп ителгән һәм җиңүгә китергән проект пәйда булган. Алар җирле җитәкчелекнең төп принцибы белән илһамланып иҗат иткән: «Башкаларныкы кебек түгел, яхшырак итеп эшләргә кирәк».

Арттырабыз, дисезме? Балыкчылык тарихы музеен булдыруга, Вшиха тавын, Иделдәге баскычны реконструкцияләүгә отылган федераль грантлар үзләре хакында үзләре сөйли. Кечкенә генә провинциаль Тәтештә, буа ярында, әле төсле музыкалы фонтан да бар – көнләшегез, башкалалар!

Барысы да чын. Төп максат – тормыш сыйфатын яхшырту – Тәтештә даими һәм уңышлы тормышка ашырыла.

Тәтеш якларына баргач, тәмле итеп сыйланып аласыгыз киләме? Шәһәрдә очраган кемнән генә сорасагыз да, сезгә, һичшиксез, «Жасмин» яки «Абажур»ны тәкъдим итәрләр! Аларның һәркайсында сезне ачык йөз белән каршы алып, яхшы хезмәт күрсәтәчәкләр һәм телеңне йотарлык итеп сыйлаячаклар. Ә моның сере бик гади: әлеге кафеларның хуҗасы Рәмзия Рәфыйкова аларга бөтен күңел җылысын биргән.

КАФЕБЫЗГА РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Рәмзия Рәфыйкова,
шәхси эшмәкәр

БЕЗ БУЛМАСАК, КЕМ?

«Жасмин» һәм «Абажур» – табышлы бизнес-проект түгел, ә туган шәһәреңә, аның халкына һәм кунакларына мәхәббәт белдерү ул. Тәтешлеләр башкалардан киммени, ни өчен аларның яхшы кухнясы, уңайлы мохите һәм ягымлы персоналы булган, дуслар яки гаилә белән сыйланып утырырлык урыннары юк? Эш сәфәре белән Татарстанны гизеп йөргәндә, хәтта иң караңгы төбәктә дә кафе булганын, ә үзе туып-үскән Тәтештә андый кафе-ише нәрсәнең юклыгын күргән Рәмзия Әхмәт кызы әнә шулайрак фикер йөртә. Һәм менә 2007 елда ул бу хәлне тиз арада төзәтергә кирәк дигән карарга килә.

– Мин һәрвакыт тәмле пешерергә, таныш-белешләрне, якыннарымны яңа ризыклар белән сөендерергә яраттым, һәм менә шәһәребездә кафе ачарга булдым, – ди Рәмзия ханым. Бәлки, бу ниндидер авантюра булгандыр, ләкин шулай да ул гаиләсенең ярдәме белән эшкә тотына.

– Акча бөтенләй юк иде, без кредитлар җыйдык һәм фатирыбызны «Жасмин» дип аталган беренче кафебыз өчен үзгәртеп корырга алындык. Зур эшләрдән кала, ремонтын да үзебез башкардык, – дип сөйли Рәмзия Рәфыйкова. – Куркытты билгеле, тегенди-мондый артык нәрсә түгел, ә кайчак әле кирәклесен дә алыр хәлебез юк иде. Әмма барысы да уңышлы килеп чыкты. Һәм бу – иң мөһиме!

УҢАЙЛЫ АБАЖУР ЯКТЫСЫНДА

«Жасмин» кафесыннан соң шундый ук исемдәге банкет залы барлыкка килә, чөнки кунаклар күбәя, уңайлы мохиттә, тәмле табын корып, төрле бәйрәм-юбилейларны билгеләп үтәргә теләүчеләр дә арта. Сүз уңаеннан, хәзер зал бер көн дә буш тормый.

Безнең героебыз ирешкәннәрдә генә туктап калырга теләми, һәм бераздан «Абажур» кафесы ачыла. Янә үгезне мөгезеннән эләктерә ул! Бу кафе да шәһәр халкы һәм кунакларның яраткан урынына әйләнә. Әле шунысын да искәртү мөһим: хәзер Тәтештә бик күп җәмәгать туклануы урыннары бар, ягъни көндәшлек җитәрлек.

УҢЫШ СЕРЕ

– Бездә гадәти Европа кухнясы, әллә нинди искитәрлек нәрсәләр юк. Нәрсә беләбез, шуны әзерлибез, – дип тыйнак кына сөйли Рәмзия Рәфыйкова. Ә кафеларның популярлыгына караганда, алар күп нәрсә әзерли белә. Биредә ризыклар тәмле, файдалы, матур бизәлгән, бәяләре дә тешләми.

Кафеларның төп өстенлеге, хуҗа ханым сүзләренчә, ризыкларның сыйфатында. Бу мәсьәләгә биредә аерым игътибар бирелә. Һәм кешеләр кафега кабат-кабат килә, аны дусларына да тәкъдим итә. Бирегә туристларны да алып киләләр, ә аларның, кагыйдә буларак, бик күп җирләрдә булганнары һәм әллә нәрсәләр татып караганнары бар. Туристлар да канәгать кала: кечкенә генә Тәтештә дә яхшы кухня дигән нәрсәне беләләр икән ләбаса!

Шәһәр хакимияте ярдәменнән башка кафелар уңышлы эшли алмас иде, моның өчен аңа зур рәхмәт.

«Жасмин» һәм «Абажур» кафелары коллективы Тәтеш районы башлыгы Рәмис Сафиулловны юбилее белән котлый!

Хөрмәтле Рәмис Хатыйпович!

Туган көнегез – 60 яшьлек юбилеегыз уңаеннан иң ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз!

Сезнең югары һөнәри осталыгыгыз, иң катлаулы мәсьәләләрне эзлекле рәвештә һәм төгәл хәл итә белүегез, максатчанлыгыгыз шәһәр һәм район халкының лаеклы хөрмәтен казанды. Талантлы җитәкче буларак, Сез тирән белемегез, искиткеч оештыру сәләте, югары нәтиҗәгә ирешерлек итеп эшли белүегез белән аерылып торасыз.

Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, бәхет, иминлек, эшегездә уңышлар, барлык планнарыгызның тормышка ашуын һәм бетмәс-төкәнмәс энергия телибез!

Фотолар Рәмзия Рәфыйковадан алынды. РЕКЛАМА

КОРЫЧ ХОЛЫКЛЫ ПЫЯЛА

Казанның яңа төзелешләре, Иннополис, КАМАЗ, POZIS, «Казан Оргсинтез» – Татарстанның әлеге саллы объектларын бер-берсе белән ни бәйли? Алар барысы да – «ТольяттиТехСтекло» компаниясенең Тәтеш филиалы клиентлары.

Нигез салынган көннән үк Алексей Черкасов җитәкләгән компаниянең төп продукциясе – һәркайсыбызның йорт тәрәзәләрендәге пыяла конструкцияләр. Татарстанда ишек-тәрәзә җитештерүчеләр Тәтеш продукциясенең сыйфатын һәм көндәшлеккә сәләтлелеген бик югары бәяли.

ТУГАННАРЧА КАРШЫ АЛГАННАР

Компания Россия базарына 2008 елда чыга. Инде Уфа һәм Самара филиаллары булган килеш, 2015 елда ул Татарстанда да эшен җәелдерергә карар кыла. Шул рәвешле Тәтештәге сәнәгать мәйданчыгында «ТТС-116» ҖЧҖ теркәлә.

Ни өчен нәкъ менә Тәтеш сайлап алынган, югыйсә Татарстан зур бит? Алексей Черкасов сүзләренчә, монда шәһәрнең логистика ягыннан уңышлы урнашуы гына түгел, район башлыгы, яңа җитештерү предприятиесе ачылуга актив булышлык күрсәткән Рәмис Сафиуллов белән шәхсән очрашу да зур роль уйнаган. «Эшләгез, кирәк булганда, ярдәм итәрбез!» – Рәмис Хатыйп улының бу сүзләре предприятиенең уңышка ирешәчәгенә тәмам ышандыра.

Нәтиҗәдә, район – өстәмә керем һәм 60 кеше өчен югары хезмәт хакы түләнә торган эш урыннарына, ә Татарстанның тәрәзә кую осталары бик яхшы пыяла пакетлар белән тәэмин итә торган ышанычлы ширкәткә ия була.

Сүз уңаеннан, берничә ел элек компаниянең Тәтеш филиалында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов булып киткән һәм күргәннәреннән канәгать калган.

ПЫЯЛАНЫ – ҺӘРКЕМГӘ ҺӘМ ҺӘРКАЙДА!

Бүген бу – заманча һәм калдыксыз җитештерү предприятиесе. Ике югары технологияле линиянең эше Япониянең 5S системасы нигезендә оештырылган: цехлар тамгаланган, һәр сменадагы хезмәткәрләр үз функцияләрен һәм урынннарын анык белә.

Ассортиментта табак пыяладан 3 меңнән артык исемдәге әйбер санала: аларны кисеп, ябыштырып, тоныклатып, чыныктырып һәм бөгеп бирәләр, хәтта броня белән дә каплап бирә алалар. Пыяла пакетлар җитештерүдә кулланыла торган барлык материаллар да – үзебезнеке, безнең җирлектән.

«ТТС» клиентлары, югарыда искә алынганча, шактый саллы оешмалар – POZIS, «Казан Оргсинтез», КАМАЗ. Тәтештә эшләнгән пыяла пакетлары Казанның күп кенә торак комплексларында урнаштырылган. Әлмәттә «Орленок» һәм Яшел Үзәндә «Чайка» лагерьларына, Буада универсаль спорт залына «ТТС» продукциясе куелган. Компания эшләнмәләре Ульяновск өлкәсенә, Мари Элга, Чувашиягә һәм башка төбәкләргә җибәрелә.

Бүгенге «ТТС» – сыйфат билгесе ул, моны фирманың күп санлы партнерлары яхшы аңлый.

«ТольяттиТехСтекло» компаниясе Тәтеш районы башлыгы Рәмис Сафиулловны 60 яшьлек юбилее белән котлый.

Хөрмәтле Рәмис Хатыйпович!

Сезнең ярдәмегез ширкәтебезнең тәүге елларыннан бирле безгә көч биреп тора һәм иртәгәсе көнгә ышаныч белән карарга мөмкинлек тудыра. Нәтиҗәле хезмәттәшлегебез өчен рәхмәт!

Чын күңелдән Сезгә нык сәламәтлек, эшегездә яңа уңышлар һәм гаиләгездә иминлек телибез!

Тагын бер тапкыр юбилеегыз белән Сезне!

Фотолар «ТТС» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

АВЫЛНЫ САКЛАУЧЫЛАР

Быелгы елның июнендә Тәтеш районында Россия Куркынычсызлык Советы Секретаре Николай Патрушев, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм РФ Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров булып киттеләр. Сәбәбе районның социаль объектлар төзү буенча уникаль тәҗрибәсе булды. Бу эштә Тәтешнең «Бакырчы» ҖЧҖ кебек алдынгы аграр предприятиеләре зур роль уйнады.

Уңыш буенча Тәтеш агрофирмалары арасында өченче урында барган бу хуҗалык урынында әле берничә ел элек кенә ташландык кырлар һәм ишелгән фермалар иде. 2015 елда «Бакырчы» Илгиз Шәйхаттаров җитәкчелегендә яңа старт алды. Кадрлар кытлыгы һәм башка кыенлыкларга да карамастан, шул ук елны предприятие, чәчү эшләрен вакытында башкарып, озак вакытлар дәвамында булмаган беренче уңышны җыя алды.

Дистәдән артык трактор, берничә чәчкеч һәм башка машиналар сатып алу агрофирманың мөмкинлекләрен арттыруда беренче адым булды. «Бакырчы»да авыл хуҗалыгы эшчәнлеген субсидияләү буенча федераль һәм республика программалары бирә торган мөмкинлекләрне күрә һәм куллана беләләр.

Нәтиҗәле хуҗалык эшчәнлегенең мөһим өлеше – коллектив. Бүген биредә 50ләп кеше эшли, сезон вакытында 60 ка җитә. Бакырчы авылының үзендә нибары 300 гә якын кеше яшәвен исәпкә алганда, агрофирма биредә бюджет төзүче предприятие, дип әйтергә була.

– Лаеклы хезмәт хакы түләү – безнең төп принцип, – ди Илгиз Шәйхаттаров. – Кеше үзен якланган итеп хис итәргә, хезмәт хакын соңга калмый көнендә алачагын белеп торырга тиеш. Авыл хуҗалыгы – еш кына көрәш кыры, ә яуда ялгызың бернишләп тә булмый. Коллективтан башка син беркем түгел. Шуңа күрә хезмәткәрләрнең ышанычы бик мөһим.

Башка күп хуҗалыклардан аермалы буларак, «Бакырчы» кадрларга кытлык кичерми, гәрчә монда эш бик күп булса да. Предприятиенең 4650 га чәчүлек җире бар, шул исәптән 2829 га бөртекле культуралар, 500 га шикәр чөгендере, 515 га күпьеллык үлән, 200 га көнбагыш өчен. Моннан тыш, аг-

Фото: tatarstan.ru. РЕКЛАМА

рофирма терлекчелек белән дә шөгыльләнә: 1200 баш терлекнең 350се савым сыеры, якын араларда аларның баш саны 500 гә җиткереләчәк.

Предприятие белгечләре үз эшләрен беләләр һәм яраталар, шуңа күрә һәр юнәлеш буенча яхшы нәтиҗәләргә ирешәләр.

Узган корылыклы елда бирелә бер гектардан 37,5 центнер уңыш җыеп алынган, бу район буенча уртача күрсәткечтән 15 центнерга күбрәк. Быел 50 центнерга кадәр алырга исәп тоталар. Тәтешнең башка алдынгы хуҗалыкларындагы кебек үк, «Бакырчы»да да туфракны һәм чәчүлекләрне эшкәртү технологияләрен төгәл үтиләр: ашламалар, яфрактан тукландыру, фунгицид, гербицидлар һәр сезонда график буенча кертелә. Элиталы һәм суперэлиталы орлыклар гына чәчәләр. Уңыш үзләрен чәчү материалы белән тәэмин итү өчен дә, элеваторга тапшыру өчен дә җитәрлек.

«Бакырчы» кебек предприятиеләр булганда республикага шикәр кризисы янамый. Биредә шикәр чөгендеренең уңдырышлылыгын гектарыннан 600 центнерга кадәр җиткергәннәр. 2021 ел нәтиҗәләре буенча, агрофирма «Россиянең иң яхшы чөгендер игүче хуҗалыгы» исеменә лаек булган. Чөгендерне Буа һәм Ульяновск шикәр заводларына эшкәртүгә озаталар.

Узган елда «Бакырчы»да тулай продукт күләме 286 млн сум булган. Мондый икътисадый дәрәҗә хуҗалыкка үз районы тормышында актив катнашырга мөмкинлек бирә – инфраструктура объектларын ремонтлау һәм төзүгә булышудан алып бәйрәм чараларын үткәрүгә кадәр. Бу тырышлыклар югары бәяләнә.

«...Буыннан буынга үз куллары белән туган авылларын төзиләр һәм үстерәләр, Ватаныбыз иминлеге хакына фидакарь хезмәт итәләр...», – Николай Патрушев авыл музееның мактаулы кунаклары китабында Бакырчы авылы халкына багышлап нәк шундый сүзләр язып калдырган. Бу язма илнең байлыгы, иң беренче чиратта, аның кешеләре булуын искә төшереп тора. Хезмәт кешеләре, җирдә эшләүче кешеләр булуын. Т

ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА

СЕКРЕТАРЯ СОВЕТА БЕЗОПАСНОСТИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

НАГРАЖДАЕТСЯ

ШАЙХАТАРОВ
ИЛЬГИЗ ФАТЫХОВИЧ

За значительный личный вклад в обеспечение государственных интересов Российской Федерации

Секретарь Совета Безопасности Российской Федерации — Н.ПАТРУШЕВ

12 июля 2022 г.

СЕЗНЕҢ КИҢӘШ БЕЗГӘ БИК КИРӘК!

Радик Нургалиев,
«Нур» агрофирмасы җитәкчесе.

Тәтеш районының «Нур» хуҗалыгы оешканга унҗиде елдан артык вакыт узып китте. Шунысы сөенечле: күп кенә авырлыкларны җиңеп чыга алдык. Әлбәттә, әле эшлисе эшләр, куелган бурыч, максатлар бик зур. Бүген «Нур» агрофирмасын республикада да беләләр. Былтыр «Елның иң яхшы орлыкчылык хуҗалыгы» исеменә лаек булдык. Татарстан Республикасы хуҗалыклары арасында бара торган мәртәбәле конкурс ул. Безне котларга республикабызның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Илдус Габдрахманов, «Татарстанның элиталы орлыклары» ассоциациясе генераль директоры Юрий Еров, Идел алды зонасының орлыкчылык хуҗалыгы вәкилләре килгән иде. Шулвакыт район башлыгыбыз Рәмис Сафиуллов кунакларны каршы алды, озатып йөрде. Безгә караганда, ул ныграк та сөенде булса кирәк, чөнки һәр хуҗалыкның уңышы – район өчен дәрәҗә дә, зур сөенеч тә.

Рәмис Хатыйп улы безнең хуҗалыкка карата һәрвакыт игътибарлы. Ә бу эшләргә зур көч бирә. Бүген 4 мең 900 гектар сөрү җиребез бар. Заманча, зур терлекчелек комплексы төзеп ятабыз. Бу да район башлыгының хәер-фатыйхасы белән башланган эшләр.

Тагын бер күзәтүем – Рәмис Сафиулловның алдан күрү сәләте бар. Һәм ул үгетли белә. Яңа техника алыргамы, юкмы дип уйлап торганда, ул һәрвакыт: «Алыгыз!» – ди. Чынлап та, куркыбрак алынган техника өчен ничектер тиз арада түләнеп тә бетә. Әбиләр әйтмешли, җан биргәнгә җүн бирә. Ашлама белән дә шул ук хәл: Рәмис Хатыйп улының киңәшен тотсаң – отасың...

«Нур» агрофирмасына Кече Әтрәч, Зур Әтрәч, Алабирде авыллары керә. Безнең җирлектә җыр-моңга гашыйк, ачык күңелле халык яши. Авылга килгән һәркем әнә шуңа сокланып китә. Шуның белән бергә эштән дә курыкмыйлар. Без шушы мең еллык тарихы булган әлеге җирдә эшләвебез, яшәвебез белән чиксез бәхетлебез.

Бу көннәрдә без хөрмәт иткән район башлыгы Рәмис Хатыйп улы Сафиуллов үзенең күркәм юбилеен каршы ала. Һәм шушы тарихи җирдән торып, хөрмәтле район җитәкчебезне зур юбилее белән котлыйбыз.

Хөрмәтле Рәмис Хатыйпович! Ихлас күңелдән сезне шушы олуг бәйрәмегез белән тәбрик итәбез. Зыялылыгыгыз, үз-үзегезгә таләпчәнлегегез, конструктив әңгәмә кора белүегез, тирә-юньдәгеләргә игътибарлы мөнәсәбәтегез барыбызның ихтирамын яулады. Сезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, бәхет, бетмәс-төкәнмәс энергия һәм иминлек телибез!

Фото «Нур» агрофирмасыннан алынды. РЕКЛАМА

акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр /

игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Йолаларыбызны **ничек** кайтарырга

Кем ул Хөсәен Әмирхан

Әҗем мәчете **ничек** сакланып калган

Келәнчедә тарихны **ничек** торгызалар

ЙОЛА – КОНСТИТУЦИЯ УЛ!

Рабит Батулла,
язучы-прозаик, драматург

Татар гомергә йолаларны санлап, аларга таянып яшәгән. Шуның өчен дә «Татарстан» журналы гореф-гадәт, йолаларны барларга булды. Бу эштә ярдәмгә татар язучысы, драматургы Рабит Батулланы чакырдык. Әлеге теманы ныклап өйрәнгән кеше буларак, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләде ул.

ГАДӘТ БЕЛӘН ЙОЛА НИЧЕК АЕРЫЛА?

– Гадәт бар, йола бар. Гадәт дигән сүз ул бик кечкенә, аның әллә ни әһәмияте юк. Мисал өчен, аякны селкеп утыру, бармак белән өстәлгә шакылдату гадәте бар. Саный китсәң күп инде. Болар барысы да вак әйберләр. Һәм күп очракта бик матур да түгел. Шуның өчен дә алар зураеп, йолага әверелмәгән дә.

Бер генә кеше түгел, ә бөтен халык шушы гадәтне эшли башласа, ул йолага әйләнә. Ә йола ул – язылмаган канун, хәтта Конституция, дияр идем. Әлбәттә, кайбер Кавказ халыкларында гадәтне дә бик зурайталар, «адәт» диләр. Шәригать кануннары дәрәҗәсенә җиткерәләр.

Мәктәп, мәдәният, холык, киемсалым, аш-су – барысы да йола. Ул бик зур институт, аңа бик җитди карарга кирәк. Һичшиксез, балаларны йола белән тәрбияләү мөһим. Бу тарих, әдәбият, мәдәният институтлары, Фәннәр академиясе өйрәнергә тиешле бик зур өлкә.

Кызганыч ки, Россиядә, бүтән милләтләр белән тыгыз аралашып яшәү аркасында, без йолаларны иртә оныттык. Әйтик, казахлар, кыргызлар, үзбәкләр, Кавказ халыклары йолаларны әле дә саклый. Кавказ, Урта Азия мөселман халыкларында нинди йола булса, татарда да шул бар иде, чөнки без бер йолада тәрбияләнгән халыклар. Аерма шунда гына: аларда йолалар туксан процент, бездә сигез-ун процент сакланган. Шуңа күрә безне бүтән төрки халыклар аңлап та бетерми: ничек инде ата-бабадан килгән шундый ядкәрне онытырга мөмкин?! Югалган ул йолаларны кайтарырга мөмкин әле, нәкъ менә шул Кавказ, Урта Азия яклары халкына карап. Мисал өчен, Кырым татарларында безнең уртак йолалар бик күп сакланган.

Бик кызганыч, йоласыз йортта үсәбез. Йоласыз йортта үскән кешене әллә кайдан күреп була. Тәртипсез була ул. Шуңа күрә аның атамалары да бар: мәнсез, пәрвайсыз, тәрбиясез, анасы яламаган бозау кебек һ.б. Йоласы булмаган халык юкка чыга, монысы – һичшиксез. Менә без шуның алдында торабыз. Йола – милләтнең җаны, йөзе, тарихы, мәдәнияте.

Исламга кадәр дә йолалар күп булган. Аны да белмибез, өйрәнергә кирәк. Йола турында осталык дәресләре үткәрелергә, ул мәктәпләрдә өйрәтелергә тиеш.

Фотолар: culture.ru, islam.ru

ИСӘНЛӘШҮ ЙОЛАСЫ

Исәнләшү йоласыннан башлыйк. Гап-гади тоелган шушы гамәл дә бетеп бара бит. Бүген шәһәр балалары исәнләшә белми. Югыйсә бер подъездда яшиләр, таныйлар, әмма эндәшмиләр. Ә безгә әби көн саен: «Олы кешегә сәлам бирегез, таныш булмаса да, әссәламегаләйкем, исәнме, абый, дип әйтегез», – дип өйрәтә килде. Һәм без шулай эшләдек тә.

Ә бит Көнбатыш илләрендә таныш булмасалар да исәнләшәләр. Елмаеп: «Гуд монинг!» – дип сүз каталар. Сөйләшеп китәр өчен дә яхшы сылтау бит бу! Әйе, сәлам бирү зур культура. Бозау да «Му-у», – ди. Ә без, адәм балалары, бер-беребезгә «Му-у» да димибез. Менә сиңа шәһәр культурасы. Авылны культурасызлык дип калдырдык та килеп җиттек. Ә бит авылда нинди генә матур йола, гореф-гадәтләр яшәмәде! Менә шуларның берсен мисалга китерәм: элек авыл өйләрендә кыңгырау юк иде. Шулай да җаен тапканнар: Әминә түтиләрнең капка келәсе бер төрле шылтырый, безнеке икенче төрле, сул як күршенеке өченче төрле. Махсустыр, тимерчеләр капка келәләрен бер үк тавыш белән ясамаган. Әби токмач кискәндә: «Әминәләргә кемдер килде, улым, кара әле», – дип әйтә иде. Бу шылтырау – тәртип, ягъни сигнал булып хезмәт иткән. Янәсе, чит кеше керә, ярамаган эшләрегезне куеп торыгыз, оятка калмагыз, мине дә оятка калдырмагыз.

Озак еллар Заһидә Тинчурина белән аралашып яшәдек. «Ураза гаетләрендә бөтен туганнарда йөреп чыгып, хәер өләшә идек», – дип сөйли торган иде ул. – Кайткач, фәлән апаларга кердеңме дип сорыйлар. Оныткан булсаң, кире җибәрәләр. Килеп кергәч, тиз генә чыгып китеп булмый, күчтәнәч белән сыйлыйлар. Әби әле чәен куя. Ә өйгә кергәч, иң элек тезләнеп әбинең кулын алып үбәсең дә, башка тидереп аласың...»

Бу йола бездә хәзер юк инде. Кырым татарларында, төрекләрдә сакланган. Югыйсә кырым татарларын туздырып бетерделәр, ләкин алар йоланы саклый. Менә бу сокланырлык. Мин килеп керәм икән, алар кем икәнемне белми, әмма барысы аягүрә баса. Татар икәнемне күрәләр, чөнки мин аларныкы кебек үк баш киеменнән. Бөтен балалар йөгереп килеп керәләр дә кулымны үбеп маңгайларына куялар: «Әссәламегаләйкем, ага кеше».

Менә бит өйрәнер өчен бер дигән йола! Иң бетмәс милләтләр – йоланы саклаучылар. Кавказ да, Урта Азия дә йоланы саклый. Аларда шуңа күрә эчкечелек аз. Әрмәнстанда айныткычлар юк. Бердәнбер айныткыч булмаган ил ул – Әрмәнстан.

ТАТАРЛАР «ИСӘНМЕСЕЗ» ДИП СӘЛАМ БИРӘ. Ә БИТ КАРШЫНДА ИСӘН КЕШЕ БАСЫП ТОРА. БУ ОЧРАКТА: «ӘЙЕ, ӘЛЕ ҮЛМӘДЕМ», – ДИП ӘЙТЕРГӘ ТИЕШБЕЗ КЕБЕК. ХИКМӘТ НӘРСӘДӘ?

КАЗАН ХАНЛЫГЫ БӘЙСЕЗЛЕГЕН ЮГАЛТКАН ВАКЫТТА БИК КҮП ХАЛЫК ҮЛГӘН, АВЫЛЛАР ЯНДЫРЫЛГАН, БЕР НӘСЕЛ КЕШЕЛӘРЕ ТӨРЛЕ ҖИРЛӘРГӘ, УРМАН-ДАЛАЛАРГА КАЧКАН. БЕРАЗ ТЫНЫЧЛЫК УРНАШКАННАН СОҢ, КЕШЕЛӘР АКРЫНЛАП ТУГАН АВЫЛЛАРЫНА КАЙТА БАШЛАГАН. ШУНДА БЕР-БЕРСЕНЕҢ ИСӘНИКӘНЕН КҮРЕП, ШУҢА СӨЕНЕП: «ИСӘНМЕНИ ӘЛЕ СЕЗ», – ДИП КУЛ БИРЕШКӘННӘР.

МЕНӘ БУ СҮЗ КАЯН КИЛЕП ЧЫККАН. «ИСӘНМЕСЕЗ» ТАТАРДА АЕРЫМ БЕР ИСӘНЛӘШҮ ҺӘМ УЛ ДӨРЕС ДИЯР ИДЕМ.

ТӨРЛЕ ХАЛЫКЛАР НИЧЕК ИСӘНЛӘШӘ:

ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР, МӨСЕЛМАННАР – «ӘССӘЛАМЕГАЛӘЙКЕМ»;
ТАТАРЛАР – «ИСӘНМЕСЕЗ»;
КАЗАХЛАР– «ҖАКСЫМЫ СЕЗ»;
ҮЗБӘКЛӘР – «СӘЛАМӘТМЕ СЕЗ»;
КЕРӘШЕННӘР – «АРУМЫ СЕЗ».



ХӨСӘЕН ӘМИРХАН ЯДКӘРЕ

Идел буе
Болгар дәүләтендә
Ислам динен
кабул итүнең
1100 еллыгы
922
2022

XIX гасырда милләтнең интеллектуаль катламын тәшкил иткән дин әһелләре беренче төбәкчеләр буларак каләм тибрәтә. Кайбер хәзрәтләр үзләре имамлык кылган авыл, мәдрәсә тарихын язарга алына, күпләре төбәк һәм ил тарихындагы мөһим вакыйгаларны дәфтәрләренә теркәп бара. XIX йөзнең икенче яртысында алар Көнчыгыш чыганакларына һәм әдәбиятына нигезләнгән милли тарих китаплары авторлары булып танылa. Татар тарихы буенча беренче хезмәтне Хөсәен хәзрәт Әмирхан яза.

Фотолар автордан алынды

НӘСЕЛЕ

Күренекле татар тарихчысы Равил Әмирхан үзенең нәсел башын Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхретдин хезмәтләре, Мөхәммәдзариф хәзрәт төзегән шәҗәрә буенча Гәрәй мирзадан башлый. Аның нәсел дәвамчысы Җәлмәт (Җөлмәт) Сембер ягыннан Чистай төбәге Чирүле Шонталы авылына килеп урнаша. Аның нәселен Әхмәд, Кадермәт, Морад мулла дәвам итә. Морадның улы Исмәгыйль хәзерге Чистай районына керә торган Татар Талкышы авылында яши. Исмәгыйльнең Габделмән улыннан туган Әмирхан (1771–1828) берничә ел Бохарада укый, Казан төбәгенең Югары Курса, Тимершык, Төрек авылларында имамлык кыла. Тиздән аны Казанның Яңа татар бистәсендәге «Иске Таш» мәчетенә мәхәллә мәктәбен эшләтеп җибәрү шарты белән имам итеп чакыралар. «Әмирхания» мәдрәсәсе шулай барлыкка килә.

Хөсәен бине Әмирхан бине Габделмәннән әт-Талкыши 1816 елның сентябрендә шушы мулла гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Әтисе вафат булган 1828 елда Хөсәенгә 12 яшь тула.

Белемгә омтылучы яшүсмер, матди кыенлыкларга карамыйча, муллалык юлын сайлый: Чистай каласында, Казанда Исхак бине Сәгыйть мулладан һәм Мәчкәрә мәдрәсәсендә Габдулла бине Яхъя Чиртушидән дәресләр ала, аннары берничә ел Бохарага барып белемен тирәнәйтә. Ислам гыйлемен туплап, 1846 елда Казанга кайта. Озак та үтми, «Иске Таш» мәчете мулласы Байморад хәзрәт кызы Бәдриҗамалга өйләнә. Шушы мәчеттә Байморад хәзрәт янында икенче мулла булып эшкә керешә. Ул вафат булгач, беренче мулла булып кала.

Мәхәлләдә дини-административ эшне алып барудан тыш, укымышлы мөдәррис башлангыч мәктәптә һәм рөшди (урта) мәдрәсәдә белем бирә.

Хөсәен Әмирхан – Казан каласында яшәгән замандаш руханилары арасында, Мәрҗанидән кала, иң актив иҗат итүче муллаларның берсе. Хөсәен хәзрәтнең 14 исемдәге хезмәте (тәрҗемә, аңлатма, төрле күләмдәге рисалә, шигырьләр) барлыгы билгеле. Календарьлар бастыручы Шиһабетдин Рәхмәтулла аның турында «һәр фәндә мөтәхәббәр», ягъни диңгез кебек тирән гыйлемле шәхес, дип яза.

1884 елда Хөсәеннең Санкт-Петербургта «Нөҗүмел-тәварих» («Тарихчылар йолдызлыгы») исемле китабы басыла. Хезмәт пәйгамбәрләр турындагы риваятьләр белән башланып, сәхабә, хәлифә, ислам дөньясындагы патша, солтаннар турында мәгълүмат бирә, шулай ук Чыңгыз хан, Аксак Тимер, Наполеон кебек шәхесләрне, Кырымның Россия тарафыннан басып алынуын, ваһһабчылар хәрәкәтен һ.б. кайбер вакыйгаларны тасвирлый.

Шул ук елны аның Казанда «Шәҗәрәи галия фи бәян әл-әнсаб» («Нәсел-нәсәпләрне бәян иткән бөек шәҗәрә китабы») исемле китабы дөнья күрә. Бу әсәр Адәм галәйһиссәламнән башлап төрек солтаны Габделхәмидкә кадәр булган патша, дәүләт эшлеклеләре, мөселман галимнәренең тормыш юлын, шулай ук кыскача аерым төрки һәм ислам дәүләтләре тарихларын бәян итә.

Хөсәен хәзрәтнең гарәп теленнән тәрҗемә ителгән «Изге Мәккә тарихы, аны яулап алучыга (Мөхәммәдкә) иң күркәм мактаулар һәм хуш исле сәламнәр» исемле хезмәте дә китап булып дөнья күрә. Бу басма тарихи, географик һәм дини-рухани мәгълүматның гомумиләштереп бирелүе ягыннан кызыклы.

1890 нчы еллар башында Хөсәен Әмирханның «Әл-Фәваид» («Файдалар») исемендә татарча «Коръән тәфсире» дөнья күрә, шул рәвешле мулла дин кардәшләрен Изге китапның эчтәлеге белән таныштыруга үз өлешен кертә.

Хөсәен хәзрәт беренче хатыны вафатыннан соң биш бала белән тол кала һәм кабат өйләнә. Аның гаиләсендә бер-бер артлы алты бала дөньяга килә. Әтисенең китапларын бастыруда олы улы Мөхәммәдзариф зур ярдәм күрсәтә.

Хәзрәт 1893 елның 17 гыйнварында вафат була, Яңа бистә зиратында җирләнә.

«ТӘВАРИХЫ БОЛГАРИЯ» КИТАБЫ

«Тәварихы Болгария» китабы 1883 елда Хөсәен хәзрәтнең улы Мөхәммәдзариф мулла (татар язучысы Фатих Әмирханның әтисе) матди ярдәме белән басылып чыга. Китапның кулъязма тексты сакланмаган.

Укучыга мөрәҗәгать итеп, автор рухани кеше өчен чит булган милли тарих темасына алыну сәбәпләрен җиткерә: «[...] мин, зәгыйфь бәндә, ничә елдан бирле бик тырышып,



«Иске Таш» мәчете.
19 гасыр башы фотосы.

һәр күргән тарих китапларыннан, борынгы вакытларда яшәгән карт галимнәрнең китап битләре кырыенда язылган һәм дөреслеккә охшаган сүзләрен күп заманнан бирле җыеп килгән идем. Шулай ук төрки халыклар тарихларындагы кыйссаларны чүпләп һәм могтәбәр китаплардан күчереп, ул китапларның күбесенең исемнәрен искә алып, тәртипкә китереп яздым. Барысы бергә ниндидер фикергә килергә файдалы булыр». Димәк, бу хезмәт кимендә өч дистә ел дәвамында җыелган материаллар нигезендә язылган. Шуңа да андагы вакыйгалар борынгыдан башлап бүгенге кадәр көнгә кадәр дәвам ителәэ, бөтен Евразияне колачлый.

Хөсәен Әмирхан – татарлар арасында милли тарих үзәккә куеп язылган беренче тарихи хезмәт авторы. Аның «Тәварихы Болгария»се Шиһабетдин Мәрҗанинең мәшһүр «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр», 1885, 1900 еллар) исемле китабыннан ике ел алдан басыла.

Хөсәен Әмирхан китабының кереш өлешендә Җир планетасының мәйданын, аның түгәрәк формада булуын әйтеп, континентларны һәм Көнчыгыштагы илләрне санап чыккач, «Болгар йортының» урнашкан урынын үзе бүлгән җиде климат өлкәсенең соңгысына (Әстерхан диңгезеннән Кытай диңгезенә кадәр сузылган мәйдан) кертә.

«Тәварихы Болгария» китабының төп өлеше 7 бүлек һәм йомгактан тора. Автор, тарих язу тәртибен кабул итеп, текстта үз дәлилләрен китергәндә, аларның чыганакларын атап бара.

Мөселман кешесе күзлегеннән караганда кешелек тарихы ике зур, бер-берсеннән тирән упкын белән аерылып торган өлешләргә бүленә: исламгача һәм ислам тәгълиматында яшәгән чорлар. Китапның беренче ике бүлеген исламгача чор тарихы тәшкил итә. Автор аларны, чын мөселман буларак, бик кыска – тарихи фактларны бер-бер артлы тезеп, үзеннән бер сүз-фикер дә өстәмичә, бик кыска итеп язып чыга.

Өченче бүлек мөселман Туран дәүләте әмире Аксак Тимернең хәрби батырлыкларын бәян итә.

Китапның беренче өч бүлеге нигездә Алтын Урда ханнары нәселеннән булган Әбелгазый Баһадир бине Гарәб Мөхәммәд хан әл-Чыңгызый әл-Хәрәзминең (1603–1663) «Шәҗәрәи төрек» исемле тарихи китабын файдаланып язылган.

БОЛГАРЧЫЛЫК КОНЦЕПЦИЯСЕ

Хөсәен хәзрәт китабының дүртенче, бишенче һәм алтынчы бүлекләрендә язылган текст Шиһабетдин Мәрҗани фикерләренә күп яктан каршы килә. Бу каршылык, нигездә, XIX гасыр башында язылган аноним автор Шәрәфетдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария»не бәяләвенә нигезләнгән дисәк, зур хата булмас. Шиһабетдин Мәрҗани, тарихчы күзлегеннән, бу әсәрне фактик ялгышларын калку күрсәтеп, кискен тәнкыйтьли, аны тулысы белән ялганга чыгара.

Кульязма формасындагы һәм китап буларак басылган (Казанда, 1870, 1887, 1892 һәм 1902 елларда) Шәрәфетдин Мөслими әсәрендә, кайбер башка вакыйгалардан тыш, Болгар халкының исламны Мөхәммәд пәйгамбәр җибәргән өч сәхабәдән кабул итүе сурәтләнә.

Хөсәен Әмирхан исә Шәрәфетдин Мөслими китабындагы ялгышларны һәм төгәлсезлекләрне күрсәтә, автор белән бәхәсләшә, чынлыкта аның фикерен нигез итеп ала, яңа фактлар белән баетып ныгыта һәм тирәнәйтә.

Автор дүртенче һәм бишенче бүлекләрдә үзе кулланган тарихи чыганаклар нигезендә Мөслиминең Аксак Тимернең Истанбулны яулап алуга бәйле җөмләләрен, рус шәһәре Владимирга һөҗүме фактын инкарь итә.

Шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан җибәрелгән сәхабәләрнең Болгарга килеп җирле халыкны вәгазьләүләре дөреслеккә туры килми, дип ассызыклый. Дүртенче бүлектә мөселманнарның Россия составында яшәгән вакытларына мөрәҗәгать итеп, кайбер вакыйгаларны санап үтә. Вакыйгалар тезмәсе хронологик планда бирелеп, Александр III нең тәхеткә утыруы белән тәмамлана. Алтынчы бүлектә болгарларның ислам динен кабул итү вакыты Габбасилар хәлифәте заманында дип раслый. Анының, болгарлар ислам динен һиҗрәттән соң, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәр (милади буенча 662 ел булып чыга) Мәккәдән Мәдинә каласына күченгәннән соң 210 ел узгач кабул иткән.

Шул рәвешле автор Болгар җирендә табигыйннар турында кыйссаларны да «буш сүз»гә чыгара. Ялган табигыйннарның каберлекләре урынына автор олы хөрмәт белән Идел-Урал төбәгендә XVIII–XIX гасырларда яшәгән һәм яңа буын дин әһелләре әзерләгән, халыкка дини һәм әхлакый тәрбия биргән берничә дистә күренекле ислам голәмәсе исемен атый һәм кайбер хезмәтләргә тасвирлама бирә. Аларга шигырь юллары – мәрсияләр багышлый.

Җиденче бүлек – хезмәтнең иң мөһим өлеше. Автор Болгар белән Казан ханлыгы бәйләнешен һәм бу ике дәүләтнең үткәнен бердәм тарих рәвешендә сурәтли. Хөсәен Әмирхан, Аксак Тимер Болгарны басып алып Габдулла ханны әсир иткәч, ханның хәләл җефете, Алтынбәк һәм Галимбәк исемле улларын алып, Бу (и) ләргә качкан, дип яза. Аның гозерен үтәп, Аксак Тимер, күп мал биреп, Иске Казан урынында йорт төзергә боера. Алтынбәк һәм Галимбәк, Иске Казанны төзеп, биредә 104 ел хакимлек итә.

Башта Габдулла ханның улы Алтынбәк 52 ел идарә итә, 76 яшендә хаҗ сәфәренә китеп, кире кайтмый. Аннан соң 31 ел Галимбәк хан була, ул Болгарга кайтып, җимерелгән мәчет һәм манараларны төзекләндерә, 73 яшендә вафат булып шунда җирләнә.

Галимбәк Болгарга киткәндә үз урынына Әлмөхәммәд исемле улын калдыра. Улы, 11 ел идарә иткәч, 1418 елда Казансу тамагында Яңа Казанга нигез сала, биредә тагын 9 ел ханлык кыла.

Бу бүлектә Идел-Урал төбәгенең Болгар җире икәне болгар ханнары һәм халкының «Болгар (Бүләр) – Иске Казан – Яңа Казан (хәзерге Казан)» төбәкләре буенча күченеп йөрүе белән дәлилләнә. Галимбәк ханның Болгар хәрабәләренә кайтып, мәчет-манараларны торгызуы, шунда вафат булуы һәм җирләнүе символик мәгънәгә ия. Дәүләтнең үзәге Иске Казанга, икенче төбәккә күчерелгәч тә, Болгар кабат дини-рухи архитектура символына әверелә.

«Казанда ханлык кылган ханнар» исемле бүлектә дәүләтнең сәяси тарихы Болгардан килгән нәсел варислары булган ханнар исемнәре аша яктыртыла... Әлмөхәммәд хан Алабугага киткәндә үз урынына Галимбәкнең улы Мәмәтгәрәй бәкне калдыра. Ул кәеф-сафа корып яшәү сәбәпле, җирле элита вәкилләре тәхеткә Алтынбәкнең улы Хәлилне утырта. Шул рәвешле Хөсәен Әмирхан Казан төбәгендә болгар ханнары оештырган яңа дәүләтнең сәяси тарихын сөйли. Биредә автор бүгенге Идел-Урал төбәге мөселманнары – Болгар иле кешеләре дигән фикерне уздыра.

«Кабан күле кыйссасы» һәм «Бистә кыйссасы» исемле бүлекчәләрдә Казан ханнары һәм Сөембикә турында кыйссалар бәян ителә. Кызганыч, бу бүлектә дә авторның рус чыганакларын һәм рус телендәге тарихи әдәбиятны белмәве үзен нык сиздерә. Кайбер ханнарның исемнәре чынбарлыкка туры килсә дә, аларның шәҗәрәләре фантастик кыяфәт ала...

Төбәк тарихына караган «Черек күл кыйссасы» һәм «Яңа бистә» өлешләре бу ике урынның барлыкка килүе турында хикәятләрдән тора. Төбәк тарихына шулай ук турыдан-туры караган йомгак өлешендә Казан каласы мәхәлләләренең руханилары турында мәгълүмат бирелә.

Муллалар турында язган бүлекләрдә 70тән артык дин әһеле исеме атала. Алар арасында Шиһабетдин Мәрҗани һәм Ризаэтдин Фәхретдин әсәрләренә кермәгән шәхесләр дә юк түгел. Китапның бу өлешләре – бүгенгәчә яңалыгын саклаган һәм яңа шәхесләрне ачарга һәм танырга мөмкинлек бирә торган, фәнни яктан зур кыйммәткә ия урыннар.

Мөслими китабындагы ялгышларны тәнкыйтьләп һәм бер үк вакытта аның концепциясен милли тарих форматында үстереп, Хөсәен Әмирхан Идел-Урал мөселманнарының дини бердәмлеге болгарларның исламны кабул итүеннән башлана, шуңа күрә Болгар һәм Идел-Урал төбәге мөселман җәмгыятенең үткәне – олы бер тарихның өлеше, дигән фикерне алга сөрә. Автор Чыңгыз хан һәм «Болгар илен» басып алган Җучи уллары турында яза, ягъни чыңгызыйлар Болгар иле тарихы белән җимерүче сыйфатында гына кисешә. Автор аларга Идел-Чулман төбәгендә хан һәм бәкләр булу, шулай ук төркиләшү һәм мөселман булу мөмкинлеген калдырмый. Хөсәен Әмирхан, Алтын Урда чорын «сикереп үтеп», Казан җирләрендә дә болгарлар белән Габдулла хан нәселе дәвамчылары идарә иткән, дигән фикерне үстерә.

Шиһабетдин Мәрҗани дә Идел-Урал төбәгендә көн күргән татарларның килеп чыгышында төп өлешне болгарлар һәм өлешчә алар тарафыннан исламлаштырылган күрше мәҗүси халыклар тәшкил итә, дип саный. Ләкин ул Алтын Урда чорын туган халкы тарихының аерылгысыз бер өлеше булуын таный, кавемдәшләрен «татар» исемен кабул итәргә өнди.

Ислам ядкярләре

КАЗАНДАГЫ ӘҖЕМ МӘЧЕТЕ

Әлеге мәчетнең шәһәр өстеннән 51 метр югарыга күтәрелгән манарасы замандашларын үзенең нәзакәтле затлылыгы белән сокландырган. Шәһәр читендәге эшче алачыклары һәм сабын кайнату заводлары тирәсендә төзелгән мәчет Елисей кырындагы Эйфель башнясыннан кәттәрәк күренә, җитмәсә, Парижның әлеге бизәгеннән бары тик бер генә елга соң, ягъни 1890 елда салына...



Исеме билгесез архитектор каршында баш иик. Мәчетне проектлаштырганда булдыра алмастайга ирешә: европача тыйнаклыкны – көнчыгыш купшылыгы, кыю фантазияне кырыс кануннар белән яраштыра ала. Бәлки, бу урынның догалы булуы да ярдәм иткәндер: бик күптәннән, таш манара күккә ашканчы ук, биредә инде Илаһка мактау сүзләре яңгыраган. Бәлки, архитекторны үз хисабына мәчет төзетүгә керешкән күренекле татар фамилиясе вәкиле – сәүдәгәр шәхесе илһамландыргандыр?

ЭШЧЕ БИСТӘСЕНДӘ ИМАН НУРЫ

Шиһабетдин Мәрҗани үзенең тарихи хезмәтләрендә болай дип хәбәр итә: биредә беренче мөселман мәхәлләсе әле 1810 елда ук пәйда була. Нәкъ шул вакытта Казанның көньяк-көнбатыш өлеше (Пләтән авылы тирәсе) бик тиз үсә: сәүдәгәр Апанаев, Китаев, Юнысовларның сабын кайнату заводлары эшчеләре күпләп урнаша башлый. Хаҗи Габделмәҗит Әбүбәкеров акчаларына салынган беренче мәчет агачтан, бер катлы, хәтта манарасыз була. Ул дүрт дистә ел тора һәм шактый кысан була: җомга һәм бәйрәм намазларына мәхәллә кешеләренә «Иске Таш» мәчетенә барырга туры килә.

Илленче еллар башында искесе урынына яңа мәчет күтәрелә, шулай ук агачтан, анысының инде манарасы була. Аны татар шәһәр Ратушасы башлыгы Мостафа Әҗемов төзетә, аның байлыгын замандашлары ике миллион сум дип бәяләгән. Иң бай һәм абруйлы татар сәүдәгәрләренең берсе булган Мостафа Әҗемов мондый савaплы эшкә акчасын кызганмый, әмма тиздән бу мәчет диварлары да кысан тоела башлый. Иркенрәк яңа бинаны шулай ук агачтан 19 гасырның 60 нчы елларында Әҗемовның олы улы – Мортаза салдыра.

Нәкъ менә беренче гильдия сәүдәгәр, ике кипе-мамык тукыма фабрикасы хуҗасы булган Мортаза тагын өч дистә елдан соң шәһәргә таш мәчет бүләк итәчәк. Әлеге гаҗәеп матур мәчет киләчәктә Казанның йөзек кашына әйләнәчәк.

Фото: Әскәр Сабиров

ТАШ СЫЛУ

Ак ташны уеп ясалган челтәр, мәзин өчен нәфис түгәрәк балкон белән бизәлгән төз манара. Пропорцияләре буенча гаҗәеп дөрес, эчтән тыйнак та, тантаналы да, тыштан нәфис фасадлы ике намаз залы. Ташта «сәлҗук чылбыры» рәвешендәге бизәкләр, витражлар, уксыман аркалар, тәрәзә уемнары өстендәге бизәкле ярымәйләнәләр... Ниһаять, «Сөләйман мөһерләре» – диварлардагы алтыпочмаклык-гексаграммалар... Бизәлеш эшләрендә кулланылган күптөрле көнчыгыш элементларына да карамастан, Әҗем мәчете гаҗәеп нәзакәтле, нәфис килеп чыга.

Әлеге искиткеч матурлык беренче гильдия сәүдәгәр Мортаза Әҗемовка 14 000 сумга төшә – заманы өчен гаять зур акчалар. Төзелешкә дүрт ел китә. Эшләр 1887 елның 18 мартында – Казан губерна идарәсе мөселман завод мәхәлләсенең «бөтенләй тузган хәлдә калган гамәлдәге агач мәчет урынына таштан яңасын салдыру турында»гы үтенечен, «шулай ук сәүдәгәр Мортаза Мостафа улы Әҗемовның үз хисабына төзелеш алып барырга ризалыгы турында имзалы кәгазен» алганнан соң башлана.

Агач мәчет, ихтимал, алай ук тузган хәлдә дә булмагандыр. Яңа төзелешкә рөхсәт алганчы ук сәүдәгәр, мәчетне сүттереп, Лаеш өязенең Чыты авылына (хәзер Питрәч районы) кайтарткан, дип сөйлиләр. Мәхәлләдә ул чакта 444 мөселман ир-аты, 283 мөселман хатын-кызы яшәп, ул мәчет барыбер кысан булуы – икенче мәсьәлә.

Ничек булса була, әмма 1890 елда яңа таш мәчет манарасыннан беренче азан тавышы яңгырый.

КЫЗЫЛ ТЕРРОРГА КАРАМАСТАН

Иң башта бу гүзәл гыйбадәтханә рәсми төстә Завод мәчете дип атала, чөнки мәхәлләнең зур өлешен сабын кайнатучы эшчеләр тәшкил итә. Әмма ул тарихка икенче исем – Әҗем мәчете буларак кереп кала, һәм бу дөрес тә. Сәүдәгәр Мортаза Әҗемов акчасына төзелгәнгә генә дә түгел. Мортаза Әҗемов эшче бистәләрен төзекләндерергә булышуы, изге эшләргә акчасын юмарт өләшүе белән мәхәллә халкының ихтирамын яулый. Ул үзе мәчет ачылышын күрергә өлгерми. Ләкин аның эшен балалары дәвам итә.

Октябрь революциясеннән соң һәм атеизм чоры башлангач, Әҗем мәчетен илдәге бөтен гыйбадәтханәләр язмышы көтә. Имамнарны да, иганәчеләрне дә сөрәләр. Дөрес, мәчет әле озак еллар дәвамында эшли: элеккеге мәзин Мөхәммәтгали Сабитов, тәвәккәлләп, бередә вәгазьләр укый, балаларга ислам нигезләрен укыта.

Гыйбадәтханәне Татреспублика ҮБК карары белән 1930 нчы еллар ахырында ябалар.





Әмма, күрәсең, большевиклар да мәчетнең никадәр матур булуын аңлый. Манараны кисәргә куллары күтәрелми. Хәер, бу намаз залларын үзләре теләгәнчә кулланырга комачауламый. Төрле елларда бередә тулай торак, киномеханиклар өчен мәктәп урнашкан була.

1989 елда Әҗем мәчетен дин тотучыларга кире кайтаралар, өч елдан соң федераль әһәмияттәге һәйкәлдә реставрация эшләре башкарыла. Шунысы гына кызганыч: илнең иң матур мәчетләренең берсе төп туристлык маршрутларыннан читтәрәк калган. Югыйсә ул бер генә мәртәбә булса да барып күрүгә лаек мәчет.

Адрес: Фәткуллин ур., 15

Әҗем мәчете манарасын кисәргә хәтта большевикларның да куллары күтәрелми.

МЕНДЕЛЕЕВСКИДА «ХӨСӘЕН» МӘЧЕТЕ

Менделеевскида яңа «Хөсәен» мәчете ачыла. Әлеге мәчетнең төзелеше вакытында булган могҗизага тиң күренешләр турында Раил хәзрәт Хөсәенов сөйләде

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы
922
2022

БЕРЕНЧЕ МОГҖИЗА

– Барысы да бик гади генә башланып китте, – дип сөйли Раил хәзрәт. – Клуб янындагы урамда ике кишәрлек җир сатып алдым, анда токымлы кәҗәләр үрчетергә ниятләгән идем. Инде кирәк-ярак материаллар да кайтарта башладым... Шунда бер егет, сүз уңаеннан, христиан диненнән: «Мондый эш өчен җирең артык зур», – диде.

Ә мин үзем дә сизмәстән: «Монда мәчет булачак!» – дип әйтеп салдым.

Теге егет бу нияткә бик шатланды: «Шәп! Мин сиңа төзелештә ярдәм итәрмен!» – диде.

Моңа гаҗәпкә калдым, өйгә кайткач, энигә бу сөйләшү турында әйттем. Ә үземнең күңелдә инде мәчет төзисем килә дигән уй ныгып та өлгерде.

Әни дә канатланып китте: «Әйдә, – ди, – улым, бергәләп төзи башлыйк. Димәк, безгә Аллаһы Тәгалә шулай язган!»

Намаз укыдым да, «Таң» мәчетенең имамы Ирек хәзрәткә шалтыратып, әлеге ниятем турында сөйләп бирдем. Ул да мине хуплады, шунда ук район башлыгына шалтыратты. Радмир Беляев та бу идеяне күтәреп алды. Һәм мәчет төзү мәсьәләсе бер сәгать эчендә хәл ителде дә куйды. Монда аның урыны да яхшы – халык күп йөри торган. Элек бу урында клуб булган. Миңа да, Аллаһ рәхмәте белән, нәкъ шундый җәмәгать урыны туры килде.

ИКЕНЧЕ МОГҖИЗА

– Ләкин төзелеш җиңел эш түгел бит, чыгымлы. Акча каян алырга? – ди Ирек хәзрәт Нуриев. – Башта Раил абый күршедәге кишәрлекне сатып алыр өчен машинасын сатты. Чөнки күрше хатыны мәчет күләгәсе аның бакчасына төшеп, яшелчәләргә үсәргә комачаулаячак дип зарланды. Төрле инстанцияләргә шикаятьләр яза башлады, безне ваһһабчылар

Фото: Александр Гәйнетдинов



дип атады... Аның белән низаглашмас өчен, Раил абый җирне сатып алды. Аннан соң бер-бер артлы могҗизалар була башлады... Гүя безгә төрле яклап ярдәм итәләр. Мәсәлән, безгә йөри торган бер апаның Казанда яши торган улы мәчеткә дип, казан һәм радиаторлар сатып алды...

ӨЧЕНЧЕ МОГҖИЗА

– Төзелеш материалларын алып кайтырга кирәк, – дип сөйли Ирек хәзрәт Нуриев. – Акча җитеп бетми. Без Раил хәзрәт белән йөк машинасында бер мөселман кешесен туктаттык та ярдәм итүен сорадык. Ә ул безгә: «Соңгы акчама машинага солярка салдым. Сезгә дә юк дип әйтә алмыйм, ләкин аннан соң барасы җиремә ничек барып җитәрмен?» Мин түлим дидем. Ул дүрт рейс ясады, Чаллыга, Мамадышка... Мин бу вакытта акча эзләдем. Таптым – түләдек. Ә ул соңыннан заправкадан шалтырата: «Күз алдына китерәсезме, могҗиза: бакка күпме солярка салган булсам, шуның кадәр калган. Тамчысы да сарыф ителмәгән!»

ДҮРТЕНЧЕ МОГҖИЗА

– Бервакыт төзелеш барганда, бер әби килде дә чукына башлады, – дип искә ала Ирек хәзрәт. – Мин аңа: «Әби, бу мәчет бит, чиркәү түгел!» – дим.

Ә ул миңа тыныч кына: «Беләм, улым!» – ди, үзе һаман чукынуын дәвам итә.

Аннан соң кара полиэтилен капчыгын калдырып китеп барган. Без онытылган капчыкны бераздан гына күрдек әле... Күргәч, әбине эзли башладык, таптык. «Әби, оныткансыз бит!» – дибез, капчыкны сузып.

Ә ул: «Беләм, улым! Сез аны ачып карадыгызмы?» – ди.

«Юк!» – дип аптыраштык без.

«Ачыгыз, – дип рөхсәт итә әби, – анда мәчеткә дигән 100 мең сум акча!» Безгә плитә алырга нәкъ шул сумма җитми иде! Төп-төгәл!

Шулай әкренләп төзибез. Акча бетә, монысын эшләргә каян акча табарбыз дип баш ватабыз. Һәм һәрвакыт әллә каян, көтмәгән җирдән кирәк кадәрле акча килеп керә.

БИШЕНЧЕ МОГҖИЗА

– Мин, гомумән, башта бары тик үз акчама гына төзергә ниятләгән идем, – дип искә ала Раил хәзрәт. – Нигезен казыдым, блоклар сатып алдым... Арматура аласы бар. Интернеттагы игълан буенча шалтыраттым да, шундыйшундый арматура кирәк, дидем. Ә теге яктагы кеше: «Нәрсә өчен? Нәрсә төзергә кирәк?» – дип төпченепме-төпченә. Өч тапкыр сорагандыр. Мәчет өчен дип әйтергә туры килде.

«Иртәгә киләм, алып киләм!» – ди.

Чаллыдан арматура алып килде, акча алмады. Менә шулай ничектер килеп чыга үзе...

АЛТЫНЧЫ МОГҖИЗА

– Район күләмендәге ифтарга әзерләнә торган вакыт, – дип искә ала тагын бер могҗизалы хәлне Ирек хәзрәт. – Район башлыгы ифтарга ниндидер кунак алып килүе турында әйтте. Ә безнең эшчеләргә бер эш өчен түләр вакыт җиткән чак... Һәм бу кунак мәчет төзелеше турында ишетте дә эшчеләргә түләргә кирәк булган кадәр суммада акча бирде.

ҖИДЕНЧЕ МОГҖИЗА.

– Барысы да ярдәм итә, – дип дәвам итә Ирек хәзрәт. – Ярдәм тиененә кадәр төгәллек белән килә. Раил абыйның әнисе пенсиясен шушы мәчет төзелешенә тотты. Мәчет белән янәшә мәдрәсә бинасы да төзедек. Ул фатирын сатты –
аның акчасына тәрәзәләр куйдык, җылылык керттек, анда барысы да бар.

Һәм бу бетмәс-төкәнмәс сәдака дип атала. Кирпеч янына кирпеч... Бу мәчет эшләп торганда, аның төзелешенә ярдәм иткән һәркемгә савабы килеп торачак. Көн саен, азан яңгыраган, намаз укылган саен аңа Аллаһның рәхмәте иңәчәк. Ул кеше мөселман өммәтеннән булмаса да, аның ярдәме үзенә савап булып кайтачак. Кеше ихлас йөрәктән игелек кыла икән, Аллаһ аңа тулысы белән кайтарачак аны.

Мәчетнең ишекләре ачылуын көтәбез.

– Иншаллаһ! – ди Раил хәзрәт.

Һәм бу бетмәс-төкәнмәс сәдака дип атала. Кирпеч янына кирпеч... Бу мәчет эшләп торганда, аның төзелешенә ярдәм иткән һәркемгә савабы килеп торачак. Көн саен, азан яңгыраган, намаз укылган саен аңа Аллаһның рәхмәте иңәчәк.

КЕЛӘНЧЕ – ТАРИХНЫ ТОРГЫЗУ...

КЕЛӘНЧЕ

Гел күзәтәм – һәр район үзенчә, башкалардан нәрсә белән булса да аерыла. Халкының яшәү рәвеше, холык-фигыленнән башлап, авыл, урамнарына кадәр төрле. Кама Тамагының Келәнче авылы турындагы хатирәләр дә күңелдә әле озак сакланачак…

Руфия Фазылова

СОҢГЫ ТАПКЫР «ЧАБЫР» БӘЙРӘМЕ 1940 ЕЛДА УЗГАН

Келәнченең урнашуы кызык: бер ягында – Апас, икенчесендә Тәтеш районына кергән авыллар. Бу авыллар белән алар гомергә тату яшиләр, бергә бәйрәмнәр үткәрәләр, килен төшерәләр, йомышка йөриләр. Заманында балалар бер үк мәктәпкә укырга да йөргән.

Узган гасыр башында Келәнче районның иң зур авылларыннан берсе булган. Инкыйлабка кадәр ике меңнән артык кеше яшәгән. Бүген исә бирердә 114 хуҗалык бар, 242 кеше гомер итә. Әле 2000 нче еллар башында да авылда 180 хуҗалык исәпләнгән. Ләкин әлеге дә баягы бирердә дә яшьләр читкә китү ягын карый. Нәтиҗәдә урта мәктәп ябылган. Ике ел элек балалар бакчасының да ишегенә йозак эленгән. Ни кызганыч... Ике катлы итеп салынган зур мәктәп бинасы бүген бөтән вазыйфаны үти: мәдәният йорты, авыл җирлеге идарәсе, ФАП, китапханә – халык өчен барлык кирәкле социаль объектларны берләштергән. Ә иске мәдәният йорты авария хәлендә икән. Яңа бина төзеп тормас өчен, мәктәпне шулай «эшкә җиккәннәр».

Келәнчегә килгәнче үк, күптән түгел бирердә узган «Чабыр җыены» турында ишеткән идек. Бик зурлап, бөтен шартын туры китереп үткәргәннәр аны. Шуның өчен дә Келәнче **авыл җирлеге башлыгы Дамир Кадыйров** башта безне «Чабыр» бәйрәме узган урынга алып китте.

1

Ике катлы итеп салынган зур мәктәп бинасы бүген бүтән вазыйфа үти.

2

«Чабыр» дип язылган тимер эскәмиягә кадәр ясаганнар.

3

«Чабыр» уздырыла торган урынга таш урнаштырып, аңа элмә такта да яздырып куйганнар.

4

– Милли тәрбия дип, җан атып яшәдем, – ди Рәйсә Хәсәнова.

Табигать могҗизасы – авыл читеннән үк мәгърур таулар башлана. Җиләк җыярга теләсәң, ике йөз метр гына читкә китәсе. Киң болыны, күле, татлы сулы чишмәсе – барысы да шунда. «Чабыр» бәйрәмен нәкъ менә биредә уздырганнар икән.

– Соңгы тапкыр «Чабыр»ны сугышка кадәр – 1940 елны үткәргәннәр, – дип аңлатты авыл җирлеге башлыгы. – Ничә дистә елдан соң без аны яңарттык.

– «Чабыр» Сабан туена охшаган бәйрәмме ул? – дим.

– Юк, Сабан туеннан аерыла, ярминкә кебек узган ул. Язгы кыр эшләре тәмамлангач үткәргәннәр. Үзенә күрә зур бәйрәм булган.

– Ә ни өчен «Чабыр»? – дим.

– Күрше Бәки авылы белән ике арада Чабырлы тау бар. Менә шушы без басып торган җирләрдән башлана ул таулар. Ярминкә әлеге тау астында узган. Шуның өчен дә «Чабыр» исеме бирелгән.

Баксаң, әлеге таулар заманында мөһим роль уйнаган – 1958 елга кадәр биредә һәр ял саен базар булган. Анда бөтен күрше-тирә авыллардан килеп сәүдә иткәннәр. Мал-туар, кош-корт, ит, бал, он, тәм-томнар, көнкүреш кирәк-яраклары – ни генә сатмаганнар. Чабырлы тауда һәр авылның бикләнә торган ларекларына кадәр булган. Һәм менә быел биредә янә сәүдә нокталары эшләгән, көне буе җыр-моң тынмаган...

Авыл җирлеге башлыгы «Чабыр жыены»н оештыручыларның берсе – Рәйсә Хәсәнова янына алып барды. Хуҗабикә хәләл җефете Хәниф белән өч бала – бер малай, ике кыз тәрбияләп үстергән. Әлеге үткән ханымнан башка авылда бер чара да үтми диярлек – сәнгатькә гашыйк кеше.

– Утыз елдан артык Келәнче балалар бакчасында җитәкче булып эшләдем, – диде Рәйсә апа. – Милли тәрбия дип, җан атып яшәдем. Күбрәк рус районы булсак та, татарлыкны гел алга сөрдек. Балалар белән милли йолаларны күрсәтү, төрле бәйгеләрдә катнашу дисеңме. Татар теле һәм әдәбияты укытучыбыз Фәния апа Гыйльметдинова кечкенәдән ана теленә мәхәббәт тәрбияләде. Бәлки, шуның өчен дә безнең авыл сәнгатьле сөйләү, әдәбиятка тартылу белән аерылып торадыр. Үзем дә кечкенәдән җыр-моңга, сәнгатькә гашыйк. Кайвакыт: «Эх, мәдәният йортында эшлисем калган», – дип тә уйлый идем.

Мәдәният йортында эшләмәсә дә, Рәйсә апа гел сәхнәдә – җырлый, сөйли, бәйрәмнәрне алып бара. Район, республика буенча оештырылган төрле чараларда еш катнаша. Шуның өчен дә «Чабыр» бәйрәмен оештырганда, авыл җирлеге башлыгы аңа мөрәҗәгать иткән.

– Күмәк эш булды ул, – диде Рәйсә апа. – Мәдәният йорты хезмәткәрләре, авыл җирлегендә эшләүче кызлар да бик тырышты, аларны әйтми калсам, бер дә дөрес булмаячак. Әлбәттә,

НАИЛ АЛЬБЕРТ УЛЫ ВАЗЫЙХОВ, КАМА ТАМАГЫ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ:
– Келәнчедә узган «Чабыр» бәйрәме турында бик уңай фикердә калдым. Һичшиксез, Авыл көне, Сабантуй бәйрәменнән югарырак масштабта узды ул. Аннары әлеге чараның тарихы да бик үзенчәлекле бит. Шуның өчен дә бу бәйрәмне алга таба да дәвам итәргә кирәк, дигән нәтиҗәгә килдек. Шушы авылда туып-үскән РФ Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов белән дә сөйләштек – «Чабыр җыены»н республика югарылыгында уздырыла торган бәйрәм итәргә кирәк. Быел ук димим, чөнки әле тагын да ныклап әзерләнергә җирлек бар. «Чабыр» турында бөтен Татарстанга шауларга кирәк. Киләсе елга шуны эшләп чыксак, аннары инде ныклап торып республика югарылыгында уза торган бәйрәмнәр рәтенә кертү өчен документлар җыярга мөмкин булачак. Ә бу «Чабыр» бәйрәмен тагын да югары баскычка күтәрү булачак, шул исәптән финанс ягы да караланачак.

авыл кешеләренә мең рәхмәт. «Чабыр» үткәрик дигәч, дәррәү күтәрелделәр. 300 мең сум акча җыелды. Сабан туена да моның кадәр акча җыелмый иде. Тарихны торгызу бәһасез бит. Авылдашлар да әнә шуны аңлады, зур сөенеч бу!

Чынлап та, «Чабыр җыены»н зурлап уздырганнар. Әлеге урынга 8 тонналы таш урнаштырып, аңа элмә такта да яздырып куйганнар. «Чабыр» дип язылган тимер эскәмияне алтын куллы авылдашлары Ринат Гомәров бәйрәмгә махсус ясаган.

– Киләсе елларга тагын да зуррак итәсе иде, – диде Рәйсә апа. – Бөтен район халкы килсен. «Чабыр җыены» бит нигездә ярминкә булган. Шуның өчен дә күбрәк сәүдә нокталары кирәк. Дөрес, быел да булды ул. Ләкин аны тагын да колачлырак итәсе килә.

ҮҖӘТЛЕК КАЯ ИЛТӘ?

Келәнчедә мал асрауны ташламаган халык – авыл көтүе дә бар. Өч гаилә үзләренә мини-ферма да ачкан. Ә менә Рамил Сафин барысын да уздырган – хуҗалыгында өч йөзләп мөгезле эре терлек бар. Моңа өстәп 400 гектар җир, дистәләп техника... Табышмактагыча – ура, суга, җилгәрә... Әле абыйсы белән икесенә йөз баш умарталары да бар икән.

– И, минем хәлләрне сөйләсәң, кеше ышанмаслык, – диде тәҗрибәле фермер. – Келәнчедә туып-үскән егет мин. Гомер биредә узды дияр идем, армиядән соң читтә эшләп алырга туры килде үзе. Әти авырый башлагач, авылга кайту турында уйладым. Фермер булам дип кайттым. Тәҗрибә бар, агроном, ферма мөдире булып та эшләдем. Ул чакта авыл җирендә үз эшеңне башлар өчен дәүләт 58 мең сум акча бирә иде. Ике дә уйламыйча шуны алып, өч бозау сатып алдым. 2005 ел иде. Әтинең дә маллары бар, иш янына куш булды. Т-25 тракторы бар иде, аны эшкә җиктем. Теге бозауларны үстереп, сыер иттем. Хатын сава, мин малларны ашатам. Шул елларны «Гаилә фермасы» программасы чыкты. Районның авыл хуҗалыгы идарәсенә киттем. «Программага кертегез әле, кредит аласым килә», – дим. Керттеләр. Озак та тормады, «Россельхозбанк»ка 25 миллион сум акча килеп төште. Ләкин ала алмыйм, лаеклы ялга китәргә



5 Үҗәтлеге, тырышлыгы нәтиҗәсендә Рамил Сафин бүген районның иң эре фермерларыннан берсенә әйләнгән.

жыенучы банк җитәкчесе: «Син айга 70 мең сум акчаны банкка түләп бара алмаячаксың», – ди. Озын сүзнең кыскасы, алты ай исәп-хисап счетында ятканнан соң, ул акчалар кире китте.

Тик Рамил абый барыбер туктап калмый. Зур процентлар белән шәхси банктан 4 миллион сум акча ала. Йортын, машинасын залогка куеп! Егерме баш сыер сатып алып, ныклап торып фермерлык эшенә тотына.

– Төннәр буе йокламыйча яткан чаклар булды, – дип дәвам итте Рамил Сафин. – Кредитларга чумып, йортсыз да калмабызмы? Дүрт бала да бар бит. Аллаһның рәхмәте, сөт акчасы кредитны түләп барырга җитте. Әрләшә-талаша дигәндәй, арендага җирләр дә ала башладым. Көн туды исә, берәр проблема килеп чыга. Шуннан соң әле фермерларны үстерергә бирелә торган грант та алдым. Ул акчага яңа ферма бинасы, техника алдым. Сөйләсәң күп инде...

Үҗәтлеге, тырышлыгы нәтиҗәсендә Рамил Сафин бүген районның иң эре фермерларыннан берсенә әйләнгән. Быелгы ел өчен сөенеп бетә алмый: печән төргәкләрен алып кайтып өйгән, сенаж салынган. Ә басуда игеннәр шаулап утыра.

– Мондый еллар сирәк була, – диде фермер. – Гектарыннан 40 центнер иген җыеп алырбыз, дип өметләнәм. Печән дә бик яхшы булды, ел ярымлык итеп запас әзерләп куярга телим. Фермер өчен быелгы җәй лотерея билеты откан кебек инде!

Рамил абый умартачы да. Әтиләре күп еллар колхоз умарталыгын карап торган. Балалар исә аңа ярдәм иткән. Башлангычта укыганда ук корт иле җыярга өйрәнгән. Әтиләренең һөнәрен дәвам итүләренә ихластан сөенә ул.

– Кортлар хәзер абый өстендә, – дип дәвам итте Рамил Сафин. – Вакыт җитми бит. Фермерлык эше бик күп вакытны ала. 2000 нче елларда колхоздан калган ул умарталык юкка чыккан иде дияргә була. Һич онытасым юк, әти үзен кортлар янына алып баруымны сорады. Авырый инде, хәле юк. Умарта бакчасына озак карап торды да күз яшьләрен сөртте: «Улым, булдыра алсаң, умарталыкны үз кулыңа ал әле. Ничек тә бетерәсе түгел иде», – диде. Менә шул вакытта үз-үземә сүз бирдем. Әтинең әманәтен үти алуыбызга сөенеп бетә алмыйм. Келәнчедә халык нинди авыр елларда да умартачылык белән шөгыльләнгән бит.

Сафин хуҗалыгында бүген даими рәвештә сигез кеше хезмәт куя. Ике ферма бинасы, янкормалар, автомат сөт саву җайланмалары... Барысы да көйләнгән. Фермер аларны безгә сөенеп тә, горурланып та күрсәтеп йөрде.

«УМАРТАЧЫЛАР ЭЛЕК ТӘ КҮП БУЛГАН, ХӘЗЕР ДӘ ҖИТӘРЛЕК»

Алда әйтелгәнчә, Келәнчедә гомергә умартачылар күп булган. (Гомумән, Кама Тамагы районында күпләр бал кортлары асрый). Әнә шуларның берсе – Гаделҗан Гизиев. Әтисе, бабасы да умартачы булган. Дөрес, биш-алты ел элек кортларын бетергән – аяклары начар йөри. Бабакайның яше дә бар инде, Аллаһ боерса, киләсе ел башында сиксән тугызны тутыра. Гаделҗан абыйны «тере энциклопедия» дип йөртәләр. Авылда бер гасыр эчендә булган күп тарихларны хәтерли ул.

– 1934 елгы мин, – диде бабай. – Гаиләдә дүрт бала идек, тик ике абыем сугыштан кайтмады. Бу бабайдан калган нигез. Шунда яңа йорт салып, мәрхүмә карчыгым Зәйтүнә белән гомер иттек. Биш бала дөньяга китердек, тик икесе яшьли үлде. Кыска гомерле булдылар шул, тумыштан килгән авырулары бар иде. Ике кызым, бер улым бар бүген. Алар гаиләләре белән Казанда яши,

6
Гаделҗан Гизиев турында авылда: «Тере энциклопедия», – диделәр.

7
«Бабайдан калган нигезгә яңа йорт салып, мәрхүмә карчыгым Зәйтүнә белән шунда гомер иттек», – диде Гаделҗан Гизиев.

атна саен кайтып йөриләр, Аллага шөкер. Зәйтүнә белән эти-әнине тәрбияләп соңгы юлга озаттык. Эти-әни белән бергә егерме елдан артык тату гомер кичердек.

Гаделҗан абый балачагын яхшы хәтерли, меңнән артык кеше яшәгән ул чакта. Сугыш вакытына туры килгән мәктәп еллары, аннан соң авылга ут, су кертүләр... Зур тарихи вакыйгаларның тере шаһиты ул.

– 1921 елгы ачлыкка кадәр авылда дүрт йөздән артык йорт, ике меңнән артык кеше яшәгән, – дип сүзен дәвам итте бабакай. – Шул авыр чакта яртьı авыл кешесе Донбасс, Әстерхан, Себер, Урта Азия якларына чыгып киткән. 1921 елны гаҗәеп корылык булган бит, утырткан бер нәрсәнең дә уңышын җыеп ала алмаганнар. Менә шул чорда авыл бушап калган. Йөзләгән кеше, балалар ачлыктан үлгән.

Гаҗәп, шундый авыр елда Келәнчедә мәктәп ачылган. Күрәсең, өстән кушылган сәясәт булгандыр ул. Белем йортына күрше Борнаш, Әтрәч, Кариле авылларыннан – өч районнан килеп укыганнар. Гаделҗан абый беренче класска 1942 елны барган, сигезьеллык мәктәп булган ул. Илдә сугыш барса да, укуларны бер көнгә дә туктатмаганнар.

– 1940 елны «Чабыр» бәйрәменә барганымны хәтерлим, – диде Гаделҗан абый. – Күрше Габдулла абый алты баланы ияртеп алып барды. Һич онытмыйм, «Чабыр»га Апас районы Йомралы авылыннан ике кәмит килгән иде. Без шунда әйләндек. Әй, аңа сөенгәннәр! Менә шул мизгел бер дә истән чыкмый...

Узган ел Гаделҗан абыйның 65 ел бергә яшәгән карчыгы Зәйтүнә апа вафат булган – ковидтан тернәкләнә алмаган. Уналты яшеннән ярәшеп, күп авырлыкларны җиңеп, бик тату яшәүче матур пар булганнар. Шуңа да Зәйтүнә апа турында сүз чыккан саен, бабакай күз яшьләрен сөртепсөртеп алды. Бик сагына ул җәмәгатен...

– Карчыгым киткәч, зерә дә ямансулап калдым, – диде ул. – Җиде яшемдә сугышка киткән абыемның тальянында уйнарга өйрәндем. Сугыш вакытында мәктәптә гел уйнаталар иде, чөнки бөтен гармунчылар фронтка китеп бетте бит. Гомер буе гармунны ташламадым. Бөтен мәҗлесләргә өчәүләп – Зәйтүнәм, гармуным белән йөрдек. Карчыгым мин уйнаганны бик ярата иде. Аны җирләгәннән соң гармуным да ямансулап калды кебек – тавышы моңсу чыга. Шуның өчен хәзер уйнамыйм...

Шулай да безнең өчен искәрмә ясады бабай, үзенең яраткан «Авыл көе»н сузды. Күз яшьләре аша елмаеп, дәртләнеп уйнады. Бу мизгелдә бабакай үзенең бөтен тормышын күз алдыннан кичерде кебек тоелды. Тамакка төер тыгылды. Эх, гомерләр...

Келәнченең тагын бер умартачылар гаиләсе – Хәмзиннәр. Гаилә башлыгы Рәшит абый кечкенәдән кортлар янында үскән, чөнки әтисе умартачы булган. Алай да бер мәл бу нигездә умартачылык эшен ташлап торганнар. Җан тартмаса, кан тарта диләрме – Рәшит абыйның улы Радик нәсел шөгылен дәвам иткән.

– Кайнатам урын өстенә калган, Рәшит көне буе тракторы белән кырда эшләгән,- диде хуҗабикә Мәдинә апа. – Шулай итеп кортлар таралып беткән. Мин ул вакытта әле бу йортка килен булып төшмәгән идем. Шактый еллар умартасыз гына яшәдек. Берсендә улыбыз Радик бер оя корт алып кайтты. Сигезенче сыйныфны тәмамлаган елыдыр ул. Аннары тагын бер оя табыштырды. Шулай итеп үрчеттек.

Бүген Хәмзиннәр хуҗалыгында утызлап оя корт бар. Быелгы бал уңышыннан канәгатьләр. Яз салкын булса да, кортлар яхшы гына эшләп алган. Хуҗалар инде бални аерткан, сөенечләре белән уртаклаштылар.

...Җәйге сәфәрләрне яратам. Борынны кытыклап җиләк, кипкән печән исе керә. Урамнар буйлап узарга да күңелле: ирексездән капка төпләренә күз төшә. «Бу йортта бигрәк уңган кешеләр яшидер, бакчалары шау чәчәктә» яки «Май чүлмәге тышыннан билгеле шул, ишек алларында ник бер чүп булсын», – дип нәтиҗә чыгарасың. Келәнчедә әнә шулай фәлсәфә корып, хозурланып, кичкә кадәр йөрдек. Кем очраса да елмаеп сөйләшә, күптән белгән таныш диярсең. Кешеләрнең генә түгел, авылларның да сөйкемле сыяклаpe була. Келәнченең дә үзенә гашыйк итә торган бер яме бар, монысы бәхәссез.

8

Рәшит Хәмзин кечкенәдән кортлар янында үскән, чөнки әтисе умартачы булган.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Роза Хәмитованың «Яза каләм Келәнче, Бәки кылганнарын» китабыннан:

«Мин боларны Вәгыйзь абый Идрисов истәлекләреннән язып алдым:

«Авыл тарихы турында төгәл мәгълүматлар калмаган. Шулай да мин дүртенче сыйныфта укыганда (1927–1928 уку елы) укытучыбыз Бәдретдин Гыймадиев Келәнче авылы тарихын болай сөйләгән иде: «Авылның мулласы Шиһап хәзрәт бер язу калдырды. Анда Келәнче авылы Болгар ханлыгы таркалганнан соң оешкан дип язылган. Куркыныч хәлләрдән соң өч гаилә Тау башына килеп утырган. Алар аучылык һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән. Келәнче – болгар телендә «аучы» дигәнне аңлата. Соңрак өч гаиләнең икесе читкәрәк күчеп урнаша. Бу Апас районына караган Болгаер һәм Борнаш авыллары булырга тиеш».

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

Фото: Александр Ефремов, Михаил Захаров/tatar-inform.ru

«ТАРХАН» ТАЛАНТЛАР АЧА

Илүзә Илшатова

Университетта укудан булдыра алганның барысын да ничек алырга? Дүрт ел эчендә үзеңне төрледән төрле эшчәнлек юнәлешләрендә ничек сынап карарга? Халыкара мөнәсәбәтләр институтының «Тарих» юнәлешенә караган иң перспективалы профильләрнең берсе – «Төрки халыклар тарихы»н сайлап алганда бу мөмкин хәл. Укырга керергә кыенмы? Бу эштә «Тархан» уникаль тарихи-мәдәни конкурсы ярдәм итә ала. Хәер, барысын да тәртип буенча аңлатыйк.

«Төрки халыклар тарихы» программасы тюркология, көнчыгыш телләре, Россия һәм күрше илләр халыклары тарихы өлкәсендә белгечләр әзерләүгә юнәлдерелгән. Укыту процессы гомумтарихи, тел һәм көнчыгыш белеме буенча әзерлекне үз эченә ала. Бакалавриат кысаларында студентлар гомуми тарихи процессларның закончалыкларын, сәяси, социомәдәни, икътисадый, этник тарихны өйрәнәләр, тарихи чыганаклар белән танышалар, тәҗрибәле җитәкчеләр ярдәмендә тюркология өлкәсендә тикшеренү эшләре алу бару мөмкинлеге алалар.

Әлбәттә, белем алуның перспективалы юнәлеше буенча укырга керү өчен, абитуриентка җитди конкурсны үтәргә – тарих, җәмгыять белеме һәм рус теле буенча БДИны яхшы бирергә кирәк. Хәер, быелгы уку елыннан башлап, Халыкара мөнәсәбәтләр институтына керү мөмкинлеге арта төшә. Бу эштә «Тархан» конкурсы ярдәм итәчәк – анда җиңүчеләр һәм призерлар укырга кергәндә ташламалы шартларга ия булачак.

КОНКУРС: ИКЕ ТЕЛ ҺӘМҺӘРКЕМ ӨЧЕН ШАНС

Быел беренче «Тархан» конкурсында Татарстан Республикасы

мәктәпләрендә белем алучы урта һәм өлкән сыйныф укучылары катнашты. Оештыручылар билгеләгән максат – яшьләр арасында Татарстан һәм төрки халыклар тарихына һәм мәдәниятенә кызыксыну уяту, шулай ук язмышын тарих белән бәйләргә ниятләгән талантлы яшьләрне ачыклау.

Төп стимул: җиңүчеләр Казан (Идел буе) федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбендә «Төрки халыклар тарихы» профиле буенча бушлай уку мөмкинлеге ала.

Түбәндәге мөһим фактор конкурска аерым бер әһәмият өсти: бүгенге Россия Федерациясе территориясендә бик күп төрки халыклар яши, һәм аларның мәдәниятен, тарихын белү Россия җәмгыятьчелегендә этникара һәм конфессияара татулыкны ныгытырга булыша.

«Тархан» конкурсы – Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институты белән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының уртак проекты.

Конкурс биремнәрен оештыру һәм әзерләүгә Казан (Идел буе) федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбенең Методик комиссиясе җитди өлеш кертте. Югары мәктәп хезмәткәрләре арасыннан шул исәптән экспертлар комиссиясе дә төзелде.

Конкурс һәркемгә яхшы мөмкинлек бирә, чөнки бу ике телле проект. Конкурс сорауларына укучылар татар телендә дә, рус телендә дә җавап бирә ала. Асылда катнашучылар тигез старт мөмкинлекләренә ия – шул исәптән ниндидер сәбәпләр аркасында бюджет урынына дәгъва кыла алмаган укучылар да.

НИЧЕК ИҢ ЯХШЫСЫ БУЛЫРГА

Башлангыч этапта конкурс сайтына 250 дән артык гариза керде. Катнашучылар читтән торып җитди сайлау аша узды. Нәтиҗәдә Татарстанның 12 районында яшәүче 32 укучы гына

ЭКСПЕРТЛАР ФИКЕРЕ:

РАМИЛ ХӘЙРЕТДИНОВ, **КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры:**

– Милли тарих өлкәсендә телевизион гуманитар олимпиада оештыру идеясе күптән туды, «Тарих» юнәлеше буенча әзерлекнең махсус профилен ачканнан бирле. Аны без республика башлыгы Рөстәм Миңнехановның шәхси ярдәме, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессының булышлыгы белән тормышка ашырабыз. Шуңа бәйле рәвештә әлеге максатчан программа буенча укырга Россиянең барлык төбәкләреннән һәм дөньяның төрле илләреннән талантлы балаларны җәлеп итүнең гадәти булмаган ысулын табасы килде. Шул ук вакытта минем өчен «Тархан» телевизион конкурсының калька яисә бүгенге көндә Россиядә яисә чит илләрдә бара торган викториналарны кабатлау булмавы гаять мөһим иде. Безнең иҗат командасының уртак көче белән кызыклы проект туды һәм аңа милли тарих, мәдәният һәм традицияләр белән кызыксынучы аеруча актив яшьләрне җәлеп итү мөмкин булды. Иң мөһиме – бу КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институтында белем алырга, Татарстанда яшәргә һәм эшләргә теләүчеләр. Тапшырулар уяткан резонанс «Тархан» конкурсының бүгенгесе шәп, киләчәге өметле булуын күрсәтте. Якын араларда без әлеге программаны уникаль интеллектуаль продукт буларак патентларга уйлыйбыз.

АЙРАТ СИТДЫЙКОВ, **Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирас югары мәктәбе деканы:**

– Безнең программаны тормышка ашыру – талантлы балаларның Татарстан Республикасы бүлеп бирә торган максатчан урыннарга укырга керү мөмкинлеген арттыру ул. Һәркем катнаша, ә иң сәләтлеләре КФУга укырга керә ала торган мәйданчыклар булдыру бик мөһим. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: конкурсның беренче елы укучыларның тарих белән кызыксынуы зур булуын күрсәтте. Катнашучылар, һичшиксез, бик тырыштылар. Укытучыларның эшен аерым билгеләп үтәм. Бу мәйданчык безгә талантлы укытучылар белән хезмәттәшлекне җайга салырга мөмкинлек бирде, алар белән без киләсе конкурс сезонында да эшләячәкбез.

РАФАЭЛЬ ВӘЛИЕВ, **фәнни эшчәнлек буенча директор урынбасары:**

– Бу проектның киләчәге зур. Республикабызда бик көчле тарихи, археологик, этнографик мәктәпләр, Татарстан халыклары, татар халкы тарихын өйрәнүгә бәйле эзләнүләр бар. Без талантлы балаларны институтыбызда күрергә бик шат.

көндезге – телевизион этапта катнашу хокукына ия булды.

Көндезге уеннар чыгып китү кагыйдәсе буенча оештырылды. Катнашучыларга TED стилендә чыгыш ясарга һәм үзләренең белемен, артистлык сәләтен һәм харизмасын күрсәтергә кирәк булды. Иң аз балл җыйганнар конкурстан төшеп кала барды, калганнар ярышны тагын да югарырак дәрәҗәдә – киләсе турда дәвам итте. Конкурсның 1/8, ¼ финаллары, ике ярымфинал һәм кызыклы финал нәкъ шулай узды.

Көндәшлекле көрәштә дүрт конкурсант җиңүгә иреште. Беренче урынны «Актанышның аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ укучысы Илнур Әмирханов яулады. «Яшел Үзән муниципаль районының 3 нче гимназиясе» МББУ укучысы Андрей Цапок икенчелекне алды. Сәет Сруров («Иннополис» лицее) һәм Ләйсән Галиуллина («Сарман гимназиясе» МББУ) үзара өченче урынны бүлеште.

КОНКУРСТА НИЧЕК КАТНАШЫРГА

«Тархан» конкурсында Россия Федерациясенең барлык субъектларында яшәүче 10-11 сыйныф укучылары һәм урта махсус белем бирү учреждениеләре студентлары, шулай ук якын һәм ерак чит илләрдәге абитуриентлары катнаша ала. **Киләсе сезонга гаризаларны кабул итү 2022 елның октябреннән башлана.**

Конкурс ике турда уздырыла:

1-й тур – онлайн (читтән торып) www.univer.tatar/tarhan.ru сайтында теркәлүне, тест үтүне һәм бирелгән темага эссе язуны үз эченә ала.

2-й тур – офлайн (көндезге) уен-телевикторина форматындагы 4 этаптан тора – 1/8, 1/4, 1/2, финал. Һәр этапта өчәр җиңүче билгеләнә, алар көндезге турның киләсе этабына уза.

«Тархан» конкурсының күп этаплы интеллектуаль телевизион шоу йомгаклары буенча жюри өч җиңүчене билгели.

«ТАРХАН» КОНКУРСЫНДА ҖИҢҮЧЕЛӘР СӨЙЛИ

ИЛНУР ӘМИРХАНОВ:

– Кечкенәдән үк тарих белән мавыгам. Барысы да әбинең үз авылы турында сөйләгән риваятьләреннән башланды. Аннары миңа төрле урыннарның тарихын белү кызык тоелды. «Тархан» бәйгесендә бик теләп катнаштым. Әлеге конкурс нәтиҗәсендә тарих белән кызыксынучы яшьләр күпкә артачак, дип уйлыйм. Конкурс үзеңне тагын да үстерү өчен зур этәргеч бирә. Миңа ярдәм иткән, шул исәптән бу юлдан мине алып барган укытучыма зур рәхмәт әйтәсем килә.

АНДРЕЙ ЦАПОК:

– Минем мондый ярышларда катнашу тәҗрибәм шактый («Умники и умницы», тарих буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасы, Татарстан һәм татар халкы тарихы буенча республика олимпиадасы, башка олимпиадалар), шуңа күрә артык дулкынланмадым кебек. Җиңү яулаганда эмоцияләр дә бик көчле булмады, чөнки мин баштан ук үземне җиңүгә әзерләдем. Бик җитди эшләдем: күп укыдым, тестлар чиштем. Биремнәрнең авырлыгы турында болай дип әйтәсем килә: беренче турдан соң нинди сораулар буласы һәм уенның форматы аңлашылды, мин нәрсәгә әзерләнергә кирәклеген белдем. Ә менә беренче уен, сине нәрсә көткәнен аңламаган чакта, чыннан да кыенрак булды. Әмма бернигә дә карамастан, мин җиңдем һәм моңа бик шат.

ЛӘЙСӘН ГАЛИУЛЛИНА:

– Конкурс турында тарих укытучым һәм сыйныф җитәкчем Кифая Әхсән кызы Заһировадан белдем. Тарих белән күптәннән мавыгам, туганнан бирле дияргә була. Конкурска көн-төн әзерләндем – Кифая Әхсәновна ярдәмендә, өйдә эти-әниләр белән. Барыннан да элек конкурсның колачы, жюри составы мине таң калдырды (берничә министрлык җәлеп ителгән иде). Кумирым Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов белән очрашу истә калды. Мин барысына да чиксез рәхмәтле.



КАМИЛЛЕККӘ ИРЕШҮ ЮЛЫНДА

Гөлнара Лялина,
«Гидрозо» ҖЧҖнең Казан шәһәрендәге филиалы җитәкчесе

–Хөрмәтле Эдуард Юрьевич!

«Гидрозо» компаниясе коллективы Сезне ихлас күңелдән юбилеегыз белән тәбрик итә!

Сезнең идарә итә белү таланты, профессиональлек, җаваплылык, эшкә иҗади якын килү кебек иң яхшы сыйфатларыгызга озак еллар дәвамында дәүләт дәрәҗәсендә ихтыяҗ булып торсын. Татарстанда яхшы сыйфатлы юллар күбрәк булсын, ә әлеге бурычны хәл итү юнәлешендәге уртак хезмәттәшлегебез дәвам итсен!

Сезгә барлык күркәм башлангычларыгызда уңышлар, зур планнар һәм аларны шәп итеп тормышка ашыруыгызны телибез. Озын гомер, ныклы сәламәтлек юлдаш булсын Сезгә!

«Гидрозо» компаниясе тарафыннан җитештерелә торган продукция исемлегендә ясалма юл өслекләрен һәм корылмаларын саклау, аларның чыдамлыгын арттыру өчен кулланылучы сыйфатлы материаллар аерым урын биләп тора.

Бетонга өстәлмә, металл саклау системасының төрле элементлары, күпер өслеге өчен полимер материаллар, деформацияле җөй зоналарын каплау – болар барысы да юл үткәргечләре, юл чишелешләре, күперләре булган заманча магистральләр төзелә торган урыннарда бигрәк тә кирәк.

Безнең даими партнерларыбыз арасында Татарстан предприятиеләренең булуы очраклы хәл түгел: республика алга киткән юллар челтәре белән дан тота. Юллар биредә үрнәккә куярлык дәрәҗәдә карап тотыла, даими яңартыла һәм камилләштерелә.

Болар барысы да, әлбәттә, очраклы түгел: җаваплы дәүләт структуралары ышанычлы контрольне, партнерларның тырышлыгын көйләүне, дөрес планлаштыруны һәм бурычларны төгәл үтәүне тәэмин итә. Моны үз тәҗрибәбездә дә күрәбез: безнең «Главтатдортранс» Дәүләт казна учреждениесе белән эшлекле хезмәттәшлегебез республикада автомобиль юлларын һәм корылмаларын проектлау, төзү, реконструкцияләү, төзекләндерү һәм карап тотуда бердәм дәүләт сәясәте гамәлгә ашырылуын раслый.

Бу эштә «Главтатдортранс» җитәкчесе Эдуард Даниловның да өлеше зур булуын беләбез. Аның профессиональлегенә, эшкә дәүләтчә якын килә белүенә бер генә мәртәбә инанырга туры килмәде.

ГИДРОЗО
Нәтиҗәле төзелеш карарлары

Фотолар «Гидрозо» компаниясеннән алынды, tatar-inform.ru. РЕКЛАМА

ЯЗМЫШ ЮЛЛАРЫ

ТАТДОРПРОЕКТ
ИНСТИТУТ ПО ПРОЕКТИРОВАНИЮ ОБЪЕКТОВ ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РТ

Эдуард Данилов – республика юллары өчен җаваплы кеше. Эдуард Юрьевич – «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» – «Главтатдортранс» дәүләт казна учреждениесе директоры.

Елена Пановская,
«Юл хуҗалыгы объектларын проектлаштыру институты» АҖ генераль директоры

– Хөрмәтле Эдуард Юрьевич! Теләсә кайсы республиканың, өлкәнең, крайның икътисадый үсеш дәрәҗәсендәге иң мөһим күрсәткечләреннән берсе төбәк һәм җирле юлларның торышы икәнлеген яхшы беләбез. Татарстанның горурланырлыгы бар: бездәге юл челтәре илдә иң яхшыларның берсе булып тора, ул тотрыклы үсә, камилләшә. Бәхәссез факт: социаль иминлегебез өчен кирәкле йөзләрчә чакрым юл Сез шушы җаваплы вазыйфаны башкарган вакыт эчендә төзелгән һәм ремонтланган, бу эшләр тирән уйланылган карарлар кабул итү, тармакка бәйле оешмаларның эшен координацияләү һәм көйләү нәтиҗәсендә башкарылган. Республика муниципаль районнарында юл хәрәкәтенең сыйфатын һәм иминлеген арттыру өчен шәхсән үзегез һәм командагыз тарафыннан никадәр хезмәт куелган!

Транспорт артерияләрен төзегәндә, елга ярларын тоташтырганда, төрле ясалма корылмалар булдырганда, без Сезнең үзегез һәм командагыз белән тыгыз элемтәдә эшлибез, һәм бу хезмәттәшлек тулысынча конструктив нигездә алып барыла. Сезгә Татарстан Республикасы юл-транспорт челтәре тармагында гамәлгә ашырылган проектлар өчен, шулай ук көнүзәк мәсьәләләрне дөрес хәл итәргә булышып, проектлаучыларның проблемаларын һәрвакыт аңлап эшләгәнегез өчен рәхмәтлебез. Бай тормыш тәҗрибәгез, һөнәри осталыгыгыз, максатчанлыгыгыз, иң җитди мәсьәләләрне хәл итү юлларын дөрес таба белү сәләтегез һәрдаим үзгәрештәге бүгенге тормышта безнең өчен ышанычлы маяк булып тора.

Хөрмәтле Эдуард Юрьевич!

«Татдорпроект» институты» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм! Күп еллар дәвамында тупланган һөнәри тәҗрибәгез киләчәккә ышаныч белән карарга һәм куелган максатларга нәтиҗәле ирешергә мөмкинлек бирсен, ә Сезнең эшчәнлегегез киләчәктә дә кешеләрнең иминлеге, мул тормышы һәм республиканың гөрләп үсүе өчен хезмәт куя белүнең якты үрнәге булып торсын! Эшегездә, барлык теләк-ниятләрегездә уңышлар телибез, хезмәттәшләрегез Сезне аңлап, булышлык күрсәтсен, туганнарыгыз һәм якыннарыгызның күңел җылысы һәм яратуы һич кимемәсен!

Фото «ТР Юл хуҗалыгы объектларын проектлаштыру институты» АҖнән алынды.
РЕКЛАМА

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN

Реклама бүлеге:
тел.: (843) 222-09-79
8-9600-487-900
8-9172-740-352

Реклама 16+

«ВАСИЛЬЕВСКИЙ»: ГАИЛӘ БЕЛӘН РӘХӘТ ЯЛ

Чираттагы ялны күңелле генә түгел, гаилә өчен файдалы да уздырырга кирәк дип баш ватасызмы? Димәк, сезгә «Васильевский» шифаханәсенә юл тотарга вакыт!

ТИРӘНРӘК СУЛАГЫЗ!

Бирегә хәтта бер тапкыр да булмаган кешеләргә дә шифаханәнең тышкы күренеше таныш тоелачак. Мезонинлы борынгы йорт, уртада күле булган зур урман-парклы территория – табигатьне беренчел халәтендә саклап калуның сирәк очрый торган үрнәге генә түгел, ә яңа урыннар белән танышырга, өйрәнергә яратучылар өчен чын табыш та бу. Җәй көне шифаханәнең нарат урманы тынчу эсселектән коткара, кышын җилдән ышыклый, ә ике йөз яшьлек агачларның серле шаулавы шәһәр ыгы-зыгысыннан аерып тора. Шифаханәнең уникаль микроклиматы өлкәннәргә генә түгел, балаларга да файдалы.

УҢАЙЛЫ ДА, ФАЙДАЛЫ ДА ЯЛ

«Васильевский» – заманча дүрт торак корпус һәм тарихи «Аучы йорты»ннан гыйбарәт комплекс. Ул берьюлы 500 дән артык кешене кабул итә ала. Ялгызы гына ял итүчеләр өчен һәм шифаханәгә гаилә белән килүчеләр өчен бер, ике урынлы һәм люкс категориясендәге номерлар бар – теләгәнен сайлап ал. Монда һәркемгә уңайлы. Шунысы да мөһим: биредә теләсә кайсы яшьтәге балалар белән ял итәргә була, өстәвенә, өч яшькә кадәрге балалар бушлай яши, ата-аналар соравы буенча номерга нәниләр өчен караватт куйдырырга мөмкин.

Саллы дәвалау-диагностика базасы кунакларга савыгу һәм сәламәтлек өчен бик күп төрле хезмәтләр тәкъдим итә – 30 дан артык төрдә дәвалау-профилактика процедуралары, шул исәптән шифалы су белән дәвалау, кул көче белән ясала торган һәм аппаратлы массажлар, бихисап физиотерапия ысуллары... Шифаханәнең төп өстенлекләреннән берсе – табигый дәва чаралары: үзенең сульфат-хлорид-натрийлы «Васильевская» минераль суы; Саак күленең шифалы ләме; ванналар өчен минераль су – составында йод һәм бром булганы, йөрәк-кан тамырлары, терәк-хәрәкәт һәм нерв системаларына яхшы йогынты ясый торган югары концентрацияле тоз эремәләре.

Биредә нерв системасы; терәк-хәрәкәт аппараты; сулыш системасы чирләре; кардиологик, гинекологик, урологик, гомумән, теләсә нинди авырулары булган, теләсә кайсы яшьтәге кунакларны кабул итәләр. Онкологик авырулар да биредә тернәкләндерү курсы уза.

Шифаханә кунакларының буш вакытлары өчен чаралар да һәркем үз зәвыгына туры килгәнне сайлап алырлык итеп оештырылган. Тыныч ял итәргә яратучылар өчен китапханә, кинозал эшли, шигърият кичәләре, концертлар, тематик бию кичәләре үткәрелә. Актив ял яратасызмы? Тренажерлар, өстәл теннисы, бильярд залы, волейбол һәм баскетбол мәйданчыклары, караоке, дискотека – барсы да сезнең карамакта. Нәни кунаклар өчен аерым меню, уен бүлмәләре, ресторанда исә бала урындыклары бар. Балалар өчен велосипед, самокат, туп һәм сикергечләрне прокатка алырга мөмкин. Күңел ачу чаралары исемлегендә хәзерге заманча өстәл уеннары, балалар мәйданчыклары, аниматорлар һәм хәтта шифаханәнең үз дискотекасы да бар.

Шифаханә кунаклары өчен тиешенчә балансланган, дөрес туклану таләпләренә туры килгән, бай меню әзерләнгән. Ризыклар яңа суелган иттән пешерелә. Табында – балык, яшелчә һәм җиләк-җимеш, фермерлардан китерелгән табигый сөт продуктлары. Үз зәвыкларына һәм табиб билгеләгәннәргә туры килгән менюны ата-аналар да, балалар да, әби-бабайлар да табачак. Вегетариан табын да, хәләл меню да бар.

«Васильевский» – гади бер шифаханә генә түгел. «Үз» энергетикасына ия искиткеч урын да әле ул: биредә һәркем – бала-чага да, чал чәчле әби-бабай да күңеленә хуш килгән шөгыль табачак һәм сәламәтләнеп кайтачак.

Чөнки гаилә тату гына түгел, сәламәт тә булырга тиеш!

Фотолар «Васильевский» шифаханәсеннән алынды. РЕКЛАМА
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

12:22
АО "ТАТМЕДИА"
5.0 (6 Оценок)
113 Заказ
Продажа печатной продукции
Онлайн-чат
Подробно
КИЛЛЕР
140 ₽

Казан. «Я выбираю небо!» авиация тамашасы

Фото: Александр Ефремов